# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2025 2 (46)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан нәшер ителә.***
***Елына кәгазь һәм электрон форматта 4 сан чыгарыла.***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе

► **РЕДКОЛЛЕГИЯ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, редколлегия рәисе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МИҢНЕХАНОВ Р.Н., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХАЛИКОВ И.И., филология фәннәре кандидаты (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ МӨХӘРРИР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
НАДЫРШИНА Л.Р., ГЫЙНИЯТУЛЛИНА Л.М. (җаваплы сәркатип)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ДӘҮЛӘТШИНА Л.Х. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
АБДУЛЛИНА Н.Т., ЧУГУНОВ А.С.

Редакция адресы: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһ., К. Маркс ур, 12.
ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Тел.: (843) 590-61-11
E-mai1: f_tatarstan@mail.ru
Сайт: https://ft.antat.ru/

## БУ САНДА


### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Гыйләҗетдинова Г.Х.* XV–XVII гасырлар рус телендәге Көнчыгыш алынмалары сүзлеген оештыру үзенчәлекләре . . . . .7
*Хәбибуллина Л.Г.* Татар телендә иярчен җөмлә төрләре . . . . . . .15
*Хисияма Ю.* Соңгы иҗектә [и] сузыгы булган гарәп-фарсы алынмаларында сингармонизм күренеше: Татар теленең язма корпусы нигезендә тикшеренүләр . . . . . . .21
*Идиятуллина А.И., Хөсәинова А.Я.* Татар теленең метеорологик лексикасын өйрәнү тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .29

### ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ФӘНЕ

*Алишина Х.Ч.* Элгәрләребезнең фәнни мирасы: тюрколог, борынгы уйгур теле белгече профессор Д.М. Насиловның тууына 90 ел тулу уңаеннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .34

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Юсупова Н.М.* Кәшшаф Патии: шагыйрь, укытучы, мулла . . . . .46

### ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 140 ЕЛЛЫКНЫ КАРШЫЛАП

*Заһидуллина Д.Ф.* Фатих Әмирхан: татар халкы өчен янып яшәү. .53
*Хөснетдинова Г.А.* Халык мәнфәгатен яклап.... . . . . . . . . . . .66

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Дәүләтшина Л.Х.* Татар йола фольклорының бүгенге яшәеше: солдатка озату йоласы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .77

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Абзалина Р.Ә.* Күңел матурлыгын сурәтләрлек пумалалар бармы дөньяда?.. *(К. Насыйри портретын ясау тарихы)*. . . . . . . . . .88

### БӨЕК ҖИҢҮГӘ 80 ЕЛ

*Дәүләтшин Г.М.* Г. Фронт һәм фән юлын узган галимнәр . . . . .95
*Фазлетдинов И.К.* Башкортстан татарларының бәетләрендә Бөек Ватан сугышы вакыйгалары чагылышы . . . . . . . . . . 110

### СӘНГАТЬ

*Шевченко Е.Н.* Коки Митаниның «Көлке академиясе» Айдар Җәббаров куелышында. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
*Галиева Р.Н.* 1920 еллар татар плакатларының визуаль теле һәм пластик чишелеш үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . 125
*Шкляева Л.М., Герасимова Н.В.* Ф.Г. Халиков иҗатында тарихи жанр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133

## ФӘННИ ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*Гайнетдинов А.М.* Самара өлкәсе Камышлы районының эпиграфик мирасы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Фәйзрахманов Җ.И.* Фәнгә яңалык кертүче
*(профессор Ф.С. Сибгатуллинның фәнни мирасы)* . . . . . . . . 145
*Закирова И.Г.* Фольклорчы Флора Әхмәтова-Урманче . . . . . . 150
*Бәширова И.Б.* «Әдәби тел тарихы – аның стильләре тарихы»
*(Латыйф Җәләйнең тууына 130 ел тулу уңаеннан)* . . . . . . . . 155
*Ямалтдинов И.И.* Татар җырларын өйрәнүгә багышланган гомер
*(фольклорчы Илбарис Надировның тууына 100 ел)* . . . . . . . . 169

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Ильина Г.Г.* Татарларның дөньяны мифологик кабул итүе:
төп образлар һәм символлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ


*Гилязетдинова Г.Х.* Особенности организации словаря восточных слов в русском языке XV–XVII веков . . . . . . . . . . .7

*Хабибуллина Л.Г.* Виды придаточных предложений в татарском языке. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .15

*Хисияма Ю.* Проявление сингармонизма в арабско-персидских заимствованиях с гласным [и] в конечном слоге: исследования на основе Письменного корпуса татарского языка. . . . . . . . . .21

*Идиятуллина А.И., Хөсәинова А.Я.* История изучения метеорологической лексики татарского языка . . . . . . . . . . . .29


### НАУКА ТЮРКСКИХ НАРОДОВ


*Алишина Х.Ч.* Научное наследие предшественников: к 90-летию тюрколога, специалиста по древнеуйгурскому языку профессора Д.М. Насилова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .34


### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ


*Юсупова Н.М.* Кашшаф Патии: поэт, педагог, имам-хатыб . . . . .46


### К 140-ЛЕТИЮ ФАТИХА АМИРХАНА


*Заһидуллина Д.Ф.* Фатих Амирхан: жизнь во имя татарского народа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .53

*Хуснутдинова Г.А.* На защите интересов народа... . . . . . . . . . .66


### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО


*Давлетшина Л.Х.* Современное бытование обрядового фольклора татар: обряд проводов в армию . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .77


### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ


*Абзалина Р.А.* К истории создания портрета К. Насыри . . . . . . .88


### 80 ЛЕТ ВЕЛИКОЙ ПОБЕДЕ


*Давлетшин Г.М.* Ученые-фронтовики ИЯЛИ . . . . . . . . . . . .95

*Фазлутдинов И.К.* Отражение событий Великой Отечественной войны в баитах татар Башкортостана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110


### ИСКУССТВО


*Шевченко Е.Н.* «Академия смеха» Коки Митани в постановке Айдара Заббарова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119

*Галиева Р.Н.* Особенности визуального языка и пластических решений татарских плакатов 1920-х гг. . . . . . . . . . . . . . . 125

*Шкляева Л.М., Герасимова Н.В.* Исторический жанр в творчестве Ф.Г. Халикова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133

## ПО СЛЕДАМ НАУЧНЫХ ЭКСПЕДИЦИЙ

*Гайнутдинов А.М.* Эпиграфическое наследие Камышлинского района Самарской области . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139

## ПЕРСОНАЛИИ

*Файзрахманов Дж.И.* Научное наследие профессора Ф.С. Сибагатуллина . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145

*Закирова И.Г.* Фольклорист Флора Ахметова-Урманче . . . . . . 150

*Баширова И.Б.* Об истории стилей татарского литературного языка *(к 130-летию со дня рождения Латифа Заляя)* . . . . . . 155

*Ямалтдинов И.И.* Исследователь татарской песенной поэзии *(100 лет со дня рождения фольклориста Ильбариса Надирова)* . 169

## НОВЫЕ КНИГИ

*Ильина Г.Г.* Мифологическое мировосприятие татар: ключевые образы и символы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 81'374

*Г.Х. Гыйләҗетдинова*

# XV–XVII ГАСЫРЛАР РУС ТЕЛЕНДӘГЕ КӨНЧЫГЫШ АЛЫНМАЛАРЫ СҮЗЛЕГЕН ОЕШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В статье представлена концепция «Словаря восточных заимствований XV–XVII вв.», относящегося к историческим словарям филологического типа. Источниковой базой Словаря выступают памятники письменности разножанрового характера – повести, пьесы, официально-деловые тексты, описи имущества, хожения, эпистолярные источники, конфессиональная литература и др. Выявляется словообразовательный потенциал восточных слов в русском языке XV–XVII вв., определенную часть которых составляют лексические единицы тюркского и татарского происхождения. Определены принципы описания выявленных дериватов в подготовленном к публикации словаре восточных заимствований исследуемого периода. Подчеркивается, что неодинаковая словообразовательная активность ориентализмов обусловлена как особенностями самих заимствованных лексем, так и адаптационными возможностями языка-рецептора.

**Ключевые слова:** ориентализмы, язык-рецептор, словообразовательный потенциал, русский язык XV–XVII вв., словарь восточных заимствований.

The article presents the concept of the “Dictionary of Eastern Borrowings of the 15th–17th Centuries”, which belongs to historical dictionaries of the philological type. The source base of the Dictionary is written monuments of different genres – stories, plays, official and business texts, inventories of property, travels, epistolary sources, confessional literature, etc. The word-formation potential of Eastern words in the Russian language of the 15th–17th centuries is revealed, a certain part of which are lexical units of Turkic and Tatar origin. The principles of describing the identified derivatives in the Dictionary of Eastern Borrowings of the period under study, prepared for publication, are determined. It is emphasized that the unequal word-formation activity of Orientalisms is due to both the peculiarities of the borrowed lexemes themselves and the adaptive capabilities of the receptor language.

**Keywords:** orientalisms, receptor language, word-formation potential, Russian language of the 15th–17th centuries, Dictionary of Eastern borrowings.

Хәзерге тарихи лексикография фәне хәл итәсе актуаль мәсьәләләрнең берсе булып билгеле бер өлешен төрки һәм татар чыгышлы лексик берәмлекләр тәшкил иткән борынгы рус чоры Көнчыгыш алынмалары сүзлеген төзү тора. Бүгенге көндә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлегендә «XV–XVII гасырлар рус телендәге Көнчыгыш алынмалары сүзлеге» басмага әзерләнә. Тикшерелә торган чор ориентализмнарының тулы җыелмасын төзегәндә, төрле жанрларга караган язма истәлекләр кыйммәтле чыганак ролен үти.

Сүзлекнең бурычы – рус милли әдәби теле формалашкан чорда Көнчыгыш алынмаларының һәм алардан ясалган сүзләрнең яшәеш үзенчәлекләрен билгеләп, аларны анализлана торган чыганаклар төркемендә аерып күрсәтү.

Жанры ягыннан хезмәтне филологик типтагы тарихи сүзлек дип атарга мөмкин. Сүзлек 1600 гә якын лексеманы (алынмалар һәм сүзләрнең гомуми санының яртысын диярлек тәшкил иткән шул алынмалардан ясалма номинацияләрне) һәм 350 дән артык сылтама сүзне (сүзлектә фонетик, сүзьясалыш, морфологик вариантлар өчен сылтамалы юллар бар) колачлый. Ул алфавит тәртибендә төзелә.

Сүзлек телдә безнең көннәргә кадәр сакланган лексемаларны (амбар, бахрома, казна, казначей, нефть, очаг) һәм бүгенге көндә кулланылыштан төшеп калган алынмаларны үз эченә ала. Мәсәлән: (*алафа* [тур. ülüfe ‘жалованье’ от араб. ‘ulüfa ‘жалованье, плата’] ‘награда, дар; жалованье; оброк’, *алман* [шор., леб., саг., чул. alban ‘дань, подать’ (из монг. alban, калм. alwn̥)] ‘налог, собираемый в пользу правителей местных народов Сибири’, *бехтерец* [из монг. bekter ‘доспех из металлических дощечек’] ‘панцирь из металлических пластинок’).

Алынма сүзләрне анализлау өчен, XV–XVII гасырларга караган төрле язма истәлекләргә мөрәҗәгать ителә. Галимнәр фикеренчә, алар рус теленең халыклашкан әдәби-язма вариантында иҗат ителгәннәр (В.В. Виноградов, Б.А. Ларинин, В.В. Колесов һ. б.). Анализланган текстлар арасында (150 дән артык язма истәлек) түбәндәгеләр бар: 1) публицистик текстлар (И. Пересветов, патша Явыз Иван (XVI гасыр), протопоп Аввакум (XVII гасыр) һ. б. әсәрләре); 2) XV–XVII гасырлар рус повестьлары; 3) пьесалар («Артаксерксово действо» (1672), «Юдифь» (1674), «Баязет и Тамерлан» (1674–1675 ) һ. б.).

Файдаланылган чыганаклар арасында чит илләрне тасвирлауга багышланган сәяхәтнамәләр («Хожение инока Зосимы» (1419–1422); Афанасий Никитинның «Хожение за три моря» (1466–1472); «Хожение купца Василия Познякова по святым местам Востока» (1558–1561) һ. б.) аерым урын алып тора. Әлеге әсәрләрдә шәркый чыгышлы экзотик лексика киң кулланыла. Бу сәяхәтнамә жанры үзенчәлекләре белән аңлатыла. Чыганаклар арасына шулай ук рус теленең милли чор әдәби нормалары, аның сүзлек составы, шул исәптән Көнчыгыш фондының формалашу процессын тикшерүдә зур әһәмияткә ия булган эш кәгазьләре текстлары да кертелде: рәсми эш кәгазьләре («Акты Московского государства» (1571–1644), таможня кенәгәләре, илчеләрнең отчёт-көндәлекләре).

Эш кәгазьләре репрезентантлары сыйфатында эпистоляр текстлар («Частная переписка князя П.И. Хованского, его семьи и родственников» (XVII гасыр), «Письма царя Михаила Федоровича» (1619–1631) һ. б.) тикшерелде. Аларда Мәскәү дәүләтендәге төрле халык катлауларының шәхси тормышы һәм эшчәнлеге турында кыйммәтле мәгълүматлар бар.

Чыганакларның шактый зур төркемен халык сөйләм теле тарихы буенча истәлекләр тәшкил итә. Алар эш кәгазьләрендә һәм көндәлек тормышта Көнчыгыш сүзләренең киң үзләштерелүен һәм таралуын күрсәтә. Шундыйлардан «Памятники русского народно-разговорного языка XVII столетия (из фонда А.И. Безобразова)» (М., 1965), «Московская деловая и бытовая письменность XVII века» (М., 1968), «Грамотки XVII – начала XVIII в.» кебекләрне билгеләп үтәргә мөмкин.

Тарихи-этнографик пландагы кыйммәтле лексик материалны үз эченә алган текстлар аерым игътибарга лаек. Мәсәлән, патшалык итүче затлар даирәсенә караган мал-мөлкәт исемлекләре («Платье царя Бориса Феодоровича Годунова, 1589 г.», «Царская утварь и платье царя Феодора Алексеевича, 1682 г.» һ. б.). Алар төрле тематик төркемнәргә (тукыма, өс киеме, аяк киеме, көбә кием һәм кораллар, ат дирбияләре һ. б.) караган Көнчыгыш алынмаларын ачыкларга мөмкинлек бирә.

Конфессиональ әдәбият истәлекләре (изгеләрнең тәрҗемәи хәлләре, мактау сүзләре һ. б.), Көнчыгыш лексикасы бик аз тәкъдим ителүгә карамастан, иске рус телендәге төрле жанрларга караган чыганаклар аша чит тел лексик берәмлекләренең яшәешен бербөтен картина итеп күзаллый алабыз.

Чыганаклар буларак XVI гасыр – XVIII гасыр башына караган җирле эш кәгазьләрен фәнни әйләнешкә кертеп җибәргән региональ тарихи сүзлекләр файдаланыла: «Региональный исторический словарь второй половины XVI – XVIII вв. (по памятникам письменности Смоленского края)» (Смоленск, 2000), «Казанский край: словарь памятников XVI в.» (Казань, 2000), «Казанский край: словарь языка памятников первой четверти XVII в.» (Казань, 2008), «Словарь русской народно-диалектной речи в Сибири XVII – первой половины XVIII в.» (Новосибирск, 1991) һ. б. Әлеге лексикографик ядкәрләрдә рус теленең сүзлек составы тарихын тулаем яңадан торгызу өчен җитәрлек материал тупланган. Моннан тыш, рус теленең тарихи сүзлекләре (И.И. Срезневский. «Материалы для словаря древнерусского языка»; «Словарь русского языка XI–XVII вв.», «Словарь русского языка XVIII века» һ. б.), терминологик сүзлекләр (Г.Е. Кочин. «Материалы для терминологического словаря древней России») ориентализмнарның хронологиясен, рус теленә үтеп керү юлларын һәм аларның алга таба үсешен ачыклауда мөһим лингвистик чыганак булып торалар.

Әзерләнә торган Көнчыгыш алынмалары сүзлеге өйрәнелә торган чыганакларда табылган барлык Көнчыгыш сүзләрен һәм алардан ясалган лексик берәмлекләрне тулысынча тасвирлауга юнәлтелгән лексикографик тикшеренү булып тора. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: табылган алынмаларның этимоннарын – алынма сүзнең эчке формаларын ачып бирү максаты белән баш сүздән соң этимологик белешмә бирелә.

**АРЧАКЪ (ОРЧАКЪ),** *м.* [тат. arčak ‘седельная лука’] Деревянный остов седла, седло.

Сүзлектә төрле дәрәҗәдә адаптацияләнгән Көнчыгыш алынмалары теркәлә. Барыннан да элек, фонетик, морфологик һәм семантик планда үзләштерелеп, XV–XVII гасырларда рус теле составына шактый тирән үтеп кергән саф алынма сүзләр билгеләнә: аманатъ, амбаръ, артель, аршинъ, атаманъ, бахматъ, бахрома, башмакъ, войлокъ, камка, кафтанъ, набатъ, серьги һ. б. Мондый лексика өйрәнелә торган чорда сүз ясалышы активлыгы белән аерылып тора. Мәсәлән, атаман – атаманишка, атаманов, атаманский, атаманство; кирпич – кирпичик, кирпичник, кирпичный, кирпищик һ. б.

Көнчыгыш лексикасының икенче өлешен рус теле законнары буенча төзелгән, әмма фонетик-график һәм морфологик вариативлыклары белән аерылып торган экзотик Көнчыгыш реалияләрен характерлаган сүзләр тәшкил итә. Экзотизмнар азсанлы мисалларда чагылыш таба: абызъ (абазъ, обузъ, обызъ) [тат., казах., тоб. abyz ‘ученый мулла’] ‘мөселман рухание (имам, мулла)’, амиръ һәм амира [гарәп. ‘amīr ‘хөкүмәт башлыгы, җитәкче’] ‘хөкүмәт башлыгы титулы (мөселман Шәрыгы илләрендә)’, куранъ һәм алкоранъ (олкаранъ, олкаренъ) [гарәп. al kur’ān] ‘мөселманнарның изге китабы, Коръән’ һ. б. Мондый стилистик төсмерләргә бай ориентализмнар тасвирланган күренешләрнең Көнчыгыш колоритын булдыру өчен кулланылалар, һәм аларның сүзьясалыш потенциалы чикләнгән.

Көнчыгыш сүзләренең өченче тибы текстларда үзләренең беренчел формаларында бирелгән һәм, реципиент телдә ассимиляциягә дучар ителмичә, үзләрен чит тел сүзе буларак саклап калган ясалма булмаган лексемаларны үз эченә ала. Мәсәлән: арпа [тат. arpa ‘ячмень’], раки [төр., кыпч. raky ‘водка’, гар. ‘araqy ‘финиковая водка’] ‘виноградное вино’, [тур. hälâl ‘дозволенный к применению’ (из араб. χälâl)] ‘дозволенное религиозным законом’ халялъ һ. б. Еш кына мондый чит тел сүзләренә аңлатмалар текстта бирелә. Мәсәлән: «<...> арпа, а по рускому ячмень, а иного хлеба нет» (Х. Котова, 32. 1624 г.). Әлеге төр алынмаларны сүзлеккә кертү – тикшерелә торган чыганакларда ачыкланган барлык шәркый чыгышлы лексемаларны (мөмкин кадәр) чагылдыру бурычы белән аңлатыла.

Сүзлек апеллятив лексика нигезендә төзелә, һәм анда кеше исемнәре кертелми. Сүзлеккә а) уртаклык мәгънәсендә кулланыла торган (чагыштыр: **БУХАРА,** ж. Сорт кожи); ә) тотрыклы терминологик сүзтезмәләр составына кергән (чагыштыр: **БУРМИНСКИЙ,** прил. [от тюрк. названия города Ормуз (Хормуз) – Hormuz, Hurmuz – у Персидского залива] Название жемчуга лучшего качества (подобного добываемому в Персидском заливе). ***Бурминское зерно*** – крупная, правильной формы жемчужина) географик атамалар (һәм алардан ясалган сүзләр) алына.

Сүзлектә шулай ук төрле кабиләләр һәм халыкларның исемнәре һәм алардан ясалган сүзләр китерелә:

**БОЛГАРЫ,** мн. [др.-тюрк. bulγar ‘смешанного происхождения, метис’ от bulγamak ‘мешать’] Народы, населяющие Поволжье и Прикамье.

XV–XVII гасырлар рус теленең төрле жанрларга караган истәлекләрендә безнең тарафтан табылган кайбер Көнчыгыш алынмалары һәм алардан ясалган сүзләр (инчи ‘скатный жемчуг’, дугень ‘торговая лавка’, киса ‘сумка, мешок, котомка’, курбан ‘жертва’, арбузец, казаченки, лальный ‘украшенный лалами’, мечетный, намазный, натесемничек һ. б.) «Словарь русского языка XI–XVII вв.» академик басмасында теркәлмәгән.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: XV–XVII гасырларда рус телендә Көнчыгыш алынмалары төрле сүзьясалыш активлыгы күрсәтәләр. Ясалма булмаган Көнчыгыш лексемалары белән беррәттән, рус сүзьясалышының продуктив модельләре нигезендә сүзьясалыш морфемаларын алган ясалма ориентализмнар да зур кызыксыну тудыра. Ир-атларны ‘кешене һөнәренә карап атау’ дигән гомумиләштерелгән мәгънә белән атаганда кулланылган -ник формантлы исемләшкән ясалма сүзләр шактый зур төркем тәшкил итә. Мондый дериватларның сүзьясагыч мәгънәсе – ‘затны эш-хәрәкәтнең объекты яисә эш коралы буенча атау’: алмазник ‘шлифовальщик драгоценных камней’, кармачник ‘тот, кто делает кармаки (удочки)’, кирпичник ‘тот, кто изготовляет кирпичи’, нагарник ‘тот, кто играет на нагаре’. -ник формантлы ясалмалар белән параллель рәвештә ир-ат җенесендәге затларның -чик-/-щик- кушымчалы бер тамырлы атамалары да бирелә: алмазник – алмазщик, кирпичник – кирпищик. Хезмәттә алар аерым сүзлек мәкаләләрендә урнаштырыла. Мәсәлән:

**КИРПИЧНИКЪ (КИРПИШНИКЪ),** м. Тот, кто изготовляет кирпичи. *Кудинко Микитин **кирпишник**.* Кн. п. Казани, 17. 1565–1568 гг.

**КИРПИЩИКЪ,** м. То же, что **кирпичникъ**. *Даточныхъ же людей въ камещики и въ **кирпищики** выбрано на Москвѣ другого сбору 20 ч. да третьего сбору 716 ч., итого 736 ч.* АМГ III, 434. 1661 г.

Сүзлектә шулай ук тасвирлау берәмлекләре булып ачыкланган дублет формалар да урын ала, аларда кечерәйтү мөнәсәбәтләрен нейтральләштерү нәтиҗәсе буларак ясаучы һәм ясалма сүзләр синонимиясе күзәтелә: брага – бражка, ферезь ‘вид кафтана’ – ферезец, серьги – сережки һ. б. Мәсәлән:

**СЕРЬГИ,** мн. [из чагат. isirγa, ysyrγa ‘ушные подвески’, туркм., караим., кыпч., карач., балк., тат., казах., кирг. syrγa ‘серьга’] Серьги. *Святые образы и кресты* [казанцы] *преливаху **серьги** и ожерелия и мониста, и наряжаху тафья на главы своя, украшахуся* <...> Каз. ист., 76. XVI в.

**СЕРЕЖКИ,** мн. То же, что **серьги**. ***Сережки*** *золотые одинцы с репьи.* Сл. Каз. кр. XVI, 215. 1568 г.

Ясалма исемнәр арасында субъектив бәяләү мәгънә төсмерләренә ия булган бер төркем сүзләр аерылып тора. Биредә -к һәм -ик, -ок, -чик-, -ец- суффикслары ярдәмендә ясалган лексемаларны мисал итеп китерергә мөмкин. Әлеге кушымчалар ясалма нигезләр белән бергә кечерәйтүне, кечкенә үлчәмнәрне белдерәләр: бирюзка, колымажка, стаканчик, сургучик, тазик, ярлычок һ. б. Кечерәйтү-кимсетү маркировкалы -ишко суффиксына беткән субъектив бәяләү мәгънә төсмерләренә ия булган лексемалар предметларны (кафтанишко), хайваннарны (лошадишко), абстракт төшенчәләрне (кабалаишко) атаганда еш очрыйлар. Сүзлектә Көнчыгыш алынмаларыннан ясалган исемнәрнең стилистик мәгънә төсмерләре тиешле стилистик һәм экспрессив бизәк белән билгеләнә, мәсәлән:

**БАЗАРИШКО,** с., уменьш.-уничиж. к **базаръ**.

**КУМГАНЕЦЪ,** м., уменьш. к **кумганъ**.

Көнчыгыш чыгышлы алынма нигезләрдән ясалган сыйфатлар өйрәнелә торган чор телендә шактый күпсанлы төркемне тәшкил итә. Чыганакларда алар, нигездә, -н(ый) суффиксы ярдәмендә ясалалар. Ул хәзерге рус телендә дә, XV–XVII гасырлар телендә дә продуктив кушымчаларның берсе санала. -н(ый) суффиксы һәм аның варианты -ин(ый) ярдәмендә алынма нигезләр базасында предметны төрле мөнәсәбәт төрләре нигезендә тасвирлый торган сыйфатлар ясала: 1) нәрсәдәндер ясалган: изумрудный, кумачный, сафьянный; 2) нәрсә өчендер билгеләнгән: вьючный, лошадиный һ. б. Шунысы кызык: «Көнчыгыш» тукымаларының төрле сортлары атамалары сыйфат ясау өчен нигез булып хезмәт иткән предмет мәгънәле исемнәр рәтендә иң күпсанлы лексик-тематик төркемгә әверелгән: зуфь ‘шерстяная ткань’ – зуфный, кармазинъ ‘тонкое сукно красного цвета’ – кармазинный, кисея ‘легкая прозрачная ткань’ – кисейный һ. б.

Тикшерелә торган чорда күбесенчә зат мәгънәсендәге алынма исемнәрдән, аерым очракларда -ский форманты ярдәмендә ясалган адъектив ясалма сүзләр дә продуктив: атаман – атаманский, боярин – боярский. Аерым очракларда хайван атамалары җәлеп ителә: обезьяна – обезьянский һ. б. -ский формантлы сыйфатлар ясалганда, этник атамалар да мотивлаштыручы исемнәр була ала: бесермен(ин) – бесерменский, магметан(ин) – магметанский. Сүзьясалыш вариантлары һәм ясалма адъективларның дублетлары сүзлектә аерым мәкаләләр белән бирелде. Мәсәлән:

**АМАНАТНЫЙ,** прил. к **аманатъ**. *Порозжее место что были Никона монаха кели а после* ***аманатнои*** *двор.* Сл. Смол. кр., 23. 1673 г.

**АМАНАТСКИЙ (АМАНАЦКИЙ),** прил. к **аманатъ**. *А что, государь, дано нам, холопем твоим, твово государеву товару*

<...> *и **аманацково** корму* <...> *– и нам, холопем твоим, тот твой государев товар и **аманацкий** корм велено розложити на два зимов(ь)я.* Сл. Мангаз. пам., 28. 1636 г.

Исемнән ясалган сыйфатлар аерым сүзлек мәкаләләрендә бирелде, чагыштыр:

**ЖЕМЧУЖНОЕ,** с. В знач. сущ. Украшение из жемчуга. И привезено съ собою.

Сыйфатлардан ясалган рәвешләр сыйфатка бирелгән сүзлек мәкаләсендә китерелде. Мәсәлән:

**БЕСКАБАЛЬНЫЙ,** прил. <...> **Бескабально,** нареч. Без документа (кабалы), подтверждающего акт сделки.

Ясалма фигыльләрне тасвирлаганда, сүзлектә *-ти (-тися)* инфинитив формасы нигез итеп алынды.

**ИСХАРЧИТИ.** Истратить, израсходовать.

Аерым очракларда эш-хәрәкәтнең беренчел фигыльгә карата күп тапкыр булуына күрсәтмә бирелә:

**БРАЖНИЧИВАТИ (БРАЖНЕЧЕВАТИ).** Многокр. к **бражничати**.

Көнчыгыш сүзләреннән ясалган фигыль номинацияләре аз. Алар – күбесенчә суффикслы ясалма сүзләр. Фигыльләр алынма исемнәрдән түбәндәге суффикслар ярдәмендә ясала: -и- (дуванити ‘делить добычу, жалованье’, караулити), -ова-/-ева- (кочевати, сеунчевати ‘сообщать радостную весть’), -ива- (кабаливати ‘обращать в кабального холопа’). Җансыз исемнәрнең нигезләреннән ясалган вербаль ясалмаларның күбесе терминологик мәгънәләрне үстерә: алмазити ‘шлифовать (о драгоценных камнях)’, бархатити ‘вышивать выпуклым рисунком’ һ. б. Мәсәлән, сүзлектә:

**ТЕСМИТИ.** Украшать тесьмой. *Два лука Едринские поѣзжены* <...> *У одного каймы лазоревы, тетива шолкова, **тесмена** розными шолки.* Оруж. Мих. Фед., 59. 1640 г.

Шулай итеп, Көнчыгыш сүзләре, XV–XVII гасырлар рус теле системасында ясагыч нигезләр сыйфатында кулланылып, рецептор телдә алынмаларның лексик-семантик үзләштерелеш дәрәҗәсенә һәм Көнчыгыш лексемаларының үз семантик, грамматик үзенчәлекләренә бәйле булган төрле сүзьясалыш мөмкинлекләренә ия. Алар белән мотивлашкан ясалма сүзләрне, иң беренче чиратта, кушымчалау ысулы белән ясалган отсубстантив дериватлар (исем, сыйфат һәм – сирәк кенә – фигыльләр) тәшкил итә. Шунысын әйтергә кирәк: басмага әзерләнгән лексикографик чыганакның тарихи-мәдәни потенциалы аның XV–XVII гасырларда рус лексикасының шактый зур катламын

тәшкил иткән Көнчыгыш фондының үсешен һәм яшәеш үзенчәлекләрен күрсәтү мөмкинлеге белән аңлатыла.

**Чыганаклар**

АМГ III – Акты Московского государства, изд. Акад. наук. Разрядный приказ. Московский стол / под ред. Д. Я. Самоквасова. СПб. 1901. Т. 3.

Арс. Сух. Проскинитарий – Проскинитарий Арсения Суханова // Православный палестинский сборник. СПб. 1889. Т. 7. Вып. 3(21).

Каз. ист. – Казанская история 1564–1565 гг./ подгот. текста, вступ. статья и примеч. Г.Н. Моисеевой; под ред. В.П. Адриановой-Перетц. М., Л.: Изд-во АН СССР 1954. 194 с.

Кн. п. Казани – Материалы по истории Татарской АССР: Писцовые книги города Казани 1565–68 гг. и 1648 г. Л.: Изд-во Акад. наук, 1932. XXV, 208 с. (Труды Историко-археографического института. Материалы по истории народов СССР / Акад. наук СССР).

Оруж. Мих. Фед. – Оружие и ратный доспех царя Михаила Феодоровича 1640 года // Савваитов П.И. Описание старинных царских утварей, одежд, оружия, ратных доспехов и конского прибора, в азбучном порядке расположенное. СПб. 1865.

Сл. Каз. кр. XVI – *Исламова Э. А., Галиуллин К. Р.* Казанский край: Словарь памятников XVI в. Казань. 2000. 286 с.

Сл. Мангаз. пам. – Словарь языка мангазейских памятников XVII – первой половины XVIII в. / сост. Н.А. Цомакион. Красноярск: КГПИ. 1971. 581 с.

Сл. Смол. кр. – Региональный исторический словарь второй половины XVII – XVIII в. (по памятникам письменности Смоленского края) / отв. ред. Е.Н. Борисова. Смоленск: Смоленский гос. пед. ун-т, 2000. 367 с.

Х. Котова – Хожение купца Федота Котова в Персию, 1624 г. / публикация Н.А. Кузнецовой. М.: Изд-во вост. лит., 1958. С. 25–60, сп. вт. пол. XVII в.

***Гыйләҗетдинова Гөлинә Хәйретдин кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге фәнни хезмәткәре*

***Гилязетдинова Гелиня Хайретдиновна,***
*доктор филологических наук, профессор, научный сотрудник отдела лексикографии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*ggilaz@mail.ru*

УДК 811.512.145’367

***Л.Г. Хәбибуллина***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘ ТӨРЛӘРЕ

В статье изучаются спаянные предложения в татарском языке, которые являются специфической особенностью синтаксической системы тюркских языков. Они подчиняются главному предложению при помощи формы своего сказуемого (падежных аффиксов, формы условного наклонения, формы деепричастий, послелогов и послеложных слов). В академической «Татарской грамматике» (1995) М.З. Закиев впервые в татарском языкознании употребил термин «спаянные предложения» для обозначения таких предложений. Тем не менее в лингвистической литературе подобные конструкции по традиции называются синтетическими предложениями. В данной статье также освещается вопрос их рассмотрения в других тюркских языках, уделяется внимание и суперспаянным предложениям.

**Ключевые слова:** спаянные предложения, подчинительная связь, тюркские языки, татарский язык.

The article studies subordinate clauses in the Tatar language, which are a specific feature of the syntactic system of Turkic languages. They are subordinated to the main clause using the form of their predicate (case affixes, the form of the conditional mood, the form of gerunds, postpositions and postpositional words). In the academic “Tatar Grammar” (1995) M.Z. Zakiev for the first time in Tatar linguistics calls such sentences welded. Nevertheless, in the linguistic literature such constructions are traditionally called synthetic sentences. This article also covers the issue of their consideration in other Turkic languages and pays attention to super-cohesive sentences.

**Keywords:** subordinate clauses, subordinating connection, Turkic languages, Tatar language.

Иялртүче чаралар ияручe җөмләнең хәбәре составында килгән синтетик бәйләүче чаралар булу төрки телләр, шул исәптән татар теле синтаксик структурасының специфик үзенчәлеген тәшкил итә. Мондый җөмләләр иярчен кисәкләргә охшаган була, араларында пауза булмау һәм баш җөмләнең аныклана торган сүзе белән мәҗбүри препозицион янәшә торулары сәбәпле аларны кушма җөмлә структурасыннан аерып алу авырлаша.

Төрки тел белемендә иярчен җөмлә төрләрен классификацияләү һәрвакыт бәхәсле. Кайбер телчеләр, гомумән, төрки телләрдә иярченле кушма җөмлә булуны кире кага [5]. Бу, кагыйдә буларак, синтетик иярченле кушма җөмләгә кагыла. Ә төрки телләрнең синтаксик системасында аналитик бәйләүче чаралы иярченле кушма җөмлә булу тюркологларда (М.З. Зәкиев, Н.З. Гаджиева, Л.А. Покровская, А.А. Юлдашев һ. б.) шик тудырмый. Татар телендә аналитик конструкцияләр С.М. Ибраһимов тарафыннан җентекле өйрәнелгән.

Мәгълүм булганча, 1982 елда лингвист В.Г. Адмони синтетик җөмләләрне *спаянный* дип атарга тәкъдим итә [1: 36]. Галимнең бу фикерен дәвам итеп, академик М.З. Зәкиев төрки телләрдә иярченле кушма җөмлә дип аналитик кушма җөмләләрне генә, ә синтетик кушма җөмләләрне ябешкәкле яки берекмәле кушма җөмлә дип атауны хуп күрә [8: 411–412].

Шул рәвешле, М.З. Зәкиев В.Г. Адмони тәкъдим иткән кушма җөмлә парадигмасын төрки телләр өчен кулай дип саный: паратаксис (тезмә кушма җөмлә), гипотаксис (иярченле кушма җөмлә), гипертаксис (*сложноспаянное предложение*) [7: 29].

Төрки телләрдә гипертаксиска караган җөмләләр (*сложноспаянное предложение*), кагыйдә буларак, иярченле кушма җөмлә составында карала, мәсәлән башкорт [17], казах [16], кыргыз [12], чуваш [11] һ. б. телләрдә. А.М. Саидов мондый төр җөмләләрне комык теле материалында анализлый. Галим билгеләгәнчә, комык тел белемендә мондый конструкцияләр иярченле кушма җөмлә яки гади җөмлә буларак өйрәнелә. Әмма «алар кушма һәм гади җөмләләр арасындагы позициядә тора, *«сложноспаянный»* дигән термин грамматик яктан әлеге конструкцияләрнең асылын төгәлрәк чагылдыра» [15: 17].

Кайбер төрки телләрдә, мәсәлән кыргыз телендә, иярченле кушма җөмлә компонентлары арасында өч бәйләнеш төре аерыла: аналитик, синтетик, синтетик-аналитик [13: 13].

Н.Н. Ефремов якут телендә иярченле кушма җөмләләрне өйрәнеп, аларның синтетик, аналитик-синтетик, аналитик типлары булуны ассызыклый [6].

Татар телендә дә иярченле кушма җөмлә компонентлары арасында бер үк вакытта синтетик бәйләүче чара да, аналитик бәйләүче чара да кулланыла ала. Шарт фигыль формасы белән бергә *әгәр* теркәгече килү аеруча еш очрый. Мәсәлән: *Әгәр ир акыллы булса, хатын күндәм була* (Мәкаль). Әмма синтетик чара белән аналитик чараның параллель кулланылуы стилистик төсмер функциясен генә үти. Әйтик, бу очракта *әгәр* теркәгечен төшереп калдыру җөмлә структурасын бозмый, димәк, шарт фигыль кушымчасы (синтетик чара) – төп бәйләүче чара, җөмлә синтетик була. Шуңа күрә татар телендә синтетик-аналитик (аналитик-синтетик) җөмлә дип аерып каралмый.

Аналитик иярченле кушма җөмләләрдә бәйләүче чара хәбәр формасына кагылмый, чөнки хәбәрдән тыш урнаша. Ә *спаянный* дип аталган җөмләләрне баш җөмләгә бәйләү өчен, иярчен кисәкләрне бәйләүче шул ук чаралар кулланыла, әлеге үзенчәлек аларны җөмләнең иярчен кисәкләре белән якынайта, мондый җөмләләр кушма җөмләне тәмамлап килә алмый. Аларны баш җөмләгә ияртү өчен хәбәр составына кергән һәм аның формасын тәшкил итә торган аффикслар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, янәшә тору (бу очракта хәбәр формасы белән берлектә) кулланыла. Мәсәлән:

– шарт фигыль формасы: *Кышын кар сора**саң**, кар да бирмәс* (Әйтем); *Авыр**саң**, имче күбәер* (Мәкаль);

– хәл фигыль формалары: *Җәйнең матур кояшлы көннәре бе**теп**, бөтен дөньяны болыт вә караңгылык каплады* (Г. Ибраһимов. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»); *Сугыш бет**кәч**, батыр күбәя* (Мәкаль)*; Бер аягын атла**ганчы**, икенчесен эт ашый* (Әйтем); *Атың чык**канчы**, җаның чыксын* (Мәкаль);

– килеш кушымчалары, кайбер башка сүз бәйләүче кушымчалар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр: *Ояты бар**ның** намусы бар; Ат эшләгән**гә**, эт әлсери; Малың бар**да** бар да дус; Ике карчыга талаш**канда**, бер мендәрлек йон чыга* (Мәкаль); *Ир кичмәс**лек** елга юк* (Мәкаль);

– мәҗбүри янәшә тору һәм ияртүче сүздән пауза белән аерылмау. Мондый конструкцияләр баш җөмләдәге кайсыдыр бер сүзнең атрибуты позициясендә була. Аларның хәбәрләре сыйфат фигыль, *бар, юк* хәбәрлек сүзләре, кайбер рәвешләр һәм сыйфатлар белән белдерелә. Мәсәлән: *Артында йөз эт һауламаган бүре бүре буламыни?* (Мәкаль).

XX гасыр башы татар грамматикаларында ук, әйтик, Г. Ибраһимовның «Татар нәхүе»ндә (1919) иярчен җөмлә һәм ияртүле җөмлә аерыла.

Тел галимнәре Җ. Вәлиди «Татар теленең грамматикасы» (1919) хезмәтендә һәм Г. Алпаров «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926) монографиясендә *сложноспаянный* җөмләгә туры килгән җөмләне – ияртүле (соңрак – иярченле) кушма җөмлә, ә иярченле кушма җөмләне бәйләүле кушма җөмлә дип атыйлар.

Әмма татар тел белемендә һәр ике төр җөмләне дә иярчен дип атау традициягә кергән: синтетик иярченле кушма җөмлә һәм аналитик иярченле кушма җөмлә.

1983 елда «Советская тюркология» журналында М. З. Зәкиев иярченле кушма җөмләне – тагылмалы кушма (иярчен җөмләне – тагылма җөмлә), *сложноспаянный* җөмлә – иярченле кушма (*спаянное* – иярчен җөмлә), дип атарга тәкъдим итә [7: 36].

Әмма әлеге төшенчәләр татар теленең лингвистик терминологиясенә кермәгән, гомумән, *сложноспаянное предложение* һәм *спаянное предложение* терминнарының татар теленә төгәл һәм гомум кабул ителгән тәрҗемәсе юк.

Мәсәлән, «Лингвистик терминнарның русча-татарча аңлатмалы сүзлеге»ндә *сложноспаянные предложения* термины синтетик кушма җөмләләр дип тәрҗемә ителә [14: 164], ә *спаянное предложение* атамасы берекмә җөмлә дип бирелә [14: 172].

Рус телендәге «Татар грамматикасы» (III том, Синтаксис, 1995) белән аның татар телендәге соңгы яңа басмасында (III том, Синтаксис, 2017) кушма җөмлә бирелешендә бик зур аермалыклар бар.

Рус телендә басылган академик «Татар грамматикасы»нда (III т., Синтаксис, 1995) *сложноспаянные предложения* дип аерып чыгарыла, «мондый җөмләләрдә ияртүле мөнәсәбәт ияреп килгән

җөмләнең хәбәре формасын тәшкил итүче чаралар ярдәмендә белдерелә» [8: 418]. Академик М.З. Зәкиев билгеләгәнчә, *спаянный* сүзе урынына *синтетик* сүзен кулланып була, ул башка шундый типтагы *синтетик чаралар, синтетик бәйләнеш* кебек терминнар ясау өчен кулайрак та [8: 424–425].

«Татар грамматикасы»ның татар телендәге яңа басмасында (III т., Синтаксис, 2017) иярченле кушма җөмләләр синтетик һәм аналитик төрләргә бүленә, дип бирелә. М.З. Зәкиев билгеләгәнчә, рус телендәге «Татар грамматикасы»нда *спаянное предложение* дип аталган синтетик иярчен җөмлә *ябешкәк* яки *берекмә җөмлә* дип тәрҗемә ителергә тиеш иде. Әмма татар тел белемендә мондый термин һәм кушма җөмләне болай төркемләү кабул ителмәгән. Шулай итеп, М.З. Зәкиев, бер яктан, әлеге җөмләләрнең синтетик иярчен җөмлә булуын кире какмый [18: 339].

Л.К. Бәйрәмова һәм Ф.С. Сафиуллинаның «Рус һәм татар телләренең чагыштырма синтаксисы» («Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков», 1989) хезмәтендә В.Г. Адмониның синтетик конструкцияләргә карата фикерләре, аларның атамасын үзгәртү тәкъдиме турында язылa. Әлеге тәкъдимгә М.З. Зәкиевнең карашы яктыртыла. Әмма хезмәт авторларының бу мәсьәләгә карата үз позициясе, комментарийлары бирелми [3: 139–140].

Әлеге «Рус һәм татар телләренең чагыштырма синтаксисы»нда исә иярченле кушма җөмлә традицион рәвештә аналитик һәм синтетик төрләргә бүлеп бирелә.

Безнең карашка, төрки телләрнең синтаксик төзелешенең үзенчәлеге булган, баш җөмләгә хәбәре формасын тәшкил итүче чара ярдәмендә ияртүле бәйләнеш белән береккән җөмләләрне, рус теле белән чагыштырма тикшеренүләрне җиңеләйтү өчен генә синтетик иярчен җөмлә дип атау максатка ярашлы түгел.

Моннан тыш, татар телендә баш өлешнең (баш җөмлә дип атап булмый, чөнки җөмләнең ике хәбәрлек үзәге булса да, алар аерым-аерым мәгънә белдерми) субъекты позициясендә килгән иярчен җөмләләр дә очрый, рус телендә алар *суперспаянные предложения* (татар телендә термин юк) дип бирелә. Мондый конструкцияләрдә баш өлеш береккән өлештән башка җөмлә дип санала алмый, бәйләүче чара – мәҗбүри янәшә тору һәм ияртүче сүздән пауза белән аерылмау булганлыктан, кушма җөмлә компонентларының чикләрен билгеләү кыенлык тудыра. Мәсәлән: *Һәр ялтыраган алтын түгел* (Мәкаль).

Бу очракта кушма җөмлә компонентлары аерым, бер-берсеннән башка мәгънә белдерми. *Һәр ялтыраган* дигән өлеш формаль яктан үз предикатив үзәге булганга гына җөмлә дип санала: *һәр* – ия, *ялтыраган* – хәбәр. Моннан тыш, *һәр ялтыраган* өлеше үзе субъект позициясендә килә, баш өлешнең хәбәре (*алтын түгел)* иядән башка үзе генә тәмамланган уйны белдерми.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, төрки телләрдә аналитик ияртүле бәйләнешле конструкцияләрне генә иярченле кушма җөмлә дип атау дөресрәк. Кабул ителгән терминология буенча синтетик иярчен җөмлә дип өйрәнелгән конструкцияләрнең татарча атамасы төгәлләштерүне таләп итә. М.З. Зәкиев «Татар грамматикасы»нда вариант буларак телгә алган *берекмә җөмлә* термины бу очракта уңышлырак дип саныйбыз.

**Әдәбият**

1. *Адмони В.Г.* Сложноспаянное предложение в тюркских языках // Советская тюркология. 1982. № 3. С. 30–36.

2. *Алпаров Г.Х.* Шәкли нигездә татар грамматикасы (Телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәҗрибә). Казан: Татгосиздат, 1926. 164 б.

3. *Байрамова Л.К., Сафиуллина Ф.С.* Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1989. 197 с.

4. *Вәлиди Җ.* Татар теленең грамматикасы. Казан: Миллият, 1919. 175 б.

5. *Дубровина М.Э.* Отсутствие тюркских сложноподчиненных предложений как следствие внутреннего устройства агглютинативных языков // Вестник Российского университета дружбы народов. Серия: Теория языка. Семиотика. Семантика. 2017. Т. 8. № 3. С. 563–570.

6. *Ефремов Н.Н.* Аналитические сложноподчиненные предложения в якутском языке (в сопоставлении с хакасским языком) // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2013. № 11 (29). Часть 1. С. 66–69.

7. *Закиев М.З.* Актуальные проблемы сложных предложений в тюркских языках // Советская тюркология. 1983. № 3. С. 29–38.

8. *Закиев М.З.* Татарская грамматика. Т. III. Синтаксис. Казань, 1995. 576 с.

9. *Ибраһимов Г.* Татар нәхүе. Казан: Өмет, 1919. 52 б.

10. *Ибраһимов С.М.* Татар телендә аналитик төзелмәләр. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1964. 134 б.

11. *Иванова А.М.* Послелоги как средство связи частей сложноподчиненного предложения в чувашском языке // Вестник Томского государственного педагогического университета (Tomsk State Pedagogical University Bulletin). 2011. Вып. 9 (111). С. 168–172.

12. *Козуев Д.И.* Структурно-семантическое сопоставление английских и кыргызских бессоюзных сложных предложений // Вестник КРСУ. 2019. Т. 19. № 6. С. 59–67.

13. *Мусаев С.Ж.* Основные способы связи компонентов сложноподчиненного предложения в кыргызском языке // Turkologia. 2019. № 1 (93). С. 11–25.

14. Русско-татарский толковый словарь лингвистических терминов / под ред. Ф.И. Тагировой и Ф.Ф. Гаффаровой. Казань: ИЯЛИ, 2016. 248 с.

15. *Саидов А.М.* Предикативные слова как сказуемые спаянных частей сложноспаянных предложений в кумыкском языке // Вестник Института языка, литературы и искусства им. Г. Цадасы ДФИЦ РАН. 2021. № 25. С. 16–18.

16. *Самситова Л.Х., Сагынбек И.Ж.* История изучения сложноподчиненных предложений в казахском языке // Проблемы востоковедения. 2024. № 4 (106). С. 91–98.

17. *Самситова Л.Х., Сагынбек И.Ж.* Теоретические основы изучения сложноподчиненного предложения в башкирском языке // Проблемы востоковедения. 2022. № 4 (98). С. 40–46.

18. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һәм авт. М.З. Зәкиев. Казан: ТӘһСИ, 2017. Т. III. 536 б.

***Хәбибуллина Лениза Газинур кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Хабибуллина Лениза Газинуровна,***
*доктор филологических наук, старший научный сотрудник отдела ареальной лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*valievalg@mail.ru*

УДК УДК 81'354

***Ю. Хисияма***

# СОҢГЫ ИҖЕКТӘ [И] СУЗЫГЫ БУЛГАН ГАРӘП-ФАРСЫ АЛЫНМАЛАРЫНДА СИНГАРМОНИЗМ КҮРЕНЕШЕ:

## Татар теленең язма корпусы нигезендә тикшеренүләр

Татарский язык подчиняется закону сингармонизма, который в некоторых заимствованных словах иногда нарушается. В данном исследовании мы использовали Письменный корпус татарского языка для изучения колебаний, наблюдаемых в аффиксальных гласных арабо-персидских заимствований, имеющих [и] в конечном слоге, и выяснили следующее: 1) слова с гласным заднего ряда в предпоследнем слоге часто имеют гласные заднего ряда в аффиксах, но когда конечный согласный звук слова является передним согласным [л], аффиксы часто имеют гласные переднего ряда; 2) слова с гласным переднего ряда в предпоследнем слоге часто имеют гласные переднего ряда и в аффиксах, но когда конечный согласный звук слова является задним согласным [к] или [х], суффиксы часто имеют гласные заднего ряда. Основываясь на результатах исследования, мы утверждаем, что в данном типе заимствований гласный предпоследнего слога и конечный согласный слова участвуют в сингармонизме, в то время как гласный конечного слога [и] участвует в нем в меньшей степени.

**Ключевые слова**: татарский язык, закон сингармонизма, заимствование, орфография, корпус.

The Tatar language obeys the law of synharmonism, which is sometimes violated in some borrowed words. In this work we used The written corpus of the Tatar language to study the fluctuations seen in the affixal vowels of Arabic-Persian loanwords that have [и] (i) in the final syllable and found the following: 1) words with a back vowel in the second to the last syllable often have back vowels in their suffixes but when the final consonant is the front consonant [л] (l), suffixes often have front vowels; 2) words with a front vowel in the second to the last syllable often have front vowels in their suffixes but when the final consonant is the back consonant [к] (q) or x (x), suffixes often have back vowels. Based on the survey results we claim that in this type of loanwords the second to the last syllable vowel and word-final consonant are involved in vowel harmony, while the final syllable vowel [и] (i) is less involved in it.

**Keywords:** Tatar language, vowel harmony, loanword, orthography, corpus.

Сөйләм агышында янәшә урнашкан авазлар бер-берсе тәэсирендә төрле үзгәрешләр кичерергә мөмкин. Татар телендә шундый үзгәрешләрнең берсе – сингармонизм. Ул – сузыклар ассимиляциясенең бер төре. «Сингармонизм, яки сузыклар гармониясе – барлык төрки телләр өчен дә диярлек (чуваш һәм үзбәк телләреннән башка) характерлы билге» [1: 31]. Сингармонизмның ике төре бар – рәт гармониясе һәм ирен гармониясе. Язуда бары рәт гармониясе генә чагылыш

таба. Рәт гармониясе булганда, сүздә я алгы рәт (нечкә) сузыклары [ә], [э], [ө], [ү], [и], я арткы рәт (калын) сузыклары [а], [ы], [о], [у] гына кулланыла: *кеше-ләр-гә, атлы-лар-га*.

Кайбер алынма сүзләр бу законга буйсынмый [1: 32; 6: 903; 5: 11]. Мәсәлән, соңгы иҗектә [и] сузыгы булган гарәп-фарсы алынмаларына калын кушымчалар ялгана ала: *шаһит-лар*. Бу турыда тәфсилләп язылган хезмәтләр юк диярлек. Инглиз телендә язылган татар теле грамматикасында кайбер гарәп-фарсы алынмаларына, соңгы иҗектә нечкә сузык булса да, калын кушымчалар ялгана (боларның күбесе беренче иҗектә – [а], икенче иҗектә [и] сузыгы булган ике иҗекле алынмалар) дип аңлатыла: *тарих-ның* [5: 11].

Ләкин, язма материалларда күзәтелгәнчә, әлеге алынмаларга калын кушымчалар да, нечкә кушымчалар да ялгана ала: *шаһит-лар* ~ *шаһит-ләр* [3]. Өч һәм күбрәк иҗекле сүзләрдә дә шуны ук күзәтәбез: *Мәрҗани-га* ~ *Мәрҗани-гә* [3]. Гарәп-фарсы алынмалары тарихи-традицион принципка нигезләнеп язылса да, кушымчаның язылышы күпмедер дәрәҗәдә әйтелешне чагылдыра. Бу мәкаләдә без соңгы иҗектә [и] сузыгы булган гарәп-фарсы алынмаларында сингармонизм күренешләрен Татар теленең язма корпусы нигезендә, анда теркәлгән материалларны кулланып тикшердек.

Соңгы иҗектә [и] сузыгы булган гарәп-фарсы алынмаларын җыйганда, «Татар телендәге гарәп-фарсы алынмалары» сайтыннан [2] файдаландык. Кеше исемнәрен дә исәпкә алдык. Дүрт яки күбрәк иҗекле сүзләр бик сирәк булганга, ике яки өч иҗекле сүзләр тикшерелде.

Хәзерге вакытта Татар теленең язма корпусы 500 миллионнан артык сүзне колачлый, төрле сүзформаларның саны 5 миллион тирәсе. Теркәлгән текстлар, нигездә, өч стильгә – публицистика (аларның күләме ≈ 60%), сәнгатьле чәчмә әдәбият (≈ 35%) һәм гуманитар юнәлештәге фәнни стильгә (≈ 5%) карый [3].

Шушы корпустан файдаланып, соңгы иҗектә [и] сузыгы булган гарәп-фарсы алынмаларында сингармонизм күренешләрен түбәндәге адымнар белән тикшердек. Башта, беренче таблицаның сул баганасында күрсәтелгәнчә, сүз һәм тамгаларны җыеп (сүз + кушымча + йолдызчык), «Табу!» төймәсенә бастык (1 нче рәсем). Беренче таблицаның сул баганасында «шаһит» сүзен тикшерү мисалга алынды. Йолдызчык – 1 яки аннан күбрәк сүз формасы була алуны күрсәтә. Шуңа күрә, «шаһитлар*» дип кертеп, «Табу!» төймәсенә баскач, «шаһитлар, шаһитлары, шаһитларыннан» кебек сүз формалары табыла (2 нче таблица).

Искәрмә: *и* хәрефенә беткән сүзләргә ялганган *е* хәрефенең калын сузыкны [йы] яки нечкә сузыкны [йэ] белдерүе билгеле булмагач, *и* хәрефенә беткән сүзләрнең 1 нче таблицаның икенче рәтендәге формалары тикшерелмәде. Мәсәлән, *рухание* формасының [руханийы] яки [руханийэ] дип әйтелүе билгеле түгел.




1 нче рәсем. Корпус экраны




2 нче рәсем. Корпус экраны

1 нче таблица

Эзләү ысулы

| Сүзләр һәм тамгалар | Табылачак сүз формалары | Табылган сүзләр |
|---|---|---|
| шаһитлар*<br>шаһитләр* | исем + күплек (+ тартым)<br>(+ килеш, һ. б.) | шаһитләреннән,<br>шаһитлар һ. б. |
| шаһиты*<br>шаһите* | исем + тартым (+ килеш, һ. б.) | шаһитыбыз,<br>шаһитеңә һ. б. |
| шаһитны*<br>шаһитне* | исем + төшем яки иялек килеше<br>исем + -ныкы/-неке | шаһитны,<br>шаһитнең һ. б. |
| шаһитта*<br>шаһиттә* | исем + урын яки чыгыш килеше<br>исем + -дай/-дәй/-тай/-тәй | шаһитта,<br>шаһиттән һ. б. |
| шаһитка<br>шаһиткә | исем + юнәлеш килеше | шаһитка,<br>шаһиткә һ. б. |

Алдагы этапта корпустан табылган мисалларның санын, аларга калын һәм нечкә кушымча ялгануга карап, ике төркемгә бүлеп исәпләдек. 2 нче таблицада «шаһит» сүзен тикшерү нәтиҗәсе күрсәтелгән. Күренгәнчә, «шаһит» сүзенә калын кушымчалар күбрәк ялгана (70,3%).

2 нче таблица

Исәпләү үрнәге

| | Сүзләр һәм корпуста табылган мисаллар саны | | | | | Барлыгы (нисбәте) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Калын кушымча | шаһитлар*<br>5,862 | шаһиты*<br>4,170 | шаһитны*<br>153 | шаһитта*<br>68 | шаһитка<br>65 | 10,318<br>(70,3%) |
| Нечкә кушымча | шаһитләр*<br>3,148 | шаһите*<br>1,073 | шаһитне*<br>80 | шаһиттә*<br>16 | шаһиткә<br>33 | 4,350<br>(29,7%) |

Ике иҗекле сүзләргә күз салыйк. Беренче иҗектә калын сузык булган сүзләрне тикшерү нәтиҗәләре – 3 нче таблицада, беренче иҗектә нечкә сузык булган сүзләрне тикшерү нәтиҗәләре 4 нче таблицада күрсәтелде (һәр таблицада табылган мисалларның беренче унлыгы урнаштырылды).

3 нче таблица

Беренче иҗектә калын сузык хәрефе булган ике иҗекле сүзләр

| | Кушымча | | Нисбәте (калын) |
|---|---|---|---|
| | калын | нечкә | |
| тарих | 240,413 | 161 | 99,9 |
| табиб | 87,350 | 1,005 | 98,9 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| тасвир | 2,590 | 34 | 98,7 |
| шаһит | 10,318 | 4,350 | 70,3 |
| залим | 296 | 1496 | 16,5 |
| мохит | 3,293 | 30,236 | 9,8 |
| Камил | 162 | 3,374 | 4,8 |
| Наил | 44 | 2,608 | 1,7 |
| хаким | 36 | 7,179 | 0,5 |
| галим | 173 | 115,112 | 0,2 |

4 нче таблица

Беренче иҗектә нечкә сузык булган ике иҗекле сүзләр

| | кушымча | | Нисбәте (калын) |
|---|---|---|---|
| | калын | нечкә | |
| Тәүфикъ | 285 | 5 | 98,3 |
| мәшрикъ | 160 | 53 | 75,1 |
| тәсбих | 415 | 541 | 43,4 |
| Мәсих | 29 | 1032 | 2,7 |
| Фәнис | 2 | 1911 | 0,1 |
| дәлил | 12 | 15,733 | 0,1 |
| тәэсир | 11 | 31,055 | 0,0 |
| хәдис | 3 | 12,762 | 0,0 |
| тәкъдим | 4 | 57,337 | 0,0 |
| тәртип | 5 | 103,524 | 0,0 |

Таблицалардан аңлашылганча, 1) беренче иҗектә калын сузык булган сүзләргә, нигездә, калын кушымчалар күбрәк ялгана: *та*-*биб-**лар***. Ләкин сүз азагында *л* яки *м* хәрефе булган очракта, нечкә кушымчалар күбрәк ялгана: *Наи**л**-**гә**, гали**м**-**нәр***; 2) беренче иҗектә нечкә сузык булган сүзләргә, нигездә, нечкә кушымчалар күбрәк ялгана: *тәртип-**ләр***. Ләкин сүз азагында [к] яки [х] тартыклары булган очракта, калын кушымчалар күбрәк ялгана: *Тәүфи**къ**-**лар***, *тәсби**х**-**лар***.

Бу тенденцияләрдән чыгармалар да бар. Мәсәлән, *Һашим* сүзе *м* хәрефенә беткән булса да, аңа күбрәк калын кушымчалар ялгана (99,8%).

Өч иҗекле сүзләргә күз салыйк. Тикшерү нәтиҗәләре 5 нче таблицада күрсәтелде.

5 нче таблица

Өч иҗекле сүзләр

| | Кушымча | | Нисбәте (калын) |
|---|---|---|---|
| | калын | нечкә | |
| монафикъ | 1,278 | 0 | 100,0 |
| рухани | 7,225 | 123 | 98,3 |
| Насыйри | 2,923 | 101 | 96,7 |
| Максуди | 2,124 | 142 | 93,7 |
| Ибраһим | 2,512 | 209 | 92,3 |
| Газраил | 147 | 856 | 14,7 |
| Фәләстин | 50 | 447 | 10,1 |
| Фидаил | 25 | 287 | 8,0 |
| Мәрҗани | 444 | 5,189 | 7,9 |
| Фәхретдин | 67 | 2,138 | 3,0 |
| мәгариф | 263 | 30,640 | 0,9 |
| мөгаллим | 6 | 19,266 | 0,0 |
| гаскәри | 0 | 2,700 | 0,0 |
| мөхәррир | 0 | 30,506 | 0,0 |

Таблицадан аңлашылганча, 1) соңгыдан алдагы иҗектә калын сузык булган сүзләргә, нигездә, калын кушымчалар күбрәк ялгана: *Насы**йри-ны**ң*. Ләкин сүз азагында [л] тартыгы булган очракта, нечкә кушымчалар күбрәк ялгана: *Газраи**л-не***; 2) соңгыдан алдагы иҗектә нечкә сузык хәрефе булган сүзләргә, нигездә, нечкә кушымчалар күбрәк ялгана: *гаскәри-ләр*.

Шуны искәртеп үтәргә кирәк: *мәгариф* һәм *мөгаллим* сүзләренең икенче иҗеге *га* дип язылса да, [ғә] дип әйтелә. *Мәрҗани* сүзенең икенче иҗеге *җа* дип язылса да күп очракта *җә* дип әйтелә. Шуңа күрә, аларга күбрәк нечкә кушымчалар ялгана.

Тикшеренү нәтиҗәләренә һәм саф татар сүзләрендә [и] сузыгының нигездә беренче иҗектә генә әйтелүенә таянып [1: 24; 5: 10], без түбәндәге нәтиҗәгә киләбез: 1) әлеге алынмаларның соңгы иҗегендәге [и] сузыгы сүзгә кушымча ялгануда артык зур роль уйнамый; 2) соңгыдан алдагы иҗектәге сузык һәм сүз азагындагы тартык тиешле кушымча сайлауга тәэсир итә.

Соңгыдан алдагы иҗектә калын сузык булган сүзләргә, нигездә, калын кушымчалар күбрәк ялгану, һәм соңгыдан алдагы иҗектә нечкә сузык булган сүзләргә, нигездә, нечкә кушымчалар күбрәк ялгану әлеге алынмаларда соңгыдан алдагы иҗектәге сузыкның да, соңгы иҗектәге [и] сузыгының да ялганасы кушымчаны сайлауда мөһим булуын аңлата.

Соңгыдан алдагы иҗектә калын сузык булган сүзләрдә сүз азагындагы тартык [л] (ике иҗекле сүзләрдә [л] яки [м]) булган очракта, нечкә кушымчалар күбрәк ялгану әлеге алынмаларда [и] сузыгыннан һәм авызның алгы өлешендә әйтелә торган сонор тартыктан торган соңгы иҗекнең сингармонизмда «нечкә иҗек» булып эшләвен, ягъни сүз азагындагы тартыкның да сингармонизмда катнашуын аңлата. Аеруча [л'] авазының палаталь варианты сингармонизмда зур роль уйный.

Соңгыдан алдагы иҗектә нечкә сузык булган сүзләрдә, сүз азагындагы тартык [к] яки [х] булган очракта, калын кушымчалар күбрәк ялгану әлеге алынмаларда авызның арткы өлешендә әйтелә торган тартык тәэсирендә соңгы иҗекнең сингармонизмда «калын иҗек» булып эшләвен, ягъни монысы да сүз азагындагы тартыкның сингармонизмда катнашуын аңлата.

Яңа (татарчалашмаган) рус алынмаларында да охшаш хәлләр күзәтелүе билгеле. Аларда да [и] сузыгы сингармонизмда нейтраль, һәм, нигездә, аларга калын кушымчалар ялгана: *илчелек советн**и**г-**ы*** [6: 904], *виски, суши* һ. б. Сүз азагындагы тартыкның сингармонизмда катнашуы да күзәтелә. Мәсәлән, йомшак тартыкка беткән сүзгә нечкә кушымчалар ялгана: *секрета**рь**-ләр, апре**ль**-дә* [6: 905; 5: 12].

Рус һәм башка телләрдән кергән иске (татарчалашкан) алынмаларда да, соңгы иҗектәге [и] сузыгының сүзгә кушымча ялгануга тәэсир итмәвен күрергә була. Мәсәлән, рус теленнән кергән *фатир* (< рус. *квартира*) һәм фин-угор телләреннән кергән *поши* сүзләренә калын кушымчалар ялгана (фатир: 100%, поши: 99,7%). Әлбәттә, әлеге сүзләрнең калын әйтелүен дә истән чыгармаска кирәк.

Бу тикшеренүдә без соңгы иҗектә [и] сузыгы булган гарәп-фарсы алынмаларындагы сингармонизм күренешләрен корпуста теркәлгән язма материаллардан файдаланып, күплек сан, тартым һәм килеш кушымчаларының калын яки нечкә булуына карап тикшердек.

Тикшеренү нәтиҗәләре шуны дәлилләде: 1) алынмаларның соңгы иҗегендәге [и] сузыгы сүзгә кушымчалар ялгануда артык зур роль уйнамый; 2) соңгыдан алдагы иҗектәге сузык һәм сүз азагындагы тартык исә кушымчаның калын яки нечкә варианты сайлануга тәэсир итә.

Киләчәктә башка кушымчаларны да исәпкә алып, әлеге күренешләрне, язма материаллар белән генә чикләнмичә, тулырак тикшерергә кирәк.

**Әдәбият**

1. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Ф.М. Хисамова. Тулыл. 2 нче басма. Казан: ТӘҺСИ, 2015. Т I. 512 б.

2. Татар телендәге гарәп-фарсы алынмалары. URL: https://g-farsi.belem.ru/index.html (мөрәҗәгать итү көне: 05.04.2025)

3. Татар теленең язма корпусы. URL: https://search.corpus.tatar/tt (мөрәҗәгать итү көне: 26.07.2024)

4. Татар энциклопедиясе. URL: https://tatarica.org/tat/razdely/narody/tatary/tatarskij-yazyk/grammatika/singarmonizm (мөрәҗәгать итү көне: 26.07.2024)

5. *Burbiel, Gustav*. Tatar grammar. A Grammar of the Contemporary Tatar Literary Language. Stockholm/Moscow: Institute for Bible Translation, 2018. 901 p.

6. *Comrie, Bernard*. Tatar phonology. Alan S. Kaye (ed.) Phonologies of Asia and Africa 2. Winona Lake: Eisenbrauns. 1997. P. 899–911.

*Исследование проводилось при поддержке гранта научных исследований The Japan Society for the Promotion of Science (JSPS) 23KJ1014*

*Бу тикшеренү the Japan Society for the Promotion of Science (JSPS) 23KJ1014 фәнни тикшеренүләр гранты ярдәмендә алып барылды*

*Рәхмәт сүзләре*

*Татар һәм рус телләрендәге текстларны – Казан федераль университеты доценты Рамил Йөзмөхәммәтов, инглиз һәм рус телләрендәгесен Зарина Фәйзиева редакцияләде. Аларга зур рәхмәтемне белдерәм.*

***Хисияма Юто,***
*Ниигата университеты ассистенты*

***Хисияма Юто,***
*ассистент Ниигатского университета*
*boltwatts@gmail.com*

УДК 811.512.145

***А.И. Идиятуллина,***
***А.Я. Хөсәинова***

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ МЕТЕОРОЛОГИК ЛЕКСИКАСЫН ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫ

Изучение метеорологических названий в татарском языке представляет собой важное направление лексикологических исследований, позволяющее проследить не только историю развития языка, но и особенности взаимодействия человека с окружающей средой, отраженные в языковой картине мира. Метеонимы, будучи неотъемлемой частью повседневной жизни народа, аккумулируют в себе богатый пласт знаний о природных явлениях, связанных с климатическими условиями региона и традиционными формами хозяйственной деятельности. Несмотря на значимость данной лексической группы, история ее изучения в татарском языкознании до сих пор не получила должного освещения. Настоящая статья ставит своей целью проследить основные исследования метеорологических названий в татарском языке. В статье рассмотрены труды ученых, внесших вклад в изучение данной проблематики, проанализированы методы и подходы к анализу метеорологической лексики, а также обозначены перспективные направления дальнейших исследований.

**Ключевые слова**: метеорологическая лексика, диалектология, диалектная лексика, метеонимы, татарский язык.

The study of meteorological names in the Tatar language is an important area of lexicological research, which allows us to trace not only the history of language development, but also the features of human interaction with the environment, reflected in the linguistic picture of the world. Meteorological terms being an integral part of the daily life of the people accumulate a rich layer of knowledge about natural phenomena related to the climatic conditions of the region and traditional forms of economic activity. Despite the importance of this lexical group the history of its study in Tatar linguistics has not yet received adequate coverage. This article aims to trace the main stages of the study of meteorological names in the Tatar language, starting with the first lexicographic works and ending with modern research in the field of dialectology, semantics and ethnolinguistics. The article will review the key works of scientists who have contributed to the study of this issue, analyze methods and approaches to the analysis of meteorological vocabulary and identify promising areas for further research.

**Keywords:** meteorological vocabulary, dialectology, dialect vocabulary, meteorological names, tatar language.

Кешенең дөньяга карашында климат һәм һава торышы күренешләре аерым урын алып тора, аның тормышына һәм үз-үзен тотышына зур йогынты ясый. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү һәм танып белү процессында кеше һава торышы күренешләрен өйрәнергә генә түгел, ә аларны тасвирларга һәм бәяләргә дә тырышкан. Бу белемнәрнең барысы да телдә махсус берәмлекләр – метеонимнар

ярдәмендә чагылыш таба. Лингвистикада һава торышы өлкәсенә караган лексиканы метеоним, яисә метеорологик лексика дип атыйлар.

Метеорологик лексика дөнья телләрендәге киң үсеш алган тематик төркемнәрнең берсен тәшкил итә. Бу хәл тормыш-көнкүрештә һава торышының әһәмиятле роль уйнавы белән бәйле. Әлеге мәкаләнең максаты – татар телендәге метеорологик лексика мәсьәләләренә бәйле булган публикацияләргә күзәтү ясау, анализлау, шулай ук алга таба тикшеренүләрнең перспектив юнәлешләрен билгеләү.

Эшнең фәнни һәм гамәли әһәмияте фәнни басмаларның төрле критерийлар буенча классификациясе, аларның эчтәлеген анализлау һәм өйрәнелә торган проблематика буенча төп фәнни хезмәтләргә күзәтү ясау белән билгеләнә.

Татар телендәге метеонимнарны өйрәнү тарихын төрки тел белеме яссылыгында карау зарури санала. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: әлеге тематик төркем тюркологиядә тиешле дәрәҗәдә тикшерелмәгән, метеонимнарны монографик планда өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләр күп түгел. Мәсәлән, казах, кыргыз, азәрбайҗан һәм башкорт телләренә караган диссертацияләр (Н. Базылхан, 1998; В.Б. Джафаров, 1990; А.Г. Искандаров, 2009; К. Сагындыкова, 2012) якланган, башка төрки телләрдә аерым мәкаләләр (Р.З. Хафизова, 2015; Р.Р. Җамалетдинов, 2020; М.З. Улаков, 2021; Н.И. Данилова, 2019 һ. б.) бар. Шул ук вакытта алар арасында метеорологик лексиканы комплекслы рәвештә колачлаган хезмәтләр бик аз (Л.В. Данилова. «Метеорологическая лексика тюркских языков»; В.Б. Джафаров. «Метрологические термины в азербайджанском языке»; А.Г. Искандаров. «Метеорологическая лексика башкирского языка»; К.С. Сагындыкова. «Кыргыз тилинде жаратылыш кубулуштарынын атоолору» («Кыргыз телендә табигать күренешләренең атамалары»)). Шулай ук метеорологик лексика проблематикасының аерым аспектларына багышланган хезмәтләр дә бар [6: 234].

Аерым өлкәгә караган лексиканы системалы рәвештә тикшерү хәзерге татар тел белеменең мөһим юнәлешләреннән берсе булып тора. Аш-су, кием-салым, кош-корт, үсемлек атамаларына багышланган фәнни хезмәтләр күп булуга карамастан, метеорологик лексиканы өйрәнүгә караганнары азсанлы.

Алга таба тәкъдим ителгән тикшеренүләрне лингвистика юнәлешләре буенча классификацияләп карыйбыз.

Күпчелек хезмәтләр чагыштырма планда башкарылган, һәм аларда тугандаш телләр дә, тугандаш булмаган телләр дә тикшерелә. Мәсәлән, В.С. Дмитриева һәм Г.И. Илдархpraнованың «Лексика природных явлений в русском, татарском и турецком языках» (1998) китабында тикшерену объекты – рус, татар һәм төрек телләрендә табигать күренешләрен атаучы исемнәрнең тематик төркеме. Авторлар метеонимнарны анализлап, әлеге тематик бүленеш эчендә 6 лексик-семантик төркем аерып чыгаралар: атмосфера явым-төшемнәре, һава массаларының хәрәкәте, гомуми күренешләр, атмосфераны тоник-

ландыра торган матдәләр, атмосфераның температура халәтләре, яктылык күренешләре. Хезмәттә төп метод буларак чагыштырма-типологик метод кулланыла [2: 6].

Ә.М. Галиева һәм Р.Р. Җамалетдиновларның «Семантика и сочетаемость татарских глаголов, обозначающих природные явления» (2017) хезмәтендә табигать күренешләрен туры мәгънәдә белдергән татарча синтетик фигыльләр карала. Төп игътибар һава торышы белән бәйле субстантив фигыльләргә бирелә. Бу төркемнең үзәген һава торышы белән бәйле күренешләрне белдерүче фигыльләр тәшкил итә: явым-төшемнәр, температура үзгәрү, болытлы көн, җил көче һ. б. Мәсәлән, яву (падать – об осадках), исү (дуть – о ветре), күкрәү (грохотать – о громе), буранлау (вьюжить), давыллау (бушевать – о буре) [1: 18].

Татар телендә метеонимнар чагыштырма аспектта тикшерелгән тагын бер хезмәтне билгеләп үтәргә кирәк. Д.Д. Хәйруллина, Э.Н. Гыйләҗева, Л.В. Базароваларның «Особенности номинации природного явления «дождь» в английском и татарском языках» (2021) мәкаләсендә инглиз һәм татар телләрендә «яңгыр» күренешен аңлаткан лексемаларының семантик һәм функциональ үзенчәлекләре ачыклана. Эшнең фәнни яңалыгы шунда: әлеге лексик катлам беренче тапкыр типологик һәм генетик яктан кардәш булмаган телләрдә, чагыштырма аспектта өйрәнелә. Нәтиҗәдә, инглиз телендә яңгыр номинацияләренең ачыграк тасвирланганлыгы дәлилләнә. Инглиз теленнән аермалы буларак, татар телендә кайбер метеонимнарның уңай мәгънәгә ия булуы ачыклана. Моны төбәкнең географик үзенчәлекләре һәм климат шартлары белән аңлатырга мөмкин дип фаразлана [10: 918].

Соңгы дистә елларда лингвистикада когнитив һәм лингвокультурологик тикшеренүләргә игътибар арта бара. Метеолексика буенча хезмәтләр дә әлеге тенденциягә иярә. Мәсәлән, күренекле филолог, профессор А.Г. Шәйхулловның «Структура и идеографическая парадигматика односложных корневых основ в кыпчакских языках Урало-Поволжья в континууме ареальной, межтюркской и общетюркской лексики (синопсис и таксономия когнитивной сферы)» (2000) монографиясендә татар һәм башкорт телләрендә ареаль, гомумтөрки апеллятив лексика җирлегендә терек булмаган табигать дөньясы белән бәйле (Җир. Җир киңлеге. Су. Су киңлеге. Космос. Космос киңлеге. Һава. Һава киңлеге. Климат. Һава торышы) бер иҗекле тамырлар классификациясе һәм аларны төркемләү принциплары тикшерелә.

Берничә хезмәт метерологик лексиканы этнолингвистика юнәлешендә – халык метеорологиясе, ырымнар һәм ышанулар аша өйрәнүгә багышланган. Филология фәннәре кандидаты М.И. Закировның татар теленең метеорологик лексикасына бәйле берничә мәкаләсе бар. Аларда автор метеонимнарның татар халык авыз иҗаты әсәрләрендә, халык ышануларында, шулай ук фразеологик системада да чагылышын тикшерә. Мәсәлән, «Лексема дождь в русских и татарских

народных приметах» (2008) хезмәтендә рус һәм татар халык сынамышларында яңгыр лексемасы чагыштырма планда карала. Халык сынамышларын өйрәнүнең культурологик нигезләре тикшерелә, чагыштырыла торган телләрдә яңгыр сүзенең мәгънә вариантлары күрсәтелә, рус һәм татар халык сынамышларына тәфсилле характеристика бирелә. Яңгыр лексемасы кергән халык сынамышлары «атмосфера явым-төшемнәре» лексик-семантик төркеме мисалында тәкъдим ителә [4: 144].

Шул ук авторның «Лексема снег в русских и татарских народных приметах» (2008) дигән мәкаләсендә халык сынамышларында кар лексемасы чагыштырма аспектта карала. Хезмәттә халык сынамышларын өйрәнүнең культурологик нигезләре билгеләнә, чагыштырыла торган телләрдә кар сүзенең мәгънәләре китерелә, өйрәнелә торган лексема кергән сынамышлар тикшерелә.

М.И. Закировның «Сопоставительная характеристика лексем вода и су в народных приметах русского и татарского языков» (2008) мәкаләсе рус һәм татар телләрендә вода һәм су лексемаларын чагыштыруга багышлана, әлеге сүзләргә культурологик аспекттан чыгып анализ бирелә, шулай ук аларның лексик яктан туры килү-килмәве ачыклана.

Р.З. Хафизованың «Лексема дождь (яңгыр) в татарском языке» (2015) мәкаләсендә татар әдәби телендә һәм аның диалектларында яңгыр төрләрен билгеләү өчен күп кенә атамаларда чагылган яңгыр образын кабул итү анализлана. Мәсәлән, «ләйсән яңгыр», «койма яңгыр», «пыскак яңгыр», «җилле яңгыр» кебек татар теленә генә хас үзенчәлекле лексик берәмлекләр ачыклана [11: 202]. Шулай ук яңгыр белән бәйле гореф-гадәтләргә, мәкальләргә һәм халык сынамышларына бәяләмә бирелә (мәсәлән, «яңгыр боткасы» йоласы).

Татар теленең диалектларында метеонимнарны өйрәнү беркадәр Т.Х. Хәйретдинова мәкаләләрендә («Салават күперен кем ничек атый?» (2000), «Татар сөйләшләрендә табигать күренешләре белән бәйле кайбер сүзләр» (2002), «“Аҗаган” төшенчәсенең татар сөйләшләрендә бирелеше» (2002)) чагылыш таба. Әлеге хезмәтләрдә диалектларда теркәлгән метеорологик аппеллятивларның семантик структурасына идеографик һәм ономасиологик анализ позицияләреннән тасвирлама бирелә. Метеонимнарның семантик үзенчәлекләре анализлана, формалашу чыганаклары һәм юллары тикшерелә һәм шул нигездә татар сөйләшләре вәкилләренең һава торышы процессларына үзенчәлекле карашы турында нәтиҗәләр ясала. Мәсәлән, аҗаган сүзенең сөйләшләрдә таралыш үзенчәлекләре изоглоссалар ярдәмендә тикшерелә: 1) әҗәгай/наҗакай – Урал төбәге сөйләшләре; 2) йәшен сүзе белән сүзтезмәләр – көнбатыш диалект сөйләшләре; 3) арыш камчалау – казан арты сөйләшләре өчен характерлы [9: 122].

Шулай итеп, метеонимнар телнең сүзлек составының мөһим өлешен тәшкил итә. Шул ук вакытта әлеге лексик төркем, башка лексик-

семантик төркемнәр белән чагыштырганда, татар телендә аз өйрәнелгән.

Татар телендәге метеорологик лексикага багышланган публикацияләрне анализлау күрсәткәнчә, эшләрнең күбесе чагыштырма планда башкарыла, әлеге хезмәтләрдә метеонимнар төрле аспектларда өйрәнелә. Күрсәтелгән тикшеренүләрдә метеонимнар хәзерге тел материалында анализлана, ягъни синхрон аспектта тикшерелә.

Безнең фикеребезчә, гомумхалык телендә метеонимнарны өйрәнү аеруча әһәмиятле, чөнки ул әдәби телнең тәгәллеген чагылдыра һәм диалекталь тел байлыгын үз эченә ала.

Татар диалектларында метеорологик күренеш атамаларын җыю, системалаштыру һәм анализлау – киләчәктәге тикшеренүләрнең мөһим бурычы. Бу – татар теленең лексик байлыгын тулырак ачарга, диалектларның үзенчәлекләрен ачыкларга һәм гомумән, татар халкының мәдәни мирасын сакларга ярдәм итәчәк.

Әлеге өлкәдә алга таба тикшеренүләрнең түбәндәге перспектив юнәлешләрен билгеләргә мөмкин. Системалаштыру ягыннан татар диалектларындагы барлык метеонимнарны җыеп, тасвирлап, соңыннан диалекталь сүзлекләр һәм глоссарийлар төзү зарур. Ареалогик яссылыкта метеонимнарның географик таралышын өйрәнү, изоглоссларны билгеләү татар теленең диалекталь бүленешен һәм тарихи үсешен ачыкларга ярдәм итәчәк. Тарихи аспектта сүзләрнең килеп чыгышын, аларның борынгы төрки мирас белән мөнәсәбәтләрен, шулай ук гарәп-фарсы, рус һәм фин-угор алынмаларының йогынтысын анализлау тел тарихын тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә. Чагыштырма метод ярдәмендә диалекталь метеонимнарны татар әдәби теле, башка кардәш һәм күрше телләрдәгеләре белән чагыштырып, аларның уртак үзлекләрен һәм үзенчәлекләрен күрсәтеп була.

Әлеге тикшеренүләр татар диалектларының байлыгын ачу белән беррәттән, халык тормышының әйләнә-тирә мохит белән аерылгысыз бәйләнешен, мәдәни-тарихи мирасны, шул исәптән халык метеорологиясенең бай традицияләрен тирәнтен өйрәнергә булышыр.

**Әдәбият**

1. *Галиева А.М., Замалетдинов Р.Р.* Семантика и сочетаемость татарских глаголов, обозначающих природные явления // Филология и культура. Philology and Culture. 2017. № 3 (49). С. 17–25.

2. *Дмитриева В.С., Ильдарханова Г.И.* Лексика природных явлений в русском, татарском и турецком языках // науч. ред. Ф.А. Ганиев. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1998. 105 с.

3. *Закиров М.И.* Лексема дождь в русских и татарских народных приметах // Вестник Чувашского университета. Гуманитарные науки. 2008. № 3. С. 140–145.

4. *Закиров М.И.* Лексема снег в русских и татарских народных приметах // Вестник Вятского государственного университета. Лингвистика. 2008.

5. *Закиров М.И.* Сопоставительная характеристика лексем вода и су в народных приметах русского и татарского языков // Вестник ТГГПУ. 2008. № 3 (14).

6. *Милованова Н.В.* Исследования метеолексики в современной лингвистике: к степени изученности вопроса // Известия КазУМОиМЯ им. Абылай хана. Серия «Филологические науки» 2025. № 1 (76). С. 230–243.

7. *Хәйретдинова Т.Х.* Салават күперен кем ничек атый // Материалы Итоговой науч.-практ. конф. за 1999 г. Казань: Изд-во Татар. гос. гуманит. ин-та, 2000. С. 41–43.

8. *Хәйретдинова Т.Х.* Татар сөйләшләрендә табигать күренешләре белән бәйле кайбер сүзләр // Актуальные проблемы тюркской и финно-угорской филологии: теория и опыт изучения. Материалы Всерос. науч.-практ. конф. (10–12 декабря 2002 г., г. Елабуга). Елабуга, 2002. С. 192–197.

9. *Хәйретдинова Т.Х.* «Аҗаган» төшенчәсенең татар сөйләшләрендә бирелеше // Актуальные вопросы татарского языкознания. Казань: Фикер, 2002. С. 117–122.

10. *Хайруллина Д.Д., Гилязева Э.Н., Базарова Л.В.* Особенности номинации природного явления «дождь» в английском и татарском языках // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2021. Т. 14. Вып. 3. С. 918–922.

11. *Хафизова Р.З.* Лексема дождь (яңгыр) в татарском языке // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2015. № 8 (50). С. 201–204.

12. *Шайхуллов А.Г.* Структура и идеографическая парадигматика односложных корневых основ в кыпчакских языках Урало-Поволжья в континууме ареальной, межтюркской и общетюркской лексики (синопсис и таксономия когнитивной сферы // Природа (живая и неживая). Уфа, 2000. С. 327–360.

***Идиятуллина Алия Илдус кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге кече фәнни хезмәткәре*

***Хөсәинова Алинә Җәмил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Идиятуллина Алия Ильдусовна,***
*младший научный сотрудник отдела общей лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*aliya1311@mail.ru*

***Хусаинова Алина Ямиловна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела ареальной лингвистики Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*husainova_alina@mail.ru*

УДК 811(=512.1)

*Х.Ч. Алишина*

# ЭЛГӘРЛӘРЕБЕЗНЕҢ ФӘННИ МИРАСЫ: тюрколог, борынгы уйгур теле белгече профессор Д.М. Насиловның тууына 90 ел тулу уңаеннан

Статья посвящена научно-педагогической деятельности крупнейшего ученого-востоковеда, единственного в России специалиста по древнеуйгурскому языку, автора более 250 научных и научно-методических трудов, словарей и монографий Дмитрия Михайловича Насилова (1935–2017). Рассматриваются ключевые этапы его биографии как ученого и педагога, руководителя и общественного деятеля, определяются магистральные линии научных изысканий, дается краткий обзор наиболее значимых трудов. Автор статьи раскрывает роль Д.М. Насилова в возрождении национальных культур в 1990-е гг., сохранении научных традиций, популяризации достижений российской науки на международном уровне. Особая роль в публикации отведена освещению доклада, прозвучавшего на Международной тюркологической конференции 85-летию памяти академика Д.Г. Тумашевой, с которой его связывала многолетняя творческая дружба.

**Ключевые слова:** Дмитрий Михайлович Насилов, тюркология, ученый-востовокед, древнеуйгурский язык, грамматика тюркских языков.

The article is devoted to the scientific and pedagogical activities of the leading orientalist, the only specialist in the ancient Uyghur language in Russia, the author of more than 250 scientific and scientific-methodical works, dictionaries and monographs Dmitry Mikhailovich Nasilov (1935–2017). The key stages of his biography as a scientist and teacher, leader and public figure are considered, the main lines of scientific research are determined, a brief overview of the most significant works is given. The author of the article reveals the role of D.M. Nasilov in the revival of national cultures in the 1990s, the preservation of scientific traditions and the popularization of the achievements of Russian science at the international level. A special role in the publication is given to the coverage of the report delivered at the International Turkological Conference on the 85th anniversary of the memory of Academician D.G. Tumasheva, with whom he had a long-standing creative friendship.

Keywords: Dmitry Mikhailovich Nasilov, Turkic studies, Orientalist scholar, ancient Uyghur language, grammar of Turkic languages.

Дмитрий Насилов 1935 елның 18 мартында Мәскәү өлкәсе Зарайск шәһәрендә зыялылар гаиләсендә дөньяга килә. Һөнәр сайлауда якын туганы, шәркыятчы галим, педагог, профессор, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе Владимир Михайлович Насиловның йогынтысы зур була.

Дмитрий Михайлович Насилов бөтен гомерен төрки телләрне өйрәнүгә багышлый. Керү имтиханнарын уңышлы тапшырып, ул МДУның филология факультеты Көнчыгыш бүлегенә хәзерге (төрек, үзбәк) һәм борынгы төрки телләр белгечлегенә укырга керә.

Биредә Себер татарлары телен фәнни өйрәнүгә нигез салучы, Казан дәүләт университеты профессоры, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе, Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты, нигез салынган көннән Совет (хәзер Россия) тюркологлары комитеты әгъзасы, Türk Dil Kurumu Төркия лингвистика җәмгыятенең мактаулы әгъзасы Диләрә Гариф кызы Тумашева, филология фәннәре докторы, РФА Тел белеме институты Урал-Алтай телләре бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Галина Федоровна Благова һ.б. укый.

А.В. Шеймович «К 85-летию Галины Федоровны Благовой: научные итоги десятилетия» дигән мәкаләсендә болай дип билгеләп үтә: «Г.Ф. Благованың университеттагы укытучылары – Самойлович фәнни мәктәбен дәвам иткән Н.К. Дмитриев, Самойловичның үзендә укыган Ә.Н. Нәҗип һәм В.М. Насилов» [6: 4]. Танылган шәркыятчылар Николай Константинович Дмитриев, Әмир Нәҗип улы Нәҗип, Владимир Михайлович Насилов, Эрванд Владимирович Севортянда Дмитрий Михайлович Насилов та укый. Бу – тюркологиягә ихлас күңелдән бирелгән галимнәрнең искиткеч плеядасы.

Галина Федоровна Благова белән Диләрә Гариф кызы Тумашева яшьтәшләр була. Студент еллары 1944–1949 елларга туры килгән Д.Г. Тумашева үзенә аеруча кадерле булган педагогларны – фәнни җитәкчесе, Мәскәү тюркологлар мәктәбенә нигез салучы, СССР ФА мөхбир әгъзасы, профессор Николай Константинович Дмитриевны, гарәбиятчы Бенциан Меерович Грандены, иранист Борис Всеволодович Миллерны, тюрколог Эрванд Владимирович Севортянны, фольклорчы Мәдинә Искәндәр кызы Богданованы зур хөрмәт белән искә ала [1: 7].

Д.М. Насиловның яшьлеге, студент еллары Көнчыгышта милли азатлык хәрәкәте күтәрелгән чорга туры килә. Илгә төрки телләр буенча Мәскәү шәркыяте позициясен үстерергә һәм ныгытырга сәләтле югары квалификацияле белгечләр кирәк була. Дмитрий Михайлович, төрки филология кафедрасында диплом эшен «бик яхшы» билгесенә яклап, МДУны 1958 елда тәмамлый. ДИК (ГЭК) карары белән аңа шәркыятчы филолог, филология фәннәре өлкәсендә фәнни хезмәткәр, югары уку йорты укытучысы квалификациясе бирелә.

Мәгариф министрлыгы юлламасы белән Д.М. Насилов Үзбәкстанга китә һәм 1958–1960 елларда Сәмәрканд университетының үзбәк теле кафедрасында укытучы булып эшли. 1964 елда Мәскәүдә Тел белеме институты каршындагы аспирантураның көндезге бүлеген уңышлы тәмамлап, «Структура времени индикатива в древнеуйгурском языке (по памятникам уйгурского письма)» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Бүгенге көнгә кадәр Д.М. Насилов Россиядә борынгы уйгур теле һәм аның язуы буенча бердәнбер белгеч санала.

Д.М. Насиловның максатчан фәнни эшчәнлеге 1963 елдан башлап утыз ел дәвамында Тел белеме институтының (хәзер Россия

фәннәр академиясе Лингвистик тикшеренүләр институты) Ленинград бүлеге белән бәйле була. Анда ул алтай телләре секторы җитәкчелеге тарафыннан эшкә чакырыла. Биредә Дмитрий Михайлович үзенең эшчәнлеген кече фәнни хезмәткәр буларак башлый һәм РФА Лингвистик тикшеренүләр институты алтай телләре бүлеге мөдире дәрәҗәсенә күтәрелә. Д.М. Насилов, мәкаләләр авторы һәм мөхәррирләрнең берсе буларак, бик сирәк очрый торган китапны – «Древнетюркский словарь»ны басмага әзерләү белән шөгыльләнә. Үз вакытында В.В. Радлов, С.Е. Малов эшли башлаган сүзлеккә төркиләрнең бөтен алфавитларындагы (Орхон, төрки, гарәп, манихей) лексика теркәлгән – барлыгы 6000 сүз һәм гыйбарә. Бу елларда Дмитрий Михайлович төрки филология өлкәсендә илебезнең иң танылган һәм атказанган галимнәренең берсе була, төрки телләрнең теоретик грамматикасына зур өлеш кертә, алтай телләрендә фигыльнең грамматик категорияләрен җентекләп өйрәнә.

Д.М. Насиловның фәнни эшчәнлегенең төп юнәлешен фигыль категорияләре темасы тәшкил итә. Искәртеп үтәм: фигыль – минем фәнни җитәкчем, ТР Фәннәр академиясе академигы Диләрә Гариф кызы Тумашеваның да иң яраткан сүз төркеме иде. Яшь аермасы шактый булуга карамастан, Россиянең ике атаклы тюркологын – Диләрә Гариф кызын һәм Дмитрий Михайловичны күпьеллык иҗади дуслык бәйләп тора. Минемчә, аларны МДУның алар икесе дә укыган факультетына тугрылык, уртак фәнни мәнфәгатьләр, танылган укытучыларына хөрмәт якынайта.

Дмитрий Михайловичны *вид* мәсьәләсе борчый, чөнки төрки телләрдә, рус һәм башка славян телләрендәге кебек, аның аналогы юк, әмма «есть признаки, которые связываются с понятием аспекта в общей лингвистике» [3: 4]. Бу тема беренче мәртәбә Д.М. Насиловның «О способах выражения видовых значений в алтайских языках» дигән хезмәтендә күтәрелә. Галим 30 га якын хезмәтен әлеге проблеманың төрле аспектларына багышлый, бу «Наука» нәшриятында Ә.Р. Тенишев редакциясендә нәшер ителгән «Проблемы тюркской аспектологии. Акциональность» монографиясендә чагылыш таба. Кулъязма Дмитрий Михайлович эшләгән кафедра әгъзаларында, хезмәттәшләрендә зур кызыксыну уята. Шунысы игътибарга лаек: кулъязманы тикшерүдә себер (бараба) татарлары теле белгече, филология фәннәре докторы Людмила Васильевна Дмитриева да актив катнаша. Китапның рецензентлары – филология фәннәре докторы В.М. Павлов, филология фәннәре кандидаты Е.А. Кузьменков.

Галимнәр төрки вид проблемасына багышланган бу монографиянең аеруча әһәмиятле һәм кирәкле булуын таныйлар. Монография Дмитрий Михайловичның докторлык диссертациясенең дә нигезен тәшкил итә. Мәгариф һәм фән министрлыгының Югары аттестация комиссиясе Д.М. Насиловның фәнни казанышларын югары бәяли. 1990 елның 3 августында «Проблемы тюркской аспектологии: акциональность» дигән темага диссертация яклаганнан соң, ул филология

фәннәре докторы дипломын ала. Алга таба бу юнәлештәге тикшеренүләр типологик характерда бара. «Акциональность в алтайских языках. Типология и “детерминанта”» хезмәтендә алтай телләре чагыштырып өйрәнелә.

XX гасыр ахыры Казан тюркологлары өчен дә уңышлы була. КДУ профессоры Д.Г. Тумашева татар теле морфологиясен, аерым алганда татар фигыльләрен, өйрәнү буенча фәнни эш белән актив шөгыльләнә. 1986 елда аның миңа язган хатыннан бер өземтә китерәм: «…к 15 декабря я должна дать еще одну статью, чисто грамматическую: взаимодействие грамматических категорий глагола. Затем у меня доклад на пленарном заседании итоговой научной конференции “Способы номинации пространственной характеристики действия”, потом, на конференцию, посвященную Г. Ибрагимову – “Стилистика глагольных форм” и т. д.» [4: 237].

Профессор Д.Г. Тумашева татар телен, Себер татарлары диалектларын өйрәнү буенча зур фәнни-тикшеренү эше алып барган өчен 1991 елда Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең беренче хатын-кыз академигы итеп сайлана. Татарстан Республикасының әйдәп баручы тюркологлары М.З. Зәкиев, Ф.Ә. Ганиев, Д.Г. Тумашева, К.З. Зиннәтуллина тарафыннан эшләнгән өч томлы «Татар грамматикасы» тел белемендә зур казаныш һәм беренче җитди фәнни басма буларак бәяләнә.

Д.Г. Тумашеваның татар фигыле темасын аеруча яратып өйрәнүе турында алда әйтелгән иде. Әйтелгәннәрне раслап, 2001 елда язылган хатыннан тагын бер кечкенә өземтә китерәм: «Напишу и о себе. Очень устаю. К концу года сдали коллективную монографию на татарском языке. Я – руководитель и мною лично написаны два раздела: “Лексическое и лексико-грамматическое значение глагола” и “Функционально-семантические категории модальности, темпоральности, персональности” – 150 страниц компьютерного текста» [5: 253].

Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Төрки телләр диалектологиясе, тарихы һәм грамматик структурасы» Халыкара тюркологик конференциясе академик Д.Г. Тумашеваның тууына 85 ел тулуга багышлап уздырыла. Дмитрий Михайлович Насилов «Программный труд академика Д.Г. Тумашевой» дигән доклад белән чыгыш ясый, анда, аерым алганда, мондый сүзләр бар: «С творческой деятельностью виднейшего татарского филолога Д.Г. Тумашевой непосредственно связан тот научный сдвиг, который определил и, с нашей точки зрения, определяет теоретические направления в татарском языкознании» [2: 10].

Дмитрий Михайлович «Татарский глагол: Опыт функционально-семантического исследования грамматических категорий» китабын Д.Г. Тумашеваның программ хезмәте дип атый: «Данное учебное пособие отражает определенный этап исследования структуры

татарского глагола, осуществляемого на кафедре татарского языка Казанского университета. В нем получил отражение функционально-семантический аспект анализа глагольных форм и категорий. В пособии использован опыт предшествующих исследований по морфологии татарского глагола, в том числе диссертационных работ по глаголу Ф.М. Хисамовой, М.Б. Мардиевой, Н.Х. Салеховой, Д.Ш. Шайхайдаровой, Р.С. Абдуллиной, выполненных под руководством автора» [5: 10].

Д.М. Насилов фикеренчә, Д.Г. Тумашева татар теленең фигыль (һәм фигыльләрнең генә дә түгел!) категорияләрен функциональ-семантик аспектта һәм кыр структуралары кысаларында өйрәнүнең комплексы программасын тәкъдим итә. «Значительных успехов добились грамматисты в изучении глагольных категорий, особенно продуктивным оказалось описание поля аспектуальности в тюркских языках. Большой прорыв в этом отношении был связан с работами Ф.А. Ганиева, впервые широко использовавшего понятие способа глагольного действия применительно к татарскому глаголу» [2: 10].

Д.М. Насилов Казан галимнәре – академик Д.Г. Тумашева, ТР ФА мөхбир әгъзасы Ф.А. Ганиев – төрки тел белемендә концептуаль яктан өч юнәлешкә нигезләнгән фәнни мәктәпкә нигез салды, дип саный һәм пленар утырышта ясаган докладында әлеге юнәлешләрне җентекләп бәян итә.

«Во-первых, на материале тюркских языков была поставлена и получила конкретное обоснование идея о различении собственно видовых значений (аспект) и значений способов глагольного действия (акционсарт) как соотносительных, но содержательно разных языковых явлений, представленных в этих языках различающимися грамматическими средствами. В русле этого направления был выполнен целый ряд работ, в которых получили описание способы действия отдельных языков.

Во-вторых, наметилась определенная тенденция рассматривать систему временных форм как систему видовременных форм, в которых оказываются сопряженными аспектуальные и темпоральные значения.

Это побуждает исследователей не только углубляться в анализ состава значений отдельных временных форм, но и стремиться к определению их системных значимостей, особенно при наличии многочленных парадигм. Здесь же встают вопросы о соотношении в формах глагола временной и аспектной семантики, играющие важную роль при диахронических исследованиях, когда изучается генезис темпорально-аспектных категорий в том или ином тюркском языке. Наблюдения, накопленные в этом направлении, небезынтересны и для типологии языкового развития.

В-третьих, в современной тюркологии все возрастающее внимание уделяется функциональному подходу к описанию категорий, при котором существенное место отводится взаимодействию лексического

и морфологического уровней языка. Поэтому не случайно выясняются связи между лексическим значением глагола, его предельным/непредельным характером, принадлежностью к определенной семантической группе и образуемыми от него грамматическими формами. Уточняются и синтагматические связи глагольных словоформ, зависимость семантики последних от контекста. При этом особое внимание обращается на особенности функционирования и реализации конкретного значения глагола в каждом отдельном высказывании, то есть выделяются прежде всего значимые элементы контекста, выясняется роль аспектуального контекста, способствующего проявлению аспектуальной характеристики действия» [2: 11].

Халыкара юбилей конференциясенең пленар утырышында, үзенең докладын йомгаклап, Дмитрий Михайлович болай дип ассызыклый: «25 лет тому назад Д.Г. Тумашева своей работой показала, что на основе новейших грамматических разработок и при соответствующей реинтерпретации накопленного языкового материала возможен новый взгляд на некоторые глагольные категории татарского языка, то есть продвинувшееся новое теоретическое знание влечет за собой переоценку эмпирических фактов» [2: 12].

Танылган галимнең хезмәт биографиясендәге бер мөһим моментны билгеләп үтәргә кирәк: Санкт-Петербургта яшәсә дә, Д.М. Насилов беркайчан да Мәскәүдәге коллегалары белән элемтәне өзми, «Төрки телләрнең этимологик сүзлеге» коллективында эшли, сүзлеккә мәкаләләр язуда да, РФАнең Тел белеме институты тюркологлары тарафыннан башкарылган «Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков» дип исемләнгән күп томлы планлы хезмәтне эшләүдә дә катнаша.

Галим Д.М. Насилов ярты гасырдан артык укыту эшчәнлегеннән аерылмады. Зур һәм абруйлы тюрколог, төрки тел белеме буенча күренекле белгеч буларак, ул Петербург дәүләт университеты Көнчыгыш факультетының төрки филология кафедрасында гына түгел, ә илнең башка әйдәп баручы югары уку йортларында да лекция курслары укый. Миңа 1989 елның октябрендә Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарихы һәм Көнчыгыш телләре факультеты аспирантурасында профессор Д.М. Насиловның «Борынгы төрки язма һәйкәлләр теле» дигән лекцияләр курсын тыңлау һәм аның үзенә зачёт тапшыру насыйп булды. Профессорның мин тырышыптырышып конспектлаган һәр сүзе актуаль, еллар үтү белән аларның кыйммәте арта гына бара, алардан зур фәнни энергия бөркелә. КДУ аспирантлары алдында чыгыш ясаганда, лектор Д.М. Насилов һунну, сяньби, төрки каханлыклар, борынгы уйгур, манихей, Орхон-Енисей алфавитлары тарихын тәфсилләп аңлатты, Дмитрий Дмитриевич Васильев («Корпус древнетюркских памятников Енисея»), Сергей Ефимович Малов хезмәтләрен («Памятники древнетюркской письменности», «Енисейская письменность тюрков») җентекләп анализлады, бу китапларны табып өйрәнергә киңәш итте. Д.М. Насиловтан

алган бәһасез белемнәр, галимнең тышкы кыяфәте, югары культуралылыгы, абруе, зыялылыгы бездә – Көнбатыш Себер, Казахстан, Үзбәкстан, Таулы Шория, Якутия, Хакасия, Таганрогтан килгән аспирантларда тирән ихтирам хисе уятты. Алган белемнәребез безгә – яшь тюркологларга – алдагы тормышыбызда бик ярап куйды. Алда бит әле һәрберебез әлеге компетентлы профессор белән берничә тапкыр очрашты. Ул безнең югары уку йортларына, көтелгән хөрмәтле кунак буларак, симпозиумнарга, конференцияләргә, форумнарга, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренең оппоненты сыйфатында махсуслаштырылган фәнни советларга килә.

1993 елда профессор Дмитрий Михайлович Насиловны РФ Милләтләр эшләре буенча һәм төбәк сәясәте министрлыгы каршында оештырылган Россия Федерациясе халыклары телләре институтына чакыралар, анда ул институт директоры урынбасары вазифасын башкара. Бу – ил тормышында яңа чор, милли мәдәниятләрне торгызу этабы була. Төмән дәүләт университетында, В.И. Ленин исемендәге Мәскәү педагогия институтында, Оренбург, Тубыл һәм башка педагогия институтларында татар бүлекләре нәкъ менә шул елларда булдырыла. РФ милләтләр эшләре буенча һәм төбәк сәясәте министрлыгы бу чорда Халыкара төрки академия оештыру буенча зур эш алып бара, аның президенты итеп абруйлы тюрколог, РФА мөхбир әгъзасы Әдһәм Рәхим улы Тенишев билгеләнә, хакыйкый әгъзалары итеп Дмитрий Михайлович Насилов, Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев, Игорь Валентинович Кормушин, Рашид Абдулла улы Саликов, Шамил Фатих улы Мөхәммәдьяров, Фоат Тач-Әхмәт улы Вәлиев, Ирек Г. Акманов, Николай Константинович Антонов, Марат Вәли улы Зәйнуллин, Зиннур Газиз улы Ураксин, Кази Танай улы Лайпанов, Хәнисә Чайдат кызы Алишина һ. б. сайлана.

1996 елда Дмитрий Михайлович М.В. Ломоносов исемендәге МДУның Азия һәм Африка илләре институты төрки филология кафедрасы профессоры итеп сайлана. Д.М. Насилов югары квалификацияле фәнни-педагогик кадрлар әзерләүдә, фәнни традицияләрне саклауда зур тәҗрибәгә ия. Ул студентлар һәм аспирантлар өчен лекция курслары әзерли һәм укый: «Алтаистика тарихы», «Борынгы төрки язма истәлекләр теле», «Борынгы уйгур теле», «Үзбәк теле», «Төрки телләрнең чагыштырма грамматикасы нигезләре», «Төрки лексикология», «Төрки телләрнең функциональ грамматикасы нигезләре», «Тюркологиягә кереш», «Рус һәм үзбәк телләренең чагыштырма грамматикасы» һ.б.

Профессор Дмитрий Михайлович Насиловның фәнни хезмәтләре белән бөтен дөнья тюркологлары таныша, дияргә мөмкин. Алар галимнең түбәндәге монографияләрен югары бәялиләр: «Проблемы тюркской аспектологии: Акциональность», «Концепция языкового типа в трудах Н.А. Баскакова», «Значение» и «функция» в функциональной грамматике А.В. Бондарко», «Языки малочисленных этносов в образовательном пространстве России» һ. б. Профессор

Д.М. Насилов РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы белән тыгыз хезмәттәшлек итеп, мәктәп укытучыларына зур фәнни-методик ярдәм күрсәтә. «Россия Федерациясе Төньягының азсанлы җирле халыклары өчен этник (милли) мәктәп моделе концепциясе», «Төньяк халыклары мәктәпләре өчен тунгус-маньчжур төркеме телләре буенча типовой гомуми белем бирү программасы», «Милли мәктәп өчен туган һәм рус теле дәреслеге концепциясе» иҗади хезмәттәшлекнең нәтиҗәсе булып тора.

Элгәрләренең фәнни мирасын өйрәнүгә Д. М. Насилов зур әһәмият бирә: ул – В.В. Радлов, С.Е. Малов, О.Н. Бетлинг, П. М. Мелиоранский һ.б. турында мәкаләләр, хезмәтләр авторы. Алар арасында Д.М. Насиловның Ф. Д. Ашнин һәм В.М. Алпатов белән бергә язылган «Репрессированная тюркология»се (2002) һәм А.Н. Самойловичка һәйкәл-китабы (2005) аерылып тора. Соңгысында XX гасырның әйдәп баручы тюркологларыннан берсе булган галимнең (1938 елда репрессияләнә) төп хезмәтләре искә төшерелә һәм шәрехләнә [3: 12].

Галим Д.М. Насиловның фәнни һәм иҗади эшчәнлеге күпкырлы. Ул 100 дән артык халыкара, бөтенроссия һәм төбәк конференцияләрендә һәм симпозиумнарда актив катнаша. Алар арасында иң әһәмиятлеләре: мәсәлән, 38 Халыкара шәркыятчылар конгрессы (ИКАНАС-38) – Төркия, Әнкара (2007); күренекле галим Мәхмүд Кашгарига һәм аның «Диване лөгатет-төрк» сүзлегенә багышланган халыкара симпозиум (Левкоша) (2008); III Халыкара тюркология корылтае (Левкоша) (2008). Күренекле фәнни хезмәтләре өчен профессор Дмитрий Михайлович Насилов академик – Türk Dil Kurumu төрек лингвистика җәмгыятенең чит ил әгъзасы итеп сайлана.

Россия (элек Совет) тюркологлары комитеты әгъзасы һәм аның җитәкчеләренең берсе буларак та Д.М. Насилов зур оештыру, берләштерү эшен башкара. Әлеге комитетның, аның элекке рәисләре Андрей Николаевич Кононов, Әдһәм Рәхим улы Тенишевның, хәзерге җитәкчеләре Игорь Валентинович Кормушин, Дмитрий Михайлович Насиловның эшчәнлеге нәтиҗәсендә илебезнең барлык тюркологлары тыгыз фәнни багланышта яши. Шулай итеп, Дмитрий Михайлович Насилов бөтен фәнни эшчәнлеге дәвамында зур, күпмилләтле тюркологик коллективта хезмәт куя. Һәм ул Россия Фәннәр академиясенең Тарих-филология фәннәре бүлеге каршындагы Россия тюркологлары комитеты әгъзасы, ә аннары аның рәис урынбасары булган вакытта махсуслаштырылган фәнни мәсьәләләрне кую һәм хәл итү зарурлыгы туа. 2009 елда Россия Фәннәр академиясе, Россия фәннәр академиясенең Тел белеме институты, Россия тюркологлары комитеты химаясендә «Российская тюркология» журналы яңадан чыга башлый, аның баш мөхәррире итеп Д.М. Насилов сайлана.

Галим Дмитрий Михайлович Насиловның җәмәгать эше Россия фәннәр академиясенең Тарих-филология фәннәре бүлеге каршындагы Россия тюркологлар комитеты рәисе урынбасары, Россия тюркологлар комитеты органы булган «Российская тюркология» журналының

баш мөхәррире вазифалары белән генә чикләнми. Берничә ел дәвамында профессор Дмитрий Михайлович Насилов РФ Дәүләт Думасының Милләтара мөнәсәбәтләр комитетында эксперт булып тора. Аны еш кына Россия халыкларының мәдәнияте һәм телләре буенча төрле иҗади конкурсларда жюри рәисе булырга чакыралар.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында халыкара фәнни багланышларны киңәйтү һәм урнаштыруда алга китеш күзәтелә. Россия ПИАКның ел саен җыела торган халыкара алтаистика конференцияләрендә катнаша башлады. Чит илләрдә безнең фәнне күп еллар дәвамында Дмитрий Михайлович Насилов тәкъдим итә. Мондый конференцияләрдә Көнбатыш галимнәре безнең илдәге зур казанышлар белән таныша алалар.

2014 елның җәендә төрки әдәби телләр тарихы буенча хезмәтләре белән танылган профессор Дмитрий Михайлович Насилов «Тюркология» өлкәсенә зур өлеш керткән өчен Төркия Республикасының «Лиякат» ордены белән бүләкләнә. Бу орден чит ил кешеләренә Тышкы эшләр министрлыгы һәм Төркия Республикасының мәдәният, тел һәм тарих буенча Ататөрк исемендәге Югары советы тәкъдиме буенча Төркия Республикасы Президенты тарафыннан тапшырыла.

«Лиякат» ордены белән бүләкләнүчеләр арасында Ә.Р. Тенишев (Россия), Джеффри Льюис (Бөекбритания), Жан-Поль Ру (Франция), Геза Давид (Венгрия), Омельян Прицак (АКШ), Бубуйна Орузбаева (Кыргызстан), Камил Вели Нериманоглу (Азәрбайҗан), Андреас Рона-Таш (Венгрия), Виктор Гузев (Россия), Роберт Данков һәм Вальтер Дж. Эндрюс (АКШ), Ларс Йохансон (Швеция), Георг Хазаи (Венгрия), Абдурехити Якуфу (Кытай), Эвангелиа Балта (Греция), Клаудиа Ремер (Австрия) һ. б. бар.

Дмитрий Михайлович Насиловны бүләкләү тантанасында 500 дән артык кеше була – Төркия парламенты спикеры, Төркия вице-премьеры, министрлар, депутатлар, илчеләр, язучылар, фән һәм сәнгать учреждениеләре башлыклары, дөнья университетларының тюркология бүлекләре җитәкчеләре, укытучылар катнаша. Төркия Президенты Абдуллаһ Гүл үзенең чыгышында болай ди: «Кадерле дустыбыз Дмитрий Михайлович Насилов 56 еллык һөнәри тормышында үзенең хезмәтләре һәм язмалары белән тюркологиягә зур өлеш кертте, һәм менә дигән шәкертләр тәрбияләп, безне сөендерде. Мин Сезне котлыйм һәм фәнни эшчәнлегегездә алга таба да уңышлар телим» [12: 108].

Хаҗеттепе университетының төрек теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, «Российская тюркология» журналының редакцион советы әгъзасы, профессор, фән докторы Шөкрү Халюк Акалын, котлап чыгыш ясаганда, талантлы галимнең фәнни хезмәтләренең әһәмиятен һәм аңа хас кешелеклелек сыйфатларын аерым ассызыклый: «Дмитрий Михайлович Насилов, Төрки телләр үсешен тарихи чорларга бүлү мәсьәләләре буенча үзенчәлекле, компетентлы һәм кыйммәтле фәнни хезмәтләре аркасында төрки дөньяда әһәмиятле урында тора,

шуның белән бергә ул кешеләргә үтә гади, ихтирамлы, кисәтүчән мөнәсәбәте белән бөтен фәнни дөньяның хөрмәтен яулады» [7: 108].

Дмитрий Михайлович Насилов – төрки телләр теориясе һәм тарихы өлкәсендә зур белгеч, 250 дән артык фәнни һәм фәнни-методик хезмәтләр, сүзлекләр һәм монографияләр авторы, күп еллар М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының Азия һәм Африка илләре институтында төрки филология кафедрасын җитәкли. Аның җитәкчелегендә бик яхшы галимнәр һәм укытучылар плеядасы әзерләнгән. Докторантларга, аспирантларга, диплом һәм курс эшләренә җитәкчелек иткән. Аның сигез аспиранты кандидатлык диссертацияләре яклаган. Ул зур фәнни-укыту, оештыру, мөхәррирлек, җәмәгать эшләре алып бара, шул ук вакытта бик тыйнак кеше булып кала. Аның фәнни хезмәтләре дөнья тюркологиясен шактый баета, берничә мәкаләсе Төркия, Венгрия, Германия һәм башка илләрнең фәнни басмаларында басылып чыга. Ватаныбыз Д.М. Насиловның фәнни казанышларын югары бәяли. Күпьеллык намуслы хезмәте өчен Дмитрий Михайлович «Хезмәт ветераны», «Мәскәүнең 850 еллыгы истәлегенә» медальләре, Төркия Республикасының «Лиякат» Дәүләт ордены белән бүләкләнә.

**Әдәбият**

1. Диляра Гарифовна Тумашева. Серия «Биобиблиографические указатели ученых Академии наук Татарстана» / гл. ред. серии М.Х. Хасанов; сост. Ф.М. Хисамова. Казань: Фэн, 2003. 56 с.

2. *Насилов Д.М.* Программный труд академика Д.Г. Тумашевой // Диалектология, история и грамматическая структура тюркских языков. Сб. материалов междунар. тюркологической конф. 21–24 октября 2011 г. Казань, 2011. С. 9–12.

3. Реферативный журнал «Языкознание». М.: Наука, 2014. № 4.

4. *Тумашева Д.Г.* Татарский глагол. Опыт функционально-семантического исследования грамматических категорий / Учеб. пособие. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1986. 189 с.

5. Тумашевские чтения: актуальные проблемы развития языка, фольклора, литературы, искусства сибирских татар: материалы II Всерос. науч.-практ. конф. (Тюмень, 17 окт. 2008). Тюмень, 2008. 258 с.

6. *Шеймович А.В.* К 85-летию Галины Федоровны Благовой: научные итоги десятилетия. (Автор по нашей просьбе предоставил нам электронную версию своей статьи).

7. *Шюкрю Халык Акалын.* Дмитрий Михайлович Насилов награжден орденом Турецкой Республики «Лиякат» // Российская тюркология. Москва–Казань, 2014. № 1 (10). 116 с.

**Д.М. Насиловның төп фәнни хезмәтләре исемлеге**

Монографияләр, коллектив монографияләр, уку әсбаплары

Структура времён индикатива в древнеуйгурском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1963.

Древнетюркский словарь: словарные статьи, редактор / коллектив авт. и ред. Л., 1969.

Проблемы тюркской аспектологии: Акциональность. Л.: Наука ЛО, 1989. 208 с.

Проблемы тюркской аспектологии: Акциональность: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. М., 1989. 32 с.

Expression of situational plurality in Turkic languages // Typology of Iterative Constructions / соавт.: Х.Ф. Исхакова, В.И. Рассадин. München, 1997.

Imperative sentences in Turkic languages // Typology of imperative sentences. / соавт.: И.А. Невская, Х.Ф. Исхакова, Ш. Сафаров. München: Lincom Press, 2001. P. 181–220. [на англ. яз.]

Концепция модели этнической школы для коренных малочисленных народов Севера РФ / коллектив авт. М., 2001.

Карлукско-уйгурская группа: Фонетика. Глагол // Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Региональные реконструкции. М., 2002. С. 339–418.

Репрессированная тюркология / соавт.: Ф.Д. Ашнин, В. М. Алпатов. М., 2002.

Национальная школа: направления совершенствования структуры и содержания образования // Федеральная программа развития образования / коллектив авт.-сост. М., 2003.

Словарные статьи: *Л, М, Н, П* // Этимологический словарь тюркских языков / коллектив авт. М., 2003.

Уступительные конструкции в тюркских языках // Типология уступительных конструкций / соавт.: И.А. Невская, Х.Ф. Исхакова. СПб.: Наука, 2004. С. 425–452.

Программа лингвистического курса «Древнетюркские языки» // Программы курса турецкого языка и теоретических курсов / сост. Ю.В. Щека. М.: ИСАА МГУ, 2005. С. 51−54.

Программа спецкурса «Основы тюркской семантики» // Программы курса турецкого языка и теоретических курсов / сост. Ю.В. Щека. М.: ИСАА МГУ, 2005. С. 55−63.

***Алишина Хәнисә Чайдат кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Төмән дәүләт университеты профессоры*

***Алишина Ханиса Чайдатовна,***
*доктор филологических наук,*
*профессор Тюменского государственного университета*
*kaf_tatarlit@utmn.ru*

УДК 821.512.145

***Н.М. Юсупова***

# КӘШШАФ ПАТИИ: ШАГЫЙРЬ, УКЫТУЧЫ, МУЛЛА

Статья посвящена изучению жизненного пути татарского поэта начала XX века Кашшафа Патии, имя которого до сих пор осталось в тени. В ходе исследования дается экскурс творчеству поэта, на примере отдельных его произведений выявляются основные тенденции развития его поэзии. Кашшаф Патии, жизненный путь и творчество которого является объектом нашего исследования, стоял в передовых рядах татарской просветительской мысли начала XX века.

Решая задачу воссоздания целостной картины развития национальной поэзии, татарское литературоведение обращается к малоизученным поэтическим наследиям. Изучение жизненного и творческого пути неизвестных до сих пор широкому кругу читателей или преданных забвению поэтов, возвращение в научный оборот тех или иных творческих личностей позволяет воссоздать, реконструировать литературный процесс, выявить национальные особенности татарской поэзии начала XX века. Этим объясняется актуальность нашего исследования.

Целью данной статьи является реконструкция жизненного и творческого пути Кашшафа Патии и введение в научный оборот отдельных, до сих пор неизученных поэтических произведений поэта.

Научная новизна статьи определяется тем, что в ней жизненный путь Кашшафа Патии впервые становится объектом системного изучения. Кроме того отдельные стихотворения поэта анализируются в рамках просветительской парадигмы с применением структурно-семиотического подхода.

**Ключевые слова:** татарская поэзия начала XX века, поэт, Кашшаф Патии, жизненный путь, друг Тукая.

The article is devoted to the study of the life path of the Tatar poet of the early twentieth century Kashshaf Patiya, whose name has remained in the shadows to this day. The study provides an overview of the poet’s work, using the example of his individual works to identify the main trends in the development of his poetry. Kashshaf Patiya, whose life and work are the objects of our research, stood in the forefront of Tatar enlightenment thought at the beginning of the twentieth century. Solving the problem of recreating a holistic picture of the development of national poetry, Tatar literary criticism turns to little-studied poetic heritage. The study of the life and creative path of hitherto unknown to a wide range of readers or forgotten poets, the return to scientific circulation of certain creative personalities allows us to recreate, reconstruct the literary process and identify the national characteristics of Tatar poetry of the early twentieth century. This explains the relevance of our research. The purpose of this article is to reconstruct the life and creative path of Kashshaf Patiya and to introduce into scientific circulation some of the poet’s hitherto unexplored poetic works. The scientific novelty of the article is determined by the fact that Kashshaf Patiya’s life path becomes the object of systematic study for the first time. In addition, individual poems of the poet are analyzed within the framework of the educational paradigm using a structural and semiotic approach.

**Keywords:** tatar poetry of the early twentieth century, poet, Kashshaf Patiya, life path, friend of Tukai.

XX йөз башы татар шигърияте фикерләү киңлеге, фәлсәфи тирәнлеге белән дә, яңа агым һәм алымнарны әдәби мәйданда чарлавы белән дә сүз сәнгате тарихында аерым чорны тәшкил итә. Бу яңарышны иҗаты белән үз сүзен әйтеп, милли әдәбият үсешенә саллы өлешен керткән әдипләр янәшәсендә татар әдәбиятына борылыш алып килү нияте белән янган, аны дөнья әдәбиятлары югарылыгына чыгару омтылышы белән яшәгән яшь авторлар әйдәп бара. Р. Гайнанов төзегән исемлеккә нигезләнеп, аларның 300 дән артып китүен дә исәпкә алсак [14: 4], XX йөз башында татар шигъриятенең куәтле бер көч булуы аңлашыла. Шуңа да XX йөз башы әдәбият тарихында күпсанлы сүз осталарының төрле яклап колачлы эзләнүләр алып бару дәвере буларак бәяләнә дә. Кызганычка каршы, күбесенең иҗади мирасы, гарәп графикасындагы кульъязмалары, бүген дә үз тикшеренүчесен көтеп, киштәләрдә кала бирә. Мондый каләм ияләре арасында Тукай шигъри мәктәбе вәкиле Кәшшаф Патии исеме дә бар.

Габделкәшшаф Мөхәммәтшәриф улы Патиев (Кәшшаф Патии исемен ул үзенә әдәби псевдоним итеп ала) – шагыйрь, укытучы, мулла – 1884 елның 29 декабрендә Саратов губернасы Зимничә авылында (хәзерге Ульяновск өлкәсе) мулла Мөхәммәтшәриф белән Хәлифә гаиләсендә дөньяга килә [9: 142]. Гаиләдә бердәнбер ир бала була, шуңа этисе белән әнисенең игътибар үзәгендә үсә, Кәшшафның кечкенәдән думбра, мандолина кебек уен коралларында өйрәнүе бу гаиләнең үз чоры өчен шактый алдынгы карашлы булуы турында сөйли.

Башлангыч белемне үзенең этисеннән алган Кәшшаф 1905 елда Казанга килә [1] һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. Уку йортында 9 ел – 1905 елдан 1914 елга кадәр белем ала, 1915 елга кадәр Казанда яшәве мәгълүм. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә уку дәверендә булачак шагыйрьнең Ф. Әмирхан җитәкчелегендәге әдәби түгәрәк эшендә катнашуы турында билгеле.

Мәдрәсәдә укыганда ук, төгәлрәге 1907 елда, Кәшшаф туган авылында мулла вазифасын да башкара. З. Рәмиев фикеренчә, ул Зимничәдә 1909 елда мулла була [14: 197]. Әмма Кәшшафның муллалык эшенә нәкъ менә 1907 елда керешүе Зимничә авылының 1 нче мәчете метрика китабындагы (1912 ел өчен) белешмә белән раслана. Шагыйрьнең этисе – Мөхәммәтшәриф Патиев – беренче имам, 28 яшьлек Габделкәшшаф икенче имам буларак теркәлгән. Шунда ук без Кәшшафның имам вазифасына керешеп китү датасын да күрә алабыз: «Галимҗан хәзрәт мәдрәсәсендә» укучы Габделкәшшафның имам вазифасына 1907 елның 10 маеннан № 5398 номерлы указ нигезендә раслануы турында белешмә беркетелгән [9: 144]. 1908 елда 23 яшьлек Кәшшаф Саратов губернасының Иске Мәстәк авылында китапханә ачу эшләрендә дә башлап йөри, аның исеме китапханәне гамәлгә куючылар исемлегенә теркәлгән [13: 148].

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә уку чорында типографияләрдә эшләгән һәм Ф. Әмирхан җитәкчелегендәге әдәби түгәрәккә йөргән Кәшшаф Г. Тукай даирәсенә килеп керә. Бер үк вакытта медицина

белән кызыксынып китә, хәтта ирекле тыңлаучы сыйфатында Казан император университетының медицина факультетына лекцияләргә йөри. Тукай даирәсендәгеләрнең аны шагыйрьнең «сәламәтлек буенча урынбасары» дип тә йөртүе билгеле. Шагыйрьнең кызы Роза әтисенең Тукай үлгәнче аның янәшәсендә булуы турында сөйли.

Кәшшафның яңа фикерле яшьләр даирәсенә килеп эләгүе мәдрәсә укытучылары арасында «борчу тудыра» һәм алар егетнең әтисенә хат юллый. Мулла, улының кире туган авылына әйләнеп кайтуын таләп итеп, хатлар яза. Кәшшаф берничә ел әтисенең теләгенә каршы килеп, шигырь язып, типографияләрдә эшләп, шулардан килгән акчага яшәргә омтылып карый, әмма ахырда, әтисе матди яктан бөтенләй ярдәм итми башлагач, 1915 елда туган ягына кайтып китәргә мәҗбүр була. Туган авылы Зимничәдә мәктәп ачып җибәрә һәм балалар укыту белән шөгыльләнә башлый [16: 267].

Гаилә тарихына килсәк, 1909 елда Кәшшаф Сәхибҗамал (1888–1939) исемле кызга өйләнә, беренче никахыннан 5 балалары туа: Нургали, Тәүфикъ, Гобәйдә, Маһирә, Надирә.

Новосибирск шәһәренә командировкага баргач, Кәшшаф Зәйнәп (1901–1966) исемле үзеннән шактый яшь ятимә кыз белән таныша, аңа өйләнергә карар кыла. Зәйнәп, Кәшшафның өйләнгән кеше икәнлеген дә белмичә, икенче хатын сыйфатында Зимничә авылына кайта, бер-бер артлы өч бала таба. Бер гаиләдә ике хатын мөмкин булган кадәр тынычлыкны саклап, яхшы мөгамәләдә яшәргә тырышалар. Балалар да дус-тату булып, аралашып яшиләр һәм туганлык җепләрен саклыйлар. Шушы елларда Кәшшаф Зимничә авылында яңача укытуга корылган мәктәп ачу артыннан йөри, хәтта Хвалыннан яңа карашлы укытучыларны эшкә чакыра. Шушы гамәлләре өчен үз авылында эзәрлекләүләргә дә дучар була, әмма башлаган эшен ахырына җиткерә: мәктәпне ачып, эшләтеп җибәрүгә ирешә [9: 149].

1920–1921 елгы ачлык чорында, наданлыкны бетерү шаукымына ияреп, берничә укытучы гаиләсе Үзбәкстанның Хива шәһәренә китәргә карар кыла, алар арасында Кәшшаф белән Зәйнәп тә була. Чит җирләрдә бик авыр шартларда эшләргә туры килә, шушы елларда активлашып киткән басмачылар хәрәкәте аеруча кыенлыклар тудыра, шулай да алар үз юлларыннан тайпылмыйлар, Хива шәһәрендә 1927 елга кадәр эшләп, кабат туган якларына әйләнеп кайталар.

Әмма тынычлап яшәргә насыйп булмый, 1929 ел Патиевлар гаиләсенә зур кайгы алып килә: мулла гаиләсе буларак, өлкән яшьтәгеләр белән бергә аларны да Архангельск шәһәренә сөрәләр. Гаилә архивында Патиевлар гаиләсен сөрүгә бәйле 1929 елның 28 ноябре белән имзаланган архив документының күчермәсе саклана [9: 151]. Әлеге документта мулла гаиләсенең «Совет властена каршы эш алып баруда» гаепләнүе күрсәтелә [9: 150]. Юлда барганда, укытучылык эше белән шөгыльләнүен, прогрессив, инкыйлаби шигырьләр язуын истә тотып, Кәшшафны азат итәләр. Зәйнәп белән никахтан туган ике

кызлары юлдагы авырлыклардан үлеп кала, Зәйнәп үзе, гаепләнүчеләр исемлегендә булмавын белеп алып, улы Иркин белән Новосибирск шәһәренә туганнары янына качып китә. Сәхибҗамал исә балалары белән Архангельск шәһәренә барып төпләнә, кызганыч ки, Кәшшаф бу гаиләсе белән авырлыкларны бүлешми. Сәхибҗамалга балаларны ялгызы үстерергә, яңа җирдә аякка басырга туры килә. 1939 елда хатын каты авырып вафат була, озак еллар сәяси репрессия корбаннары исемлегендә йөри һәм 1996 елда гына реабилитацияләнә.

Кәшшаф Новосибирск шәһәреннән Зәйнәпне эзләп таба, һәм гаилә Үзбәкстанга күчеп китә. Шушы китүдән алар биредә төпләнә: 1933–1955 елларда Ташкент, соңрак Әндиҗан, Каракалпак-Найман шәһәрләрендә яшиләр, укытучылык эшчәнлеген дәвам итәләр [16: 292]. Кәшшаф һәм Зәйнәпнең җәмгысе 11 балалары туып, күбесе, ачлык елларын кичерә алмый вафат була, бары Иркин (1926–2001), Роза (1935–2017), Илтөзәр (1937–1996) генә гомерле булып чыга. Кәшшафка Үзбәкстанда да шактый кыенлыклар кичерергә туры килә: шәхес культы, сугыш һәм сугыштан соңгы авыр еллар бу гаиләгә дә кагыла. Беренче гаиләсендә калган улы Нургали сугышта һәлак була, Иркин, күп яралар алып булса да, исән-сау әйләнеп кайта.

Сугыштан соңгы елларда Кәшшафка колхозда агроном, бригадир вазифаларын да башкарырга туры килә, виноград үстерү, умартачылык белән шөгыльләнә, берара Зур Фирганә каналы төзелешендә катнашуы, агитация эше белән шөгыльләнүе дә билгеле.

1955 елда, яңа йорт төзеп, гаилә Куйган Ярга күченә, әмма бәхет озакка бармый. 1966 елда Зәйнәп дөнья куя, 1971 елның 13 февралендә 87 яшендә Кәшшаф та бакыйлыкка күчә.

Шагыйрь буларак Кәшшаф Патии исеме 1907 елдан күренә башлый: «Әлгасрелҗәдид» журналының 25 гыйнвар санында аның беренче шигыре басылып чыга. Шуннан башлап, төрле исемнәр астында, «Кашшаф Патин, К. Патин, К. Патии тәхәллүсләре» [10: 144] белән шагыйрьнең шигырьләре дөнья күрә. Хәйрулла Йосфи наширлегендә эшләнгән һәм 18 шигырьне берләштергән беренче шигырьләр китабы 1910 елда «Кәшшаф Патии шигырьләре» исеме белән Кәримовлар матбагасында басылып чыга [3]. 1915 елда аның 30 лап шигырен туплаган «Әшгарь» исемле икенче шигырьләр җыентыгы татар укучысына килеп ирешә [4]. Моннан тыш текстологлар тарафыннан Габделкәшшаф Зимничәви авторлыгында 1906 һәм 1912 елларда басылган «Тугыз чәчәк» җыентыгы да Патиига нисбәтле дип карала [12: 519; 14: 197].

Кәшшаф Патиинең беренче чор әсәрләре мәгърифәтчелек идеалларына йөз тотып языла, күп шигырьләрдә мәгърифәтчелеккә хас дөнья сурәте тудыру көчле, чөнки мәгърифәтчелек карашлары шагыйрь мәйданга чыккан 1907 елларда әле татар җәмгыяте өчен гаҗәп актуаль була. Мәгърифәтчелек агымы кысаларында язылган шигырьләрендә аң-белем, тәрбия, кадимчелек проблемалары күтәрелә, татарның алгарышы мәгърифәтчелек идеаллары белән бәйләп аңлатыла. Мондый шигырьләрдә лирик герой татар халкын алга җибәрү,

җәмгыятьне яңарту, кешеләр яшәешен камилләштерү максатына йөз тота. Шигырьләрдә күтәрелгән мотивлар да мәгърифәтчелек кысаларында яңгырый: татар җәмгыятенең аң-белем дәрәҗәсен үстерү («Ерак мәмләкәттәге дустыма», «Дустыма», «Мөхәммәдиядән: Сөальләр», «Каләмгә», «Сукачыга», «Яңа тормышка»), татар җәмгыятен рухи яңарышка өндәү («Гыйбрәт», «Гаҗиз милләткә»), хатын-кыз азатлыгы («Чапан»), кадимчелек («Ватсаң») мотивлары шундыйлардан.

Мисалга шагыйрьнең «Каләмгә!» шигырен алыйк. Әсәрдә риторик эндәш алымы ярдәмендә лирик герой каләмгә мөрәҗәгать итә, аны «сызарга, язарга, гаҗәп серне сөйләргә» өнди. Шигырьдәге төп оппозиция традицион эчтәлекле: искелек / яңалык (кадимчелек / җәдитчелек). Шагыйрь аларның татар кешесен, татар дөньясын рухи үзгәрешкә яки торгынлыкка илтерлек ике юл булуын күрсәтә:

Гыйбадәт урынына шалтырдаталар
Күк төймәләрне,
Мөкатдәс кануныңны боргалыйлар
Арлы да бирле.
Яна йөрәк, яна, түзми,
Сүнәрме әй бетәр тизме?
Югыйсә алдыйлар хәзер
Кадыйлар йөзтүбән йөзне [3: 16].

Лирик герой тарафыннан дини үзгәрешләр кирәклеге ассызыклана, нәкъ менә шул үзгәрешләр яңарышның иң беренче һәм мөһим нигезе итеп куела, татар җәмәгатьчелегендәге үзгәрешләрнең дини үзгәрешләрдән башланырга тиешлеге раслана. Шагыйрь каләмне, әдәби иҗатны шушы үзгәрешләрне әйдәп барырлык, мондый олы бурычны үз өстенә алырлык көч сыйфатында күрә, шул рәвешле шигъри сүзнең, әдәбиятның ролен югары күтәрә.

Кәшшаф Патии иҗатында аерым бер бәйләмне сатирик әсәрләр тәшкил итеп, алар тәнкыйть мотивы тирәсенә туплана. Лирик геройның тәнкыйте надан муллаларга, иске карашлы татар җәмгыятенә, әхлаксызлыкка, дини фанатизмга, икейөзлелеккә каршы юнәлтелә. Мисал өчен, «Мөхәммәдиядән» шигырендә татар җәмгыятендәге катлаулар ачы көлү объекты булып яңгырый:

Бере – ишан, гаҗәп хөрмәт вә сыйда,
Павыска тулыдыр каз, коркасы да.

Бере – мөрид, өмет итәр ишандан,
Бер өч пуз казга насыйб иршадындан.

Бере – суфи, кавын төшен да ярмый,
Кеше күргәндә һич гөнаһка бармый.

Бере – шәкерт, егерме ел укыйдыр,
Түбән карый, күтәрми баш, суфидыр.

Бере мәдрәсәдә, хәлфә исемле,
Утыз биш-кырык сәнә гомер киченде.

Бере – мулла, утыра түр башында,
Егерме ел нәтиҗәсе дә шунда.

Бере – фәкыйрь, ач үләргә теләми,
Эш эшләми, бай абзыйдан теләге.

Бере – байбәтчә, туймыйдыр ләззәттән,
Өчәр хатын аладыр ул симездән [3: 5].

Әлеге шигырьдә мулла-ишаннарның һәм шәкертләрнең жыелма образлары тудырыла, Кәшшаф Патии татар динчеләреннән, шәкертләрдән, бай-сәүдәгәрләрдән, аларның яшәү рәвешеннән ачы көлә, татар дөньясындагы төрле катлау ияләренең дөньяга карашын, ваемсызлыгын, бер көн белән яшәү омтылышын тәнкыйтьли. Шигырь каләм һәм әдәбиятның татар яшәешен төбеннән-тамырыннан үзгәртергә тиешлеген раслау белән тәмамлана.

Шагыйрь иҗатындагы өченче төркем шигырьләр мәгърифәтчелек романтизмы кысаларында иҗат ителә, мондый шигырьләрдә лирик герой милли музыкага, милли яшәешкә гашыйк кеше буларак кабул ителә. Алар, нигездә, ялгызлык халәтендәге, бу дөньяда бәхет таба алмый читләшкән лирик геройның кичерешләре хакында бәян итә. Мәсәлән, «Мандалин» шигырен алыйк. Дөньяда яшәү ямен югалткан, кайгылы, эче пошкан, күңеле таш булып каткан лирик герой шигырьнең буеннан-буена мандолинга мөрәҗәгать итә, аннан татар дөньясын дәрт-моңга, ләззәткә күмүен, үлгән күңелләрне уятуын үтенә. Һәр тезмәдә капма-каршы куелган сурәтләр аркылы рухсызлык һәм милли моң мәсьәләсе күтәрелә. Шигырь кысаларында музыканы, сәнгатьне югары күтәрү, аның көчен өстен итеп күрсәтү ачык күренә, үсештән туктаган, үлгән милләтне татар музыкасы, сәнгать, татар җыры уята, кузгата, алга җибәрә ала, дигән фикер төп идея булып яңгырый:

Милли дим, тәэсирләнәм, күз
карасын яшьләткәлим.
Милли-милли әйттерәм мин,
Там-тарим, там, там-тарим.

Таш күңелне шундый пакь
тавыш белән йомшарткалыйм.
Яртылап сүнгән рухымны
Тергезәм, нурлаткалыйм [4: 10].

Шул рәвешле, Кәшшаф Патии шактый катлаулы һәм каршылыклы гомер юлы үтә, татар шигъриятен үстерүгә үзенең өлешен кертә. Әмма 1915 елдан соң ул актив иҗат эшчәнлегеннән читләшә, 1917 елгы вакыйгалардан соң, мулла буларак, авырлыклар алдында кала, гел күченеп йөрергә мәҗбүр була. Үзбәкстанга күченгәннән соң, үзе өчен генә язса да, шигырьләрен газета-журналларда бастырмый.

XX йөз башында иҗат эше белән шөгыльләнеп тә, игътибардан читтә торган Г. Харис, Д. Гобәйди, Ф. Ибраһимов, Б. Мирзанов, Ф. Агиев, З. Бәшири һ. б. кебек йөзләгән татар шагыйрьләре кебек,

Кәшшаф Патии иҗаты да, тормыш юлы да моңа кадәр күләгәдә кала килде. Ләкин аларның иҗади мирасын бөтенлекле күзалламый торып, бу чор татар шигъриятенең үсеш-үзгәреш юлларын тулысынча ачу мөмкин түгел.

**Әдәбият**


1. *Әскәров М.* Патиевлар // Ватаным Татарстан. 2000. 11 август.

2. *Патии К.* Әлгасрелҗәдид журналына // Әлгасрелҗәдид. 1907. 25 гыйнв.

3. *Патии К.* Кәшшаф Патии шигырьләре. Казан: Электро-тип. «Урнэк», 1910. 16 б.

4. *Патии К.* Әшгарь. Казан: Кәримовлар матбагасы, 1915. 31 б.

5. *Патии К.* Тормыш // Идел. 1910. № 252.

6. *Патии К.* Музыка // Идел. 1910. № 238.

7. Патии К. Билгеле // Шура. 1914. № 14.

8. Патии К. Тукайга // Сабыйлар догасы. Казан, 1915. Б. 4.

9. Род Патиевых / Шәхси архив. 240 с.

10. Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. 10 нчы чыг. Татар әдәбиятында тәхәллүсләр / төз.: Л.Ш. Гарипова, Г.Н. Зәйниева. Казан: ТӘһСИ, 2021. 300 б.

11. Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 4 т.: XX йөз башы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 533 б.

12. Татар поэзиясе антологиясе: 2 томда. 1т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 544 б.

13. Татары Саратовского Поволжья: энциклопедический справочник / ред. совет: Ф.А. Рашитов (председатель) [и др.]. Саратов: КУБиК, 2020. 252 с.

14. Татар шигърияте: XX йөз башы / төз. З.З. Рәмиев. Казан: Мәгариф, 2004. 447 б.

15. *Юсупова Н.М.* Забытые имена: Кашшаф Патии // Филология и культура. Philology and Cultura. 2024. № 2 (76). С. 266–271.

16. *Юсупова Н.М.* Кәшшаф Патии: тормыш юлы һәм иҗаты // Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика: материалы IV Междунар. науч.-практ. семинара, посвящ. 85-летию Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова (9–10 октября 2024 г., Казань) / сост. Л.И. Фахрутдинова. Казань: ИЯЛИ, 2024. С. 291–296.

17. Яңа әсәр // Идел. 1910. № 241.



*Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде.*

*Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024*



***Юсупова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар әдәбияты кафедрасы профессоры*

***Юсупова Нурфия Марсовна,***
*доктор филологических наук, профессор кафедры татарской литературы Института Филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета*

*faikovich@mail.ru*

УДК 821.512.145

*Д.Ф. Заһидуллина*

## ФАТИХ ӘМИРХАН: ТАТАР ХАЛКЫ ӨЧЕН ЯНЫП ЯШӘҮ

Статья посвящена жизни и творчеству татарского прозаика и драматурга, публициста и журналиста Фатиха Амирхана. Рассматриваются малоизвестные факты из жизни, журналистской деятельности, сделана попытка обобщающей оценки творческой эволюции писателя. Установлено, что Ф. Амирхан стал одним из первых авторов татарской романтической прозы, мастером психологизма. Впервые в татарской драматургии он представил к вниманию татарского читателя психологические драмы. Ф. Амирхан обращается к художественному потенциалу разных литературных направлений: реализма, романтизма, модернизма. Он является сторонником идеи прогресса татарского народа, в критике и публицистике выступал за развитие национального образования, науки, культуры.

**Ключевые слова:** татарская литература, Фатих Амирхан, возрождение нач. XX века, психологизм, романтизм.

The article is devoted to the life and work of the Tatar novelist and playwright, publicist and journalist Fatih Amirkhan. Little-known facts from life and journalistic activity are considered and an attempt is made to generalize the assessment of the writer's creative evolution. It is established that F. Amirkhan became one of the first authors of Tatar romantic prose, a master of psychology. For the first time in Tatar drama he presented psychological dramas to the attention of the Tatar reader. F. Amirkhan addresses the artistic potential of various literary trends: realism, romanticism, modernism. He is a supporter of the idea of the progress of the Tatar people, in criticism and journalism he advocated the development of national education, science and culture.

**Keywords:** Tatar literature, Fatih Amirkhan, renaissance of the beginning. Twentieth century, psychologism, romanticism.

*(Дәвамы. Башы журналның 1 нче санында)*

### «Хәят»

Ф. Әмирхан прозасының гына түгел, татар әдәбиятының таҗы – «Хәят» повестен әдип 1909 елда яза башлап, 1911 елның 18 июлендә тәмам итә. Повесть шул ук елны 88 битле җыентык рәвешендә дөнья күрә һәм тиз арада укучыларның яраткан китабына әверелә. Татар дөньясында язучының әсәрнең икенче кисәген язуы хакында сүз тарала, укучылар тизрәк аның тәмамлануын көтәләр. Әмма бу мәсьәлә ачык кала.

Инде совет чорында язучы һәм әдәбият галиме М. Мәһдиев журналист Сәхи Рәхмәтинең А. Шамовка юллаган хатыннан кызыклы мәгълүматлар китерә: «...Ләкин “Хәят”ның икенче бүлеге чыкмый калды. Сәбәбе шул: 1911 елда “Хәят”ның беренче бүлеге басылып

чыгып бераз вакыт магазиннарда сатылгач та, бу китапта тасвир ителгән Хәят Г.ның хатыны Ү. ханым икәнлеге бөтен Оренбург халкына, бигрәк тә әдәбият белән шөгыльләнүчеләргә мәгълүм була. Күп тә вакыт үтми, Г. “Хәят”ның магазиннарда булган бөтен нөсхәләрен сатып алып яндырта һәм “Хәят”ның икенче кисәгенең кулъязмасын бөтен хокуклары белән ун мең сумга сатып алды, дигән хәбәр тарала» [7: 67]. Өзектән күренгәнчә, киләчәктә әсәр дәвамының табылуы зур шик астына куела.

2001 елда Галимҗан Шәрәфнең улы Арыслан ТР Милли музеена тапшырган материаллар арасында повестьның 6 дәфтәргә теркәлгән икенче өлеше табыла һәм 2016 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнеп, бастырып чыгарыла [14].

Повестьта сурәтләнгән тормыш яшьлек, аның да мәхәббәт көтү дәверенә кагыла. 16 яше дә тулмаган Хәятның күңелендә Михаилга, Галигә карата кызыксыну уяну, акылның бу кызыксынуны ярату хисенә үстерми туктатып калуы, чибәр һәм самими кызның, үзе ярәшелгән егеткә мәхәббәт бирүен сорап, Аллага ялваруы... Төп сюжет сызыгын Хәят күңелендә барган үзгәрешләр тәшкил итү авторның романтизм сукмагында каләм сынавын дәлилли.

Повестьның беренче өлеше унҗиде бүлеккә аерылган, һәрберсенең исеме бар. Күпчелек бүлекләрдә катнашучыларның репликалары исемгә чыгарылган (1 нче бүлек: «Ах, Хәят, нинди матур син...»; 6 нчы бүлек «Хәят, мин сезне сөям!»; 9 бүлек «Алар безгә, без аларга буласы түгел»; 10 бүлек «Без нәрсәгә әни сүзенә карыйбыз?»; 12 нче бүлек «Без белешмәсәк тә, белешүче табылган»; 16 нчы бүлек «Барыбер кайчан да булса бер бармый хәл юк»). Бу репликалар вакыйгаларга катнашучыларның билгеле бер караш ноктасын күрсәтеп тора. Бүлек исемнәрендә үк тормышның каршылыклы кабул ителүе ассызыклана.

Повестьның моңа кадәр билгеле өлешендә төп сюжет сызыгы Хәят күңелендәге мәхәббәт көтүдән кияүгә чыгарга карар кылуга кадәрге аралыкны колачлый. Бу сюжетны «мәхәббәт көтү тарихы» дип атарга мөмкин. Аны хәрәкәткә китерүче конфликт Хәяттагы хис һәм акыл көрәше, гаилә (иске татар көнитеше, татар җәмгыятендәге кануннар, тирәлек) белән Хәят күзаллаган идеал тормыш арасында булып чыга. Хис һәм акыл үзгәреше бәхеткә, иреккә, үзең теләгәнчә яшәргә омтылышның – моның мөмкин түгеллеген аңлау, ризалашу, буйсыну белән алмашынуы арасында тирбәлә. Вакыйгалар үстерелеше Салих Фатихов фотосын күргәннән соңгы икеләнүләрдә иң югары ноктага – кульминациягә җитә. Чишелеш – Хәятның үзе күрмәгән-белмәгән, әмма ата-аналары бирергә теләгән егеткә кияүгә чыгарга карар итүе. Ләкин әсәр соңында кызның Аллага ялваруы («Илаһи, мәхәббәт бир!») каршылыкның чишелүе дә, ата-ана кушуы белән мәхәббәткә ирешү дә мөмкин түгеллекне раслый.

Тышкы каршылыклар исә Хәят һәм аның тирәлеге, иң элек, гаиләгә бәйле туа. Хәятның әти-әнисе аны традицион дини карашларга

туры китереп тәрбияли: бу, беренче чиратта, намаз һәм дини китаплар укытуда, мөселман ир-егетләре белән танышырга рөхсәт итмәүдә (хәтта очраклы очрашулар вакытында чит кешеләрдән йөзне каплау) күренә. Бер үк вакытта Хәят балачактан Лиза Мясникова белән дус, аның гаиләсе, абыйсы Михаил белән таныш. Мясниковлар гаиләсе тормышы Хәятлар көнитешеннән нык аерыла: Лиза һәм Михаил дөньяви белем алалар, өйләрендә еш кына яшьләр өчен бию кичәләре оештырыла.

Мясниковлар белән аралашу Хәят өчен эзсез үтми: ул русча иркен сөйләшә һәм укырга өйрәнә, әлегә кадәр дини-дидактик эчтәлекле «Дөррәтен-нәсыйхин»нар белән чикләнгән кыз яңа китаплар дөньясына килеп керә, ул үзен рус студентлары белән аралашканда да бик иркен тота. Бер үк вакытта Хәятның иҗтимагый хәле Әминә һәм аның апасы Рокыяның хәле белән аваздаш. Димәк, рус яшьләре белән иркен аралашсалар да, татар хатын-кызлары хокуксыз, сайлау ирегеннән мәхрүм булып чыга. Аларның киң тормышка омтылуы исә, язучы карашынча, күп яктан заманның тиз үзгәреше белән бәйле. Мәсәлән, Әминә студент Степанов белән мөнәсәбәтләре хакындагы сорауга болай җавап бирә: «Юк, белеш түгел; белешләнергә теләмим дә: андый егетләрне читтән торып сөяргә генә ярый... Сөй, сөймә, барыбер, туганым, алар безгә, без аларга буласы түгел бит инде» [14: 45]. Хәят та, Михаил турында уйлый башлауга, алар арасында мәхәббәт булу мөмкин түгеллекне, бу хиснең киләчәге юклыкны исенә төшерә: «Менә башка шушы соңгы уйлар килгәндә, Хәят кинәт Михаил белән үз арасында үтеп булмый торган чокыр барлыгын сизде. Ничектер, моны әүвәл бер пәрдә белән каплап торганнар да, кинәт ул пәрдәне тартып алып, аның артында капланып торган салкын һәм куркыныч нәрсәне күрсәтеп калдырганнар шикелле итеп, күңеленә килгән китеклекне ул хәзер генә аңлап җитте: “Михаил мөселман түгел бит, ул кяфер бит”» [14: 36].

16 нчы бүлектә Хәят белән Әминәнең сөйләшүе кызларның заманча уйлап та («...ул сине сөяме, син аны сөя аласыңмы икәнен белмәгән кешегә гомерлеккә хатын булу куркыныч»), ата-аналары теләгән кешегә кияүгә чыгуларын («Барыбер, кайчан да булса бер бармый хәл юк») [14: 72] аңлатып килә. Язучы моны әсәр буенча гаҗәеп оста файдаланылган күпсанлы, төрле характердагы детальләрдә ассызыклап бара. Менә бер мисал: «Бүлмәнең сул стенасына эленгән кыйммәтле урман рәсеменә каршы, уң стенага бик яхшы рам эченә тыгылган, хатты куфи белән язылган “Аятелкөрси” куелган иде дә, “урман”, хатты куфига карап, көлеп тора, хатты куфи, “урманга” карап, кашларын җыерып, ачуланып тора шикелле иде» [14: 44]. Лексик антиномия биредә XX йөз башы татар тормышына кагылышлы бәягә әйләнә: рәсем һәм дини аять янәшә урын яуларга, икесе гармониядә яшәргә омтылган вакытны белдерә.

Төп сюжет үзе өч ярдәмче сюжет сызыгына, ягъни шул ук акылхис каршылыгына нигезләнгән мөстәкыйль өч тарихка таркала.

«Михаилның Хәятка мәхәббәт аңлату тарихы», «Хәятның Гали Арсланов белән танышырга теләү тарихы», «Хәятның Салих Фатиховка кияүгә чыгарга карар кылу тарихы» алар. Ярдәмче сюжет сызыклары охшаш төзелгән: егетләр белән бәйле күңелдә кызыксыну уяну, өметләр һәм икеләнүләр агышы пәйда булу, карар кабул ителү кебек үсә һәм төгәлләнә.

Яңа табылган дәвам өлеше өч бүлекне колачлый: 18 нче бүлек «Йөрәк ашкынмый, ыргытылмый, артык сизелүлек бернәрсә тоймый...», 19 нчы бүлек «Ят, билгесез һәм куркыныч кеше», 20 нче бүлек «Сөям бугай...». Әлеге өч бүлекне «Хәятның Салих Фатиховка кияүгә чыгу тарихы» дип атап булыр иде. Һәр бүлек бер зур вакыйганы үзәккә куя: 18 нче бүлек – туй, 19 нчы бүлек – Идел буйлап пароходта сәяхәт, 20 нче бүлек – Салих өендә тормыш. Бу бүлекләрдә дә хәрәкәтне Хәятның каршылыклы мөнәсәбәте, хис һәм акыл көрәше барлыкка китерә. Акылның яратмаган Салихны аңларга тырышуга, аклауга, яратам дип уйлауга этәрүе, хиснең исә һәр мизгелдә кыз идеалы белән тәңгәл килмәгән детальләргә игътибар итә баруы күзгә ташлана. Мәсәлән, 18 нче бүлектә Хәятның беренче тәэсирләрен сурәтләгәндә үк әдип шушы эчке каршылыкны калкуландыра: «Шактый вакытлар узгач кына Хәятның күз алдын каплап тора торган томан акрын гына тарала башлады һәм бары шул вакытта гына ул Салихның матур һәм сөйкемле егет икәнен шактый ачык итеп күрде. Ләкин бу матурлык, бу сөйкемлелек Хәятта үткен бер тойгы тудыра алмады: күзләр рәхәтләнәләр, әмма йөрәк ашкынмый, ыргытылмый. Артык сизелерлек бернәрсә тоймый иде, ки тойгы ничектер бер читендәрәк яшеренеп, нәрсәгәдер юл куеп тора шикелле иде. Хәят кыска гына бер вакытта Салихның үзенә “ир”, үзенең аңар “хатын” икәнлеген дә уйлап алды. Ләкин бу уй да аның йөрәгендә әллә нинди үткен сизелерлек бер тойгы кузгата алмый, әллә ничек ялкау вә салкын уйлана иде: Салихның “ир-кияү” булучылыгы, Хәятның аңар “хатын” булучылыгы бертөрле заказ кушылып эшләтелгән, гадәт шулай булганлыктан эшләнгән нәрсә шикелле иде, ки болар һәр икесенә үткен йөрәкне катырак вә ешрак типтерерлек булып сизелми иде. Азан ишеткәч, дога укый башлау – ашап бетергәч, бит сыпырып кую кебек, теләү-теләмәүгә карамыйча, үз-үзеннән эшләнеп ташлана торган эшләр шикелле, Хәятның Салихка “хатын” вә Салихның аңар “ир” булуы да, теләү вә кирәксенүдән бигрәк, “тиешлек” өчен эшләнгән эш төсле иде, ки күңел вә тойгы әллә ничек катышмыйча читтә вә керешсез калган иде» [14: 81].

Тышкы каршылыклар да шул ук: хәзер инде Хәятның эти-әнисе, туганнары урынын – кайнанасы, аның күзаллаулары, мөнәсәбәте били. Беренче каршылык кияү белән күрешкәндә аның кулын үбәргәме, юкмы дигән сорау тирәсендә туа һәм Хәятның әнисе Газизә абыстай белән дусты Әминәнең фикерләре төрлелеге моның өлкән буын белән замана яшьләренең карашлар аерымлыгы булуын ассызыклый: «Хәят үзе дә Әминәчә уйласа да, эшкә килгәч, анасы сүзен

тотумы яки туганы сүзен тотумы яхшырак, килешлерәк буласын ачык билгеләп йиткерә алмый апдырады. Әллә нинди бер һавалылык аңар туганымы сүзен тотарга куша иде. Моңар кадәр аны чолгаган рус егетләре үзләре аның, Хәятның, кулын үбә иделәр; бүген генә инде ул иң әүвәл күргән бер егетнең кулын әүвәл күрешүдә үк һичбер сәбәпсез үзе үпсә, кызлыкның, матурлыкның хөрмәтен җуйган була шикелле; Хәят моны үз-үзенә ачык әйтеп күрсәтә алмаса да, йөрәгенең әллә кайсы бер чите белән шулай итеп аңлый иде. Ләкин икенче яктан әллә нинди белемсез бер курку аңар анасы сүзен тотарга куша, аны көчли, ирексезли дә аптырашда калдыра иде. Бераз аптыраш... яңадан бераз аптыраш... аннан соң курку җиңде дә, Хәят күңеленең теләмәвенә вә риза булмавына карамыйча, анасы сүзен тотарга, ягъни Салихның кулын үбеп күрешергә уйлап беркетеп куйды. Бу карар Хәятның кызлык көннәренең соңгы карары булды» [14: 79].

Үз заманы татар тормышында да руслар белән аралашып яшәү ягыннан аерылып торган Хәятлар гаиләсе белән чагыштырып, әдип Салихның «артык европалы» түгеллеген күп кенә детальләрдә күрсәтә. Мәсәлән, Хәят егетнең кайбер рус сүзләрен дөрес әйтмәвен искәрә. Әмма артык яңалык яклы булмаган Салих белән аның әнисе Гаделбану абыстай арасында да күп кенә мәсьәләләрдә каршылык туа. Моны язучы Салихның уйларында варенье савыты кую, яки рус повар алуга бәйле анасы белән ике арада туган каршылыкларны искә төшереп, аннары Салихның русларны өенә кунакка чакыру күренешен хәтерләтеп сөйли.

Хәят белән Гаделбану абыстай арасындагы мөнәсәбәтләрне дә язучы шушы якка игътибар итеп сурәтли: аларның икесенең дә күңел халәте яңача уйлау белән искечә фикерләү каршылыгы төсендә ачылып китә.

Повестьның матурлыгы, эмоциональ тәэсирлелеге, шиксез, төп образ бирелеше белән турыдан-туры бәйле. Хикәяләүче үз героинясы Хәятны сокланып, кызның уй-фикерләрендә, хис-кичерешләрендә калкып чыккан каршылыкларга битараф калмыйча тасвирлый.

Әсәрнең күпчелек өлеше Хәятны характер буларак ачуга хезмәт итә. Язучы аның портретын әсәр буенча «сибеп» бара: «Матур бу кызның озын керфекле кара күзләре алсу-ак йөзенә, могҗизалы якутлар шикелле, нур чәчеп торганлыктан, гүзәл башы, хәтта бөтен буе нурда йөзә шикелле күренә иде»; «Ул озын, куе вә үз-үзләреннән күперенеп тора торган, кара ефәк көлтәсе шикелле чәчләрен тараганда…» һ. б. Тышкы кыяфәтне һәм холык-фигыльне сурәтләү максатында, башка геройларның бәяләре кулланыла. Алар кызның матурлыгын да, эчке самимилеген һәм сафлыгын да ассызыклыйлар.

Ләкин иң әһәмиятлесе – хикәяләүче аңлатмалары, аның, психологизм алымнары кулланып, Хәят күңелендә туган хис-кичерешләрне, аңында бер-берсен алыштырып килгән фикерләрне укучыга «сөйләве». Кызның эчке дөньясы, нигездә, шулар аша тергезелә. Бу вакытта язучы аң агышы алымы ярдәмендә Хәятның күңел халәтен

күзәтә. Болар арасында хис һәм акыл көрәшен тергезгән урыннар аеруча мөһим һәм алар хәрәкәт хасил итә.

Бу үзенчәлек повестьның яңа табылган дәвамында да күзгә ташлана. Әмма биредә инде мәхәббәт көтү белән бәйле хис һәм акыл көрәше түгел, үз хәле белән килешергә омтылудан туган каршылыклы халәт ачыклана. Әйтик, Салихның соңаруын сурәтләгән соңгы вакыйгада язучы героинясының кичерешләрен болай аңлата: «Шулай булды инде, бер көнге шикелле төнлә генә кайтыр инде! – дип, Хәят башына килгән фикерен теле белән әйтеп, үз-үзенә аңлатты. Аның эче поша иде. Бу эч пошу Салихны сагынгандан түгел, Салихны әллә нинди хатыннар янында йөри торгандыр дип уйлап көнләшкәннән түгел, Салих белән менә хәзер эшләнергә тиешле бер эш булып да, шул эшнең вакытыннан кичеккәненнән түгел, хәтта Салихны кәефләнеп кайтып, үзен кәефсезләндерер дип уйлаудан да түгел, бәлки коры, билгесез рәвешдә эч пошу иде. Хәятта Салихка каршы үткен бер тойгы юк, шунлыктан ул аны сагынып көтми, Салихны Хәят бозык бер фахиш дип дә уйламый, шуңар күрә, ул аннан көнләшми; Салихның кәефләнеп кайтуы аңар бер көн кәефсез булса да, әүвәлге мәртәбәдәге пароходтагы шикелле үк үткен тоелмаган вә шуңар күрә ул хәзер аның тугрысында да куркынып уйланмый, бәлки үзенә мәгълүм булмаган пошыну белән пошына иде» [14: 103–104].

Бу аңлатуга Хәятның гына түгел, яратмаган, белмәгән-күрмәгән кешесенә кияүгә чыккан татар кызларының хәленә ачыну, сызлану килеп катнаша. Әгәр повестьның төп текстында Хәятның индивидуальлеге үзәктә торса, дәвам өлешендә типиклаштыру, Хәят язмышын татар кызлары язмышы кебек гомумиләштереп бәяләү калкытып куела.

Әсәр исеменә чыгарылган һәм төп героиня исеме булган, татар яшьләре хәяты дигән җыелма образда уйнатылган символның дәвам өлешендә татар хатын-кызы язмышы мәгънәсе алга чыга. Аңа каршы куелган йорт образы Салих йорты мисалында яңа яклары белән күренә башлый. Традицион татар көнитешен матур һәм бай итеп бәяләү белән бергә, язучы аның яңалыкны кабул итмәвен дәвам өлешендә дә ассызыклый.

Беренче өлештә парлы символлар – роза чәчәге һәм сандугач әсәрне лирик-эмоциональ дулкынга көйли. Чәчәк – Хәятка бәя бирә: хикәяләүче кызны матур чәчәккә охшата, Михаил исә аны кояшта сулган чәчәк белән чагыштыра. Шулай итеп, чәчәк – яшьлек, матурлык, мәхәббәт символы, ул яшьлекнең матурлыгын да, тереклекне-матурлыкны саклап кала алмау ачысын да ассызыклый. Хәятның кияүгә чыкканнан соңгы тормышы әлеге сулган чәчәк белән тиңләшә. Моның өчен язучы янәшәлек алымына мөрәҗәгать итә. Туйлары августта булган яшьләрнең пароходта йөзүләре җилле салкынча вакытка, Хәятның кияү өендә яши башлавы исә караңгы кыш көннәренә туры килә. Кыз тормышындагы үзгәрешләр шулай бәяләнә.

Хәятны гомумән татар кызы буларак уку вариантын әкәм-төкәм һәм карлыгач символлары да калкуландыра. Беренче карашка, алар

аллегория булып тоела һәм Гали Арсланов уенда калкып чыга: «Бу егет… татар кызлары хакында кайсыбер рус китапларында күргән нәрсәләрен генә белә вә шуңар күрә аларны – кабыгына яшеренеп ята торган әкәм-төкәмнәр шикелле итеп кенә күз алдына китерә ала иде» [14: 53]. Бераздан язучы образны Хәят белән Әминәгә күчерә: «Галинең зиһенендәге төркем-төркем әкәм-төкәмнәр янына тагы ике әкәм-төкәм кушылды. Шулкадәр аерма бар: Галинең әүвәлдән белә торган әкәм-төкәмнәре былчыраклар, әмма бу соңыннан килеп кушылганнары өс якларыннан чиста вә нәфисләр иде» [14: 55]. Укучы күзаллавында исә әкәм-төкәм образы Хәятның үз гаиләсе, милләте, традицияләре кысасыннан чыга алмавы белән янәшә куела, кызның карарларына бәя булып аңлашыла. Вакыйгадан вакыйгага Хәят татар тормышындагы традицияләрне үзгәртә алмаячагын аңлый бара. Рәхимә абыстай Гали Арслановны кызлар белән таныштырудан баш тарткач, хикәяләүче мондый күзәтү ясый: «Күңел үзенең ирексезлеген һәм әллә нинди бик тупас бау белән буыла икәнен сизенеп пошынды. Хәятның эч пошу эчендә нәрсәдер аның үзенә белеш түгел бер нәрсә күңелнең пошынуы белән сугышырга тотынды» [14: 57]. 12 нче бүлек ахырында, Хәят Гали Арсланов һәм Ольга биюен күзәткәндә, ул тагын калкып чыга. 13 нче бүлектә («Яшерен елаш») ирексезлекне аңлау Рокыя мисалында күрсәтелә. Шулай әдип ирекка омтылган героинясын ата-анасы фикере белән килешеп, кияүгә чыгарга ризалашуга китереп җиткерә. Бигрәк тә әсәрнең дәвамы өлешендә Хәятның психологик яктан үз күңелен көйләргә, үз хәле белән ризалашырга омтылышы күңелендә карлыгач йөрткән кызның әкәм-төкәм кабыгында калу мәҗбүриятен, шушы хәлнең драматизмын бөтен тулылыгында ача.

Героиня өчен әһәмиятле һәр вакыйга аның күңелендә каршылыклы уйлар һәм хисләр көрәшен уята, бу исә эч пошуга китерә. Эч пошу – Хәятның үзе дөрес түгел дип тапкан ситуациядән чыгу юлын таба алмавы ул. 18–20 нче бүлекләрдә исә бу халәт даими калкып чыгып тора, бу аларның тулаем диярлек эчке монолог кебек язылулары белән дә аңлатыла. Язучы Хәятның кияүгә чыкканнан соңгы халәтен мәхәббәткә өмет итеп тә, аңа ирешү мөмкин түгеллекне аңлау белән бәйли.

Әсәрнең дәвамында читтән торып ясалган психологик анализ да урын таба: «Гаделбану абыстай сүзләрендә вә мөгамәләсендә Хәятка үзенең аны әллә ничек, бигүк сөеп бетермәгәнлеген белдертмәскә тырышса да, Хәят йөрәгенең әллә кайсы бер чите белән бу эшне сизенә, ләкин аңа бик зур әһәмият бирмәскә тырыша, үз-үзен әһәмият бирмәскә ирексезли иде» [14: 100].

Шулай итеп, повестьның психологик стильдә язылуын, авторның әсәрнең дәвамын эшләгәндә дә сайланган язу рәвешенә тугры калуын билгеләргә кирәк. Героиняның күңелендә барган үсеш-үзгәрешне күзәтеп барып, язучы татар кызының матурлыгын аны чолгап алган тормышның кырыслыгына каршы куя. Үз хыялында гына булса да

Хәят тормышны үзгәртергә, гармониягә китерергә омтыла, бу вакытта аның өчен иң мөһим башлангыч булып мәхәббәт тора. Әмма кызның күңел хәрәкәте мәхәббәткә, бәхеткә, ирекка, үзең теләгәнчә яшәргә ашкынудан – моның мөмкин түгеллеген аңлау, ризалашу, буйсынуга таба юнәлә. Хәятның эш-гамәлләре дә татар кызының иҗтимагый шартлардан котыла, күнегелгән гадәтләрдән читкә чыга алмавы турында сөйли. Хәят тарихы гомумән татар хатын-кызлары язмышына әверелә, ХХ йөз башы татар җәмгыятендә яшьләрнең яңача яшәргә, хөрлеккә омтылуын, ләкин иске тәртипләрнең бу омтылышларны чикләвен аңлата. Әмма бу тарих матурлык теле белән иҗат ителгән, шуңа да ул романтик кимәлдә кала, күрсәтелгән омтылышларның гүзәллеген ассызыклый, татар кызының тышкы матурлыгына, акылына, уй-фикерләр табигыйлегенә сокланырга мәҗбүр итә, шулар аша аның хөр, ирекле, азат булачагына ышаныч саклана.

Җамал Вәлиди: «ул татар әдәбиятын заман теләгенә мауфыйк бер калыпка, Көнбатыш әдәбияты калыбына салды, аңа җитди бер форма биреп, телне, өслүбне нечкәләп эшкәртүче булды. Ф. Әмирхан – кирәк фикер ягыннан булсын, нәфис әдәбиятыбызны гаребләштерүдә[1] иң алдан чыгучы һәм киң юлдан ачучыдыр» [6: 433], диюе белән хаклы иде. Бу сүзләрнең дөреслеге «Хәят» повесте мисалында да раслана.

## Совет чынбарлыгы һәм Ф. Әмирхан

ХХ йөз башы татар әдәбияты тарихында Ф. Әмирхан иҗаты әдәбиятны идея-эстетик яктан үзгәртүләрне башлап җибәрүе, милли мәдәниятне күптөрле тәҗрибәләр аша үстерүе һәм бу вакытта шәркый традицияләрне урынлы куллануы белән үзенчәлекле. 20 нче еллар әдәбияты өчен бу иҗат – 1917 елга кадәр формалашкан юнәлешне саклаучы, татар әдәбиятының фикри һәм форма ягыннан казанышларын югалтмыйча, алдагы буыннарга тапшырырга ярдәм иткән нигез баганаларыннан. Язучы шәхесе исә – гражданлык фидакярлеге үрнәге буларак аерым хөрмәткә лаек.

1917 елгы февраль инкыйлабын Ф. Әмирхан тормышның үзгәрәчәгенә өмет белән каршы ала. «Кояш» газетасының март һәм апрель саннарында «Инкыйлаб вә без» дигән зур мәкалә, «Аң» журналының 3–4 саннарында «Богаулар өзелделәр» дигән язма бастыра. Ул инкыйлабны милләтне үстерер өчен туган олы мөмкинлек, язмышның «киләчәгегез бу көннән соң үз кулыгызда» дип белдерүе кебек кабул итә. Ф. Әмирхан халык буларак бөтенлегебезне, традицияләр, гореф-гадәтләрне саклап калыр өчен, татарның «дини, милли, мәдәни автономия» төзү зарурияten куәтли, милләтне социаль катлауларга бүлмичә, сыйнфый тартышлардан, фетнәчел чыгышлардан ерак торырга чакыра. Биредә әдипнең ихластан илһамлануы, дулкынлануы күренеп тора.

[1] *Гаребләштерү* – Көнбатышка, Европага якынайту.

Әмма тиз арада Ф. Әмирхан мәкаләләрендә большевиклар сәясәтен дөрес юлга борып җибәрү, аерым мәсьәләләрдә эш башындагыларны татар халкы кебек азсанлы милләтләрнең яшәү үзенчәлеген исәпкә алмыйча эш йөртүдә тәнкыйтьләү чаткылары барлыкка килә. «Кызыл армия» газетасының 1919 елдагы 14 декабрь санында ул «Ләфызпәрәстлек[1] кенәме, лакейлыкмы?» дигән мәкалә бастыра һәм татарларда өстенлекле сыйныф буларак пролетариат сыйныфын игълан итүнең хакыйкатькә туры килмәгәнен расларга омтыла. Аның шушы юнәлештә иҗат ителгән мәкаләләрендә, бер яктан, инкыйлабның көткән азатлыкны бирә алмавына борчылу, икенче яктан, килеп туган вазгыятьтә үз халкына киләчәккә юл күрсәтү теләге үрелеп бара.

1918 елны Фатихның әнисе Рабига абыстай бакыйлыкка күчә. Иң якын кешесен югалтуны бик авыр кичергән Фатих аңа багышлап «Тәгъзия[2]» дигән нәсер иҗат итә. Ул 1922 елны «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»[3]нда басылып чыга һәм татар әдәбиятында инкыйлабка кадәрге традицияләрнең саклануына бер дәлил булып яңгырый.

Ул әле генә бердәнбер кызларын җирләп кайткан ир белән хатынның сөйләшүе кебек язылган. Әмма бу сөйләшү – асылда, кайгыдан сыгылган, әмма хатынын юатырга омтылган картның монологы рәвешен ала. Аның фразалары, интонациясе аша хатынның җавапларын да тергезергә мөмкин.

Хатынына мөрәҗәгать итеп, ир кеше үлемнең – котылгысызлыгын, табигать законы булуын, бер җан иясенең дә аннан котылып кала алмавын искәртә. Карт сүзләрендә сер пәрдәсенә төрелгән үлем – яшәүнең бердәнбер мәгънәсе кебек калкулана. Шул ук вакытта Ф. Әмирхан иман мәсьәләсенә кагыла, өметсезлекне кичерә алу юлларын барлый (биредә үлгәннән соң яшәүнең мөһимлеге дә, һәр кешенең үз тирәсендәгеләргә яхшы мөгамәләсенең тормышны үзгәртә алуы да, җан тынычлыгы булганда гына хакыйкатькә ирешү мөмкин икәнлек тә һ. б. искәртелә). Күпмедер күләмдә әсәр 1920 елларда яңа хакимиятнең иманнан баш тартуын гаепләү булып та яңгырый («Ул газапларны, ул өмидсезлекне без матдәнең аргы ягына идракъләре[4] ирешми торган, күзләре күргәннән башканы гакыллары гына түгел, йөрәкләре дә сизми торган кызганыч бәндәләргә, динсезләргә калдырыйк. Сабырлары җитә икән, алар йөкләсеннәр шул газапларны, алар көйсеннәр шул өмидсезлек белән! Ә без, без, бу тереклектән башка тагын бер тереклек барлыкка ышанучылар, ул икенче тереклекнең безнең тереклегебезгә караганда чынрак, әһәмиятлерәк, галирәк икәнен аңлыйк, аңлыйк та ул тереклеккә күчкәннәр өчен өмидсезлеккә төшмик...» [11: 368]).

[1] *Ләфызпәрәстлек* – хәрефкә ябышып яту.

[2] *Тәгъзия* – күңел юату, сабыр итәргә өндәү; дини әдәби жанр атамасы.

[3] Бу елларда таратудан килгән акчасы ачларга ярдәм итүгә тотыла торган җыентыкларны шулай атыйлар.

[4] *Идракъ* – акыл.

Әсәр үзе хакыйкать, рухи ныклык хакындагы суфичыл дога кебек кабул ителә (моңа Урта гасырлар суфи әдәбияты жанрыннан алынган һәм бер үк вакытта әрвахларны искә алу йоласын белдерә торган әсәр исеме дә ишарә ясый). Бик нык уйланган композиция һәм сүзләрнең оста сайлануы, аң агышы укучының игътибарын үзенә җәлеп итә һәм күтәрә алмаслык олы кайгының һәр мизгелен күңелдән уздырырга мәҗбүр итә. Нәтиҗәдә, әлеге «эмоциональ күпер» укучы күңелендә дә хасил була.

1920 еллар башында Ф. Әмирхан инкыйлабка кадәрге әдәби традицияләрне дәвам иткән хикәяләр дә яза. «Беренче ашкыну» (1918) шундыйлардан. Аңа да «басылмаган озын хикәядән бер кисәк» дип аңлатма бирелгән. Хикәянең төп герое – авыл мулласының малае, шәһәр кызы Саррәгә гашыйк булган. Авылдан алып килгән карабодайны сатып бетерүгә, малай-егет, сөйгәнен күреп булмасмы дип, аларга йөгерә. Хәйлә табып, кызга мөрәҗәгать итү, аннары инде шәһәрдән авылга кайтып китү аралыгы беренче мәхәббәтнең матурлыгын, кеше күңелендә бихисап күп каршылыклы тойгылар уятуын күрсәтергә ярдәм итә. Дөрес, әсәр ахырында малай «бу көнге сагынуымда минем ул моңлы ләззәт һәм тыныч уйга бату юк, бәлки ниндидер бер ачылык, тынычсызлану, борчылу башлыча хөкем сөрәләр иде» [11: 365], ди. Бу мәхәббәтнең киләчәге булмау, чарасызлык кебек экзистенциаль мотив килеп керә. «Башымда караңгы һәм өмидтән ерак фикерләр йөренә башладылар». Ләкин социаль сәбәпләр белән уралып кергән бу халәт әсәрнең иң ахырында билгеләп кенә куела. Ә инде мәхәббәт уяткан хисләр палитрасы, уй һәм кичерешләрнең туктаусыз берсен берсе алыштырып килүе нәкъ менә беренче мәхәббәтнең тылсымлы тәэсирен сурәтләү үзәккә куелганлыкны исбатлый.

1921 елда Ф. Әмирхан әтисен югалта. Бертуган энесе Ибраһим бу вакытта Кырымда хокук саклау органнарында эшли. Якыннарыннан аерылу, 1921 елгы ачлык Фатихның болай да какшаган сәламәтлегенә зур зыян сала. Әдипнең тормышы авыр булганлыкны ул 1921 елның 7 октябрендә яза башлаган көндәлек дәфтәрләре күрсәтеп тора. Укучы бу дәфтәрләрдә 1920 елларның коточкыч атмосферасын да, инкыйлабның кешеләр аңына, күңеленә ясаган тискәре йогынтысын да, ачлыкны, мәдәни мохитне, шушы хәлләр уртасында калган талантлы татар зыялысы кичергәннәрне дә күз алдына китерә алыр. Татар мәдәниятендә Ф. Әмирхан кадәр инкыйлаби вакыйгаларга төгәл-тәнкыйди тарихи-экзистенциаль бәя биргән башка каләм әһеле булмый.

Октябрь инкыйлабының асылына төшенгән әдип 1917 елда ук «Март каһарманы» дигән хикәя язып, анда революциянең ни икәнен аңламаса да, үзе өчен файдасына төшенеп, митингтан митингка йөреп, социалист булып киткән, куштан һәм яраклаша белүче кеше тибын иҗат итә. Әлеге героен киләчәккә алып китеп, аның язмышын болай күзаллый: «1920 елда Русиядә кушма җөмһүрият урнашып

җиткән, татар штаты рәис җөмһүриятлегенә дә бер социалист сайланган, ләкин ул социалист безнең Гыйсмәтулла түгел иде. Гыйсмәтулла үз волостьларының комитетында кәтиб мөгавене[1] хезмәтен үтәп, аена йөз сум вазифа ала, социалистларны, хосусән, «бөтен инсаниятнең канын эчүче рәис җөмһүриятне» бик сүгә, халыкны анархист-индивидуалист булырга өнди һәм революция вакытында җыеп калган ун мең сум капиталының елга биш йөз сум гына процент бирүендә хәзерге «кан эчүче хөкүмәт»не гаепле күрә иде» [11: 330].

Яңа системаның асылын, идеологик нигезсезлеген аңлап, совет хакимиятенә шарж итеп язылган «Шәфигулла агай» (1924) повесте большевиклар идеологиясенең кешеләрне уйсыз-гамьсез, гасырлар буе яшәп килгән традицияләрдән аерылган кол дәрәҗәсенә төшерүен раслый. Язучы Шәфигулланың аяныч язмышы аша советчыл тәртипләрнең татар халкына рухи-әхлакый характердагы зур югалтулар китерүенә ишарә ясый. Язучы әлеге фикерне карнавал көлү – халык көлүе формасында, ирония, сарказм алымнарына таянып калкуландыра. Интеллектуаль һәм мәдәни яктан чикләнгән Шәфигулланың, тормыш алып килгән, көн саен радиодан яңгырый торган идеологик чакырулар, яңача яшәү рәвешен мактаулар тәэсирендә, «советча» яши башлавы: 20 ел бергә яшәгән хатыны Сәрвине аерып, кабат советча гаилә коруы, яңа туган улына большевикларча итеп Володя исемен куштыруы, аны, кызыл байракка төреп, кешеләргә күрсәтүе, сабый демонстрациядә салкын тидереп үлгәч, табут ясатып күмүе, көн саен балаларын «Интернационал» җырлатуы, Мәскәүгә «партийный хаҗ кылырга» китеп баруы һ. б. укучы тарафыннан акылдан язу буларак кабул ителә. Яңа идеологиянең тышкы билгеләре халык аңында киләчәк матур тормыш хакында миф тудыруга юнәлтелгән булса, Ф. Әмирханның бу идеологик йогынтыны «акылдан яздыру» буларак бәяләве әлеге рәсми мифны җимерүгә хезмәт итә. Язучы заман алып килгән үзгәрешләрне иҗтимагый яктан да, милли аспектта да бәяләп уза. Әйтик, повестьны тәмамлап, «Красный тел» газетасында басылган хәбәрдән китерелгән өзек милли сөйләмнең юкка чыгуы хакында сөйли: «Рабочий-крәстиянга тагын бер пример. Почти 60 яшенә достигать иткән татарин-рабочий Шәфигулла әле недавно гына партиягә расписаться иткән булса да, религиозный дурманнарны к черту җибәреп, полный сознательность проявить итте. Новорожденный ребенкасына Владимир куштырды...». Шул рәвешле, руслашу сәясәтенең көнитеш рәвешен һәм гореф-гадәтләрне генә түгел, гомумән миллилекне юк итүе билгеләнә.

Шул ук вакытта Ф. Әмирхан яңа чынбарлыкта үз урынын табарга омтыла. 1923–1924 елларда укыту эшенә кереп, Татар театр техникумында татар әдәбияты дәресләре алып бара, хәтта дәреслекләр дә язуда да катнаша. «Кызыл армия», «Эш», «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан» газеталарына мәкаләләр яза, аларда халыкны агарту, рухи

[1] *Кәтиб мөгавене* – секретарь.

үстерү юллары хакында уйлана. Әйтик, «Мәдәниләшү юлында зур адым» («Татарстан», 1922, 1 октябрь) мәкаләсендә татар теленең терминологиясен камилләштерү, философия, логика, психология, хокук кебек юнәлешләрдә төшенчәләр булдыру, терминологик сүзлекләр төзү турында сүз алып бара. «Бу рухта беренче…» («Безнең юл», 1925, № 3) язмасында Гыйльми үзәкнең Каюм Насыйриның тууына 100 ел тулу уңаеннан юбилей кичәсе уздыруын тәбрикләп, әдип татар халкын, аның төрле сыйныф вәкилләрен берләштерү, шулай итеп, халыкны үстерү мәсьәләсен көн тәртибенә куя.

Кызганычка каршы, бу елларда Ф. Әмирханга каршы чыгулар күбәя, аны буржуаз язучы буларак гаепләүләр яңгырый. Шулай да, Г. Ибраһимов тырышлыгы белән, 1925 елда Татарстан АССР хөкүмәте Ф. Әмирханга 40 сум күләмендә персональ пенсия билгели. Шул ук елны Әмирханда туберкулёз авыруы табыла. Хәле авырайгач, татар зыялылары аңа ярдәм оештыралар: табиблар булышлыгы, студентларның кизү торуы, зыялыларның килеп йөрүе, газеталарда көн саен аның хәле турында хәбәр ителү – халыкның Ф. Әмирханга мәхәббәтенең ачык чагылышы була.

Каты авырудан соң, 1926 елның 9 мартында әдип бакыйлыкка күчә. Бу вакытта аңа бары 40 яшь була.

Күмү мәрасиме комиссиясе саубуллашу чараларын тантаналы итеп оештыра (замандашлары аның Тукайны соңгы юлга озату дәрәҗәсендә булуын, театр мәйданына 2 меңләп кеше җыелганлыкны язып калдыралар). 12 март көнне башта театр мәйданында дөньяви митинг үткәрелә, аннары Юнысовлар мәйданында җеназа намазы укыла. Җәсәде Татар бистәсе зиратында дәфен кылына.

Бакый Урманче, әдипнең татар мәдәниятендәге урынын билгеләп, болай дип яза: «Безнең буын яшьләре, Көнчыгышның гасырлар буенча кристаллашкан, калыплашкан традицияләреннән ваемсыз читләшмичә, Европа-Көнбатыш мәдәниятенә йөзне юнәлдергән прогрессив зыялының идеаль моделе итеп Фатих Әмирханны таный иде. Әдип – үз заманындагы җәмгыять корылышы мәсьәләләрен, бөек француз революциясе аша килгән гаделлек, азатлык, тигезлек идеалларын Көнбатышның революцион фикерле алдынгы ирләре кебек аңлаган шәхесләрнең берсе, һәм бу хосусият аның әсәрләрендә генә түгел, бәлки көндәлек шәхси тормышында да табигый чагылыш тапты. Ф. Әмирхан каләме иҗат иткән әсәрләр алдынгы татар яшьләренең самими өметләренә куәт биреп, алар фикеренә шифалы һәм бәрәкәтле йогынты ясап килде» [15: 50].

Чыннан да, гыйлем һәм фән кешеләре биргән мәшһүр нәселнең затлы улы Фатих Әмирхан үзенең тирән акылы, күпкырлы эшчәнлеге, бай иҗаты белән татар халкы тарихына «аяклары бәйле Прометей» булып языла (Х. Туфан, «Могикан», 1969). Кешеләргә ут бүләк иткән грек пәһлеваны кебек, Ф. Әмирхан милләттәшләренә йөрәк, акыл, рух утын бирә, аларны да янып яшәргә, башкаларга һәм милләткә файдалы булырга өнди.

**Әдәбият**

1. *Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: Истоки и формирование социалистического реализма. М.: Наука, 1983. 263 с.

2. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 2 томда. 1 т. / төз.: Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 751 б.

3. «Әлислах» газетасының библиографик күрсәткече / төз. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1991. 78 б.

4. *Әмирхан Р.* Әмирханнар (тәфсилле шәҗәрә). Казан: Мәгариф, 2005. 125 б.

5. *Ганиева Р.* Татар әдәбияты һәм Фатих Әмирхан // Мәгърифәт. 1996. 13 февр.

6. *Җамал Вәлиди*. Әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз.: Д. Абдуллина, Җ. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2010. 624 б.

7. *Мәһдиев М*. Ф. Әмирхан. Тормышы һәм иҗат юлы турында кыскача очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 86 б.

8. *Нигматуллин Э.Г.* Татарская литература нач. XX века (до 1917 года) в её отношении к западноевропейской литературе и философско-эстетической мысли: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1972. 232 с.

9. *Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1966. 427 б.

10. *Рәми И.Г., Даутов Р.Н.* Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 399 б.

11. *Фатих Әмирхан*. Әсәрләр: дүрт томда. 1 т.: хикәяләр (1907–1922). Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 480 б.

12. *Фатих Әмирхан*. Әсәрләр: дүрт томда. 3 т.: публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 512 б.

13. *Фатих Әмирхан*. Әсәрләр: дүрт томда. 4 т.: әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 390 б.

14. *Фатих Әмирхан*. Хәят. Казан: ТӘһСИ, 2016. 308 б.

15. Фатих Әмирхан турында истәлекләр / төз.: Ф. Ибраһимова, Р. Әмирхан. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 255 б.

***Заһидуллина Дания Фатих кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге баш гыйльми хезмәткәре*

***Загидуллина Дания Фатиховна,***
*доктор филологических наук, профессор, главный научный сотрудник*
*отдела литературоведения Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*zagik63@mail.ru*

УДК 82-95

*Г.А. Хөснетдинова*

# ХАЛЫК МӘНФӘГАТЕН ЯКЛАП...

В данной публикации предлагаются неизвестные сегодняшнему читателю статьи Фатиха Амирхана (1886–1926), выдающегося татарского писателя и драматурга, эрудированного литературного критика, публициста, общественного деятеля, одного из основателей татарской периодической печати. Статьи «Бергәме, аерыммы?» («Вместе или врозь?») (1914, 17 августа, № 485) и «Мөфтилек мәсьәләсе вә аңар кандидатлар» («О муфтияте и о кандидатах») (1915, 26 июня, № 738) были напечатаны в 1914–1915 годах в газете «Кояш» за подписью «Фатих Амирхан».

Первая публикация написана в связи с созданием «Мусульманского комитета» для сбора пожертвований в пользу раненых и пострадавших в Первой мировой войне татарских солдат и ставит целью критику данной организации и ее инициаторов – Х. Максуди, Г. Салихи и С. Иманкулия.

В статье «О муфтияте и о кандидатах» Ф. Амирхан рассуждает о выборах и о кандидатах, претендующих на место умершего летом 1915 года муфтия Мухамедьяра Султанова (1836–1915). Автор выражает надежду, что правительство не станет игнорировать мнение простого народа и не назначит муфтием Баязитова или Капкаева.

Представленные статьи впервые печатаются на кириллице в текстологической обработке и с дополнениями.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, татарская литература, газета «Кояш», публицистика.

This publication offers articles unknown to today’s readers by Fatih Amirkhan (1886–1926), an outstanding Tatar writer and playwright, an erudite literary critic, publicist, public figure and one of the founders of the Tatar periodical press. The articles “Bergame, aerymmy?” (“Together or apart?”) (1914, August 17, No. 485) and “Moftilek masalase va anar candidatlar” (“About the Muftiate and candidates”) (1915, June 26, No. 738) were published in 1914–1915 in the newspaper “Koyash” signed by “Fatih Amirkhan”. The first publication was written in connection with the creation of a “Muslim Committee” to collect donations for the benefit of wounded and injured Tatar soldiers in the First World War and aims to criticize this organization and its initiators – H. Maksudi, G. Salihi and S. Imankulia. In the article “On the Muftiate and the candidates”, F. Amirkhan discusses the elections and the candidates seeking the place of Mufti Mukhamedyar Sultanov (1836–1915), who died in the summer of 1915. The author expresses the hope that the government will not ignore the opinion of the common people and will not appoint Bayazitov or Kapkaev as mufti. The presented articles are being printed in Cyrillic for the first time in textual processing and with additions.

**Keywords:** Fatih Amirkhan, Tatar literature, newspaper “Koyash”, journalism.

Татар халкының иҗтимагый-сәяси аңы, әдәбияты һәм мәдәнияте тарихында мәңге җуелмас эз калдырган шәхесләр бар. Татар әдәбияты классигы, күренекле прозаик һәм драматург, киң эрудицияле тәнкыйтьче, ялкынлы публицист, җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирхан – шундый мәшһүрләрнең берсе. Аның иҗаты, барыннан да элек, үзенең күпкырлы һәм тирән булуы белән җәлеп итә, шуның белән бергә әдипнең татар матбугатын оештыруда һәм аны юлга салуда әйдәп баручылардан булуы да мәгълүм.

Журналистика өлкәсендәге тәүге адымнарын мәдрәсәдә кулъязмада нәшер ителгән яшерен журналларда башлаган Ф. Әмирхан 1907 елда беренче татарча балалар журналы «Тәрбиятел-этфаль»-не оештыруда актив катнаша һәм анда сәркатиплек вазифасын үти. Әмма 1907 елның августында аны паралич суга, һәм ул калган гомерен коляскада үткәрергә мәҗбүр була. Көчле ихтыярлы, милләтенә хезмәт итү дәрте белән янган Фатихны бу бәхетсезлек сындыра алмый: ул актив эшчәлеген дәвам итә. 1907–1909 елларда «Әлислах» газетасы мөхәррире вазифасын башкара. 1912–1918 елларда, «Кояш» газетасында җаваплы сәркатип булып эшли, аның милләт мәнфәгатьләрен алга сөргән юнәлешен билгеләүдә төп рольләрнең берсен уйный. Ф. Әмирхан мәкаләләрендә татар дөньясындагы күренешләргә үзенең мөнәсәбәтен белдерә, үзен милләтпәрвәр фикер иясе һәм күренекле татар иҗтимагый-сәяси эшлеклеләренең берсе итеп таныта.

Журналыбызның бу санында Ф. Әмирханның бүгенге укучыга таныш булмаган «Бергәме, аерыммы?» (1914, 17 август, № 485) һәм «Мөфтилек мәсьәләсе вә аңар кандидатлар» (1915, 26 июнь, № 738) исемле ике мәкаләсе тәкъдим ителә. Алар 1914–1915 елларда «Кояш» газетасында «Фатих Әмирхан» имзасы белән басылганнар.

Ф. Әмирханның «Бергәме, аерыммы?» язмасы Һади Максуди, Мөхәммәдгариф Салихи һәм Садыйк Иманколыйлар инициативасы белән, яралылар файдасына иганә җыю өчен, «Мөселман комитеты» оештырылуы уңаеннан язылган. Максаты Беренче бөтендөнья сугышында (ягъни 1914 елда) яраланган яки сугышта зыян күргән татар солдатларына ярдәм итү булган бу комитет хакында мәгълүмат «Йолдыз» газетасының 14 август (1246 нчы) санында басыла. Ф. Әмирхан мөселманнар өчен мондый комитетның кирәксезлеген исбат итә, иганә җыю тиеш икән, бу эшне руслардан аерылмыйча, алар төзегән җәмгыятьләр аша эшләү дөресрәк булыр, ди. Бердәм булып эш иткәндә генә, бу ярдәмнең сугышта зыян күргәннәр өчен файдалырак, урынлырак булуына басым ясый.

«Мөфтилек мәсьәләсе вә аңар кандидатлар» дигән икенче мәкаләдә Ф. Әмирхан Диния нәзарәте мөфтие Мөхәммәдьяр Солтанов (1836–1915) урынына яңа мөфти сайлау мәсьәләсе турында яза. Мәгълүм булганча, әлеге уңайдан Казан, Уфа, Оренбург кебек татарлар күпләп яшәгән шәһәрләрнең зыялы һәм руханилары арасында

яңа куелачак дин башлыгының нинди булырга тиешлеге хакында бәхәсләр кыза, кандидатлар тәкъдим ителә. Вакытлы матбугатта да бу хакта күпсанлы мәкаләләр басыла, төрле фикерләр әйтелә, кандидатларның исемнәре санала. Җәмгыять хадиме булган Ф. Әмирхан үзенең мәкаләсендә хөкүмәт гади халык фикерен исәпкә алмый калмас, баюдан бүтән ихласы булмаган Капкаевны яисә исемен пычраткан Баязитовны мөфти итәргә базмас, дигән өмет белдерә.

Әмма патша хөкүмәте үзенчә эшли: 27 июльдә игълан ителгән фәрман белән мөфти итеп дин һәм җәмәгать эшлеклесе Сафа Баязитовны (1885–1937) билгеле. Бу, үз чиратында, мөселман җәмәгатьчелегендә ризасызлык тудыра, матбугатта С. Баязитовка карата тәнкыйть мәкаләләре басыла.

Түбәндәге мәкаләләр гарәп графикасыннан гамәлдәге язуга күчерелеп, текстологик яктан эшкәртелеп һәм астөшермәләр белән тулыландырылып, укучыга беренче тапкыр тәкъдим ителә. Алар Институтның текстология бүлеге галимнәре тарафыннан әзерләнә торган Фатих Әмирханның алты томлы «Әсәрләр» академик басмасының 5 нче томында урын алачак.

## БЕРГӘМЕ, АЕРЫММЫ?

«Йолдыз» гәзитәсендә күрелгән бер игъланнан аңлашылуына күрә, Һади әфәнде Максуди, мулла Садыйк Иманколый һәм мулла Мөхәммәдгариф Салихи әфәнделәр сугышта мәҗрух төшкәннәр[1] файдасына иганә җыяр өчен бер комитет – «Мөселман комитеты» тәшкил иткәннәр икән.

Ватанымыз башына зур кайгы төшкән вакытта бөтен Русия гражданнары белән бергә бөтен Русия мөселманнары да ул кайгыны иңләтү юлларына керергә вә шул юлда кулларыннан килгән һичбер нәрсәне аямаска тиешләрдер. Ватан вә падишаһ өчен сугышка кереп мәҗрух булган кешеләр – иганәгә иң мохтаҗ кешеләрдер. Бу юлга бирелгән иганә – иң урынлы бирелгән иганәләрнең берсе вә әһәмиятлеседер. Монда һич шик вә шөбһә булырга мөмкин түгел.

Мадам ки[2], киң вә куәтле Русиядән без дә башкалар белән бергә файдаланамыз, аның куәтле вә нык булуы аркасында без дә рәхәт яшимез. Аның башына бәла килгән вакытларда шул бәла белән без дә көчемездән килгән дәрәҗәдә көрәшергә бурычлымыз. Бу эштә милләт вә дин аермалары юк, бу эш – бөтен русиялеләр өчен мөштәрәк[3] вә бертигез эш вә бертигез вазифадыр. Менә шул әсаслардан чыгып

---

[1] Мәҗрух төшкәннәр – яраланганнар.
[2] Мадам ки – чөнки.
[3] Мөштәрәк – уртак.

та, мин «Мөселман комитеты» тугрысында бер-ике сүз әйтеп китүне тиеш күрәм:

Бөтен русиялеләр өчен бертигез мөштәрәк булган бу эштә мөселманнарның руслардан аерым эш күрүләрен мин һичничек итеп аңлый алмыйм. Мадам ки бәла мөштәрәк, мадам ки аңар каршы тору – бөтен русиялеләр өчен мөштәрәк бер вазифа, без бу тугрыда руслар белән кулга-кул тотышып хәрәкәт итәргә, көчләрне аермыйча, бер ноктага җыеп хәрәкәт итәргә тиешләрмез:

– Ни өчен «Мөселман комитеты»?

– Ни өчен без мөштәрәк комитетларда, мөштәрәк мөәссәсәләрдә[1] хезмәт итмимез?

Мин бу сөальләргә[2] җавап таба алмыйм.

Тәэсис ителгән[3] әллә никадәр комитетлар бар; боларның башында ышанычлы вә тәҗрибәле кешеләр торалар, шулар булып торганда ни өчен мөселманнарга махсус комитетлар ясап, аны организовать итәргә көч тыгарга? Организовать итеп, аякка бастырылган мөәссәсәләрдә мөшарәкәт итеп[4] шунда эшләшкәндә бу көч мәҗрухлар өчен тагы да файдалырак, тагы да урынлырак төшәчәк бит! Ни өчен мондый гомуми эшләрдә руслардан аерым эш күрергә? Моның кирәген мин һичбер аңлый алмыйм.

«Мөселман комитеты» ясарга йөрүчеләр үзләренең игъланнарында болай диләр: «Әгәр дә үз комитетымыз булса, гайрәт вә сәдакатемез заһир улмак илә бәрабәр биргән суммамызның никадәр икәне дә мәгълүм булыр иде». Мин бу дәлилне рәдд итеп[5] торырлык дәрәҗәдә дә күрмим. Әгәр сәдакать[6] күрсәтү мәкъсуд[7] булса, бу эш руслар белән бергә эшләшкәндә бигрәк яхшы күренә.

Әгәр үземез биргән сумманың микъдарын белү мәкъсуд булса, моны да без үземез эшләшкән мөәссәсәләрнең хисабларыннан бик яхшы күрә аламыз. Әгәр без бик бай бер милләт булып та, бу эшкә әллә ничә миллионнар иганә итеп, рус ватандашларымызга да нәмунә[8] була алырлык, аларны да гыйбта[9] иттерә алырлык булсак иде – шул вакытта бәлки хосусый «Мөселман комитеты» тәэсис итеп торуның бер әһәмияте булыр иде. Ләкин хәл болай түгел бит! Тәәссефкә каршы[10], без андый бай бер милләт түгел, безнең иткән

---

[1] Мөәссәсәләр дә – оешмаларда.

[2] Сөальләргә – сорауларга.

[3] Тәэсис ителгән – төзелгән.

[4] Мөшарәкәт итеп – бергәләп.

[5] Рәдд итеп – кире кагып.

[6] Сәдакать – турылык, дуслык.

[7] Мәкъсуд – ниятләнгән.

[8] Нәмунә – үрнәк.

[9] Гыйбта – берәүдәге яхшы якларны күреп, үзеңдә дә шуны булдырырга теләү, кызыгу.

[10] Тәәссефкә каршы – кызганычка каршы.

иганәләремез дә шул үз көчемез нисбәтендәге, русча тәгъбир иткән «скромный» гына бер хисса[1] булачак – шулай булгач, мин бу тугрыда үз башымызга гына эш күрүнең һичбер кирәген тапмыйм, хәтта зарарлы бер эш дип уйлыйм. Безнең сугышка киткән кардәшләремез рус ватандашлары белән бер сафта үләләр, бер сафта торып мәҗрух төшәләр, шулай булгач, монда калган мөселманнар да бу тугрыда руслар белән кулга-кул тотышып, бер сафта вә бер көч белән эш күрергә тиешләрдер.

Безнең үз башымызга, үземез генә эшли торган милли эшләремез дә бик күп, гомуми ватан эшләрендә без һәрвакытта рус ватандашларымыз белән бергә, алар белән кулга-кул тотышып кына эшләргә тиешләрмез. Шулай булганда гына безнең ул эшләремез көтелгән файданы бирә алырлар. Мондый эшләрдә аерым йөрү файдасыз гына түгел, бәлки зарарлы булачактыр. Мондый эшләрдә көчләрне мөмкин кадәр бер җиргә җыю – хөкүмәтнең матлубыдыр[2]. Дахилия назыйренең министрлар мәҗлесенә керткән, 1912 ел 25 июнь законына тәтиммәсенең[3] әүвәлге маддәсендә «сугышка алынганнарның гаиләсен тәрбия тугрысында күрелә торган чараларның һәммәсен берләштерергә тырышуның» кирәклеге күрсәтеләдер. Шулай булгач, без бу тугрыда аерым эш күрүемезнең хөкүмәт өчен матлуб булуы да бик шөбһәле буладыр.

Менә шуларны хәтергә алып, мин русияле мөселманнарга бу тугрыда аерым эш күрмичә, руслар белән бергә хәрәкәт итүне, гомуми мөәссәсәләрдә бөтен көчләрен сарыф итеп хезмәт итүне тәүсыя итәр[4] идем. «Мөселман комитеты», «Татар комитеты» дигән шикелле аерым бер мөәссәсәләргә һич ихтыяҗ юк. Шәһәр, земство, «Красный крест» вә башкалар тарафыннан тәэсис ителгән әллә никадәр комитетлар бар. Мөселманнар шул комитетларда ихлас белән хезмәт итешсеннән, шул комитетлар аркылы иганә итсеннән – монда һәм сәдакать күренер һәм гомуми эшләргә өйрәнү табылыр!

*(«Кояш». 1914. 17 август)*

---

[1] Хисса – өлеш.

[2] Матлубыдыр – теләгедер.

[3] Тәтиммәсенең – кушымтасының. Сүз 1912 елның 25 июнендә кабул ителгән «О призрении нижних воинских чинов и их семейств» дигән закон турында бара. Әлеге закон 1913 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертелгән.

[4] Тәүсыя итәр – киңәш бирер.

## МӨФТИЛЕК МӘСЬӘЛӘСЕ ВӘ АҢАР КАНДИДАТЛАР

*Мөфтилек тирәсендә татар әфкяре гомумиясе[1]. Матбугат берлеге. Оптимистлар вә пессимистлар. Гыйниятулла Капкаев вә «садака» мәсьәләсе. Сафа мәхдүм вә гайреләр.*

Сабикъ[2] мөфти Солтанов[3] вафат иткән көннән соң, мөфтилек мәсьәләсе гаҗәеп дәрәҗәдә татар әфкяре гомумиясен мәшгуль итә башлады. Кайда барма, кем белән очрашма, ике-өч татар бергә тугры килгән һәрбер җирдә мөфтилек мәсьәләсе мөзакәрә ителә:

Кем мөфти булачак? Дөрест әйтергә кирәк, мин әле үз халкымызның шушындый бер көндә мөфтилек мәсьәләсе белән бу кадәр кызу шөгыльләнүен көтә алмыйдыр идем, татар әфкяре гомумиясенең аз бер еллар эчендә шундый бер хәрәкәтчелек (активность) күрсәтә алуын өмид итәргә читенсенә идем. Бик күп милли мәсьәләләремездәге шикелле, бунда да татарда әле әфкяре гомумия эшләнеп җитмәгәнлекнең әсары күренер, монда да милләтнең кул селтәбрәк караганлыгы тагы бер кат заһир булыр төсле иде, ләкин үземезнең гаид шатлыгыма каршы, хәзер мин фикри бер торгынлык урынында, бер хәрәкәтчәнлек, мәсьәләнең әһәмиятен аңлаганлык күрәм:

Казанның бөтен татар даирәсе бер көн шул мәсьәлә тирәсендә фикер йөртә вә шул мәсьәлә тирәсендә сүз сөйли...

Әле ул гынамы, шул фикер йөртүчеләр вә шул сүз сөйләүчеләр һәммәсе ниндидер бер кодрәт кулы белән әсаслары бер үк ноктада җыела торган бер фикер тирәсенә оештырылганнар. Һичбер төрле дим, дәляләт итү (пропаганда) булганы юк, һичбер төрле тәртипкә салынган гомуми җыелышлар булганы юк, матбугат әле үз тарафыннан чын-чынлап эшкә керешеп, катгый мөгайян[4] булган бер ноктаны алга сөргәне юк – шулай була торып, әфкяре гомумия үз-үзеннән инде бер нокта тирәсенә якынлашып өлгергән.

Урта Русия мөселман матбугат мувәкъкатәсе[5], алдан һичбер төрле мөзакәрә итмичә[6], үз-үзеннән бертөрле нокталар тирәсендә оешты:

Имин, гафиф[7] милләткә иҗаби җәһәтеннән[8] танылган сәвияи мәдәниясе[9] белән югары урын ишгаль итә[10] торган кеше генә мөфти булырга тиеш! – диде.

---

[1] Әфкяре гомумиясе – гомуми фикере.

[2] Сабикъ – элекке, әүвәлге.

[3] Дин эшлеклесе Мөхәммәдьяр Мөхәммәдшәриф улы Солтанов (1836–1915) – 1866–1885 елларда Уфа губернасы Минзәлә һәм Бәләбәй өязләрендә мировой арадашчы, казый. 1886 елдан Оренбург мөселманнары диния нәзарәте мөфтие.

[4] Мөгайян – билгеле, ачык.

[5] Матбугат мувәкъкатәсе – вакытлы матбугаты.

[6] Мөзакәрә итмичә – фикер алышмыйча.

[7] Гафиф – саф, пакь.

[8] Иҗаби җәһәтеннән – уңай яктан.

[9] Сәвияи мәдәниясе – мәдәни тигезлеге.

[10] Урын ишгаль итә – урын тота, били.

Төрле сыйныф халкының нәкыль әфкяре[1] булган мәсләкләре дә беркадәр аерыла торган урта Русия мөселман матбугат мувәкъкатәсе, фәкать хакның шул төрле-төрле сыйныфларның теләкләрен белгәнлектән генә менә шул фикер тирәсендә тотты да оешты.

Мин соңгы көннәрдә Казан имамнарының иң нөфүзлеләреннән[2] берничәсе белән, Казан мөселман зыялыларының шактыйлары белән, сәүдәгәрләреннән берничә кешеләр белән бу тугрыда сөйләшеп уздым. Дөрестерәк тәгъбирә иткәндә, сөйләшеп уздым да түгел, бәлки аларның фикерләрен тыңладым, алар һәммәсе алдан иттифаклашып[3] куйган шикелле:

Имин, гафиф, милләткә иҗаби җәһәтеннән танылган сәвияи мәдәниясе белән югары тора торган кеше генә мөфти булырга тиеш! – диләр вә шул шартларга тугры килүләре уйланган берничә кешеләрнең исемнәрен зикер итәләр. Нинди даирәгә барма, нинди сыйныфка мәнсүб[4] татар белән сөйләшмә, ул исемнәре зикер ителә торган затлар – бер үк дип әйтергә мөмкин кешеләр, бу даирләрнең һәрберсе шул бер үк кандидатлар тирәсенә оеша алырлык күренәләр. Монафикъ миллияне аңлый башлаудан килеп чыккан бу әфкяре гомумиянең тагы шул ягы шаян игътибар ки, һәрбер даирә үзе күрсәтергә теләгән кандидатын хөкүмәт эчендә кабул ителерлек сәяси мәсләкләре белән могтәдил[5] кешеләр арасыннан сайлаганнар ки, моннан аңлашылуына күрә, әфкяре гомумия бу кандидатларын бер нәмаиш[6] буларак тәкъдим итми, бәлки хөкүмәтнең үз тавышына колак салуын өмид иткәнлегеннән тәкъдим итәдер.

Без, табигый, хөкүмәт даирәсендә бу мәсьәләдә татар әфкяре гомумиясенә колак салынып-салынмаячыгын катгый бер сурәттә әйтә алмыймыз. Ләкин дахилия нәзарәте[7] башына кенәз Щербатовның[8] чакырылуы бу тугрыда өмидле бер вакыйга булса кирәк, диеп зан итәмез[9]. Бу тугрыда мин берникадәр зыялыларның фикерләре белән таныштым, аларның күбрәге кенәз Щербатовның дахилия нәзарәте башында булучылыгын хәерле фал итеп каршы алалар. Моннан да башка сабикъ мөселман фракциясенә мөнасиб депутатлардан берсе белән дә мин бу тугрыда фикер алыштым, ул миңа шундый бер вакыйга зикер итте:

---

[1] Нәкыль әфкяре – сүз иреге.

[2] Нөфүзлеләреннән – авторитетларыннан.

[3] Иттифаклашып – берләшеп.

[4] Мәнсүб – караган.

[5] Могтәдил – уртача.

[6] Нөмаиш – күренеш.

[7] Дахилия нәзарәте – Эчке эшләр министрлыгы.

[8] Николай Борисович Щербатов (1868–1943) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, эчке эшләр министры (июнь – сентябрь, 1915 ел).

[9] Зан итәмез – уйлыйбыз.

Үткән Дума вакытында мөфти Солтановның истигъфа итү[1] хәбәре чыккач, мәзкүр зат Русиядәге гайре[2] милләтләрнең дини эшләрен идарә итүче господин Минкинга[3] мөрәҗәгать итеп, аннан бу тугрыда нинди хәрәкәт күтәргә мөмкин икәнчелеген сорашкан. Хосусый бер мәҗлестә вә хосусый сөйләштә бирелгән бер сөальгә господин Минкин болай диеп җавап биргән:

– «Мин әле ул тугрыда катгый бер сүз әйтә алмыйм, ләкин шулай да уйлыйм, бу тугрыда без мөселман фракциясенең әгъзаларыннан фикерләрен сорашырмыз вә алар күрсәткән кандидатлардан үземез өчен мөнасибрагын[4] тәгъйин итәрмез[5]. Әле мадам ки, Думада мөфти сайлау хакында закон үткәргәнеңез юк. Бу юл бердәнбер тугры юл булыр диеп зан итәм», дигән.

Менә болардан аңлашылуына күрә, хөкүмәтнең бу тугрыда татар әфкяре гомумиясенә игътибар итәчәген тәхмин итәргә мөмкин булачактыр.

Болай диеп уйлаган өчен мине артык оптимист диеп гаепләүчеләр табигый булыр. Мин үземнең оптимизм белән мөбтәля[6] икәнемне бервакытта үз-үземнән дә вә кешедән дә яшермим, фәкать аны гафу иттертү мәҗбүриятендә булынсам, дөньяда шулай тору уңгаерак, дим генә.

Бу мәсьәләдә миңа пессимистлар фикере белән дә танышырга тугры килде. Алар әйтәләр:

– «Татар әфкяре гомумиясенең хөкүмәт даирәләренә фәкать сәлби тәэсире генә булыр. Тотарлар да нинди дә булса Гыйниятулла казый Капкаев[7] яхуд Сафа мәхдүм Баязитовны[8] тәгъйин итәрләр, менә

[1] Истигъфа итү – эштән чыгу.

[2] Гайре – башка.

[3] Россия империясе Эчке эшләр министрлыгының чит диннәр буенча эшләр департаменты җитәкчесе.

[4] Мөнасибрагын – яраклырагын.

[5] Тәгъйин итәрмез – билгеләрбез.

[6] Мөбтәля – дучар.

[7] Гыйниятулла Капкаев (1856–1930) – мөселман дин һәм җәмәгать эшлеклесе, Оренбург мөселманнары диния нәзарәте (1893–1917) һәм БАССР мөселманнары Үзәк диния нәзарәте (1920 еллар) казые. Гыйниятулла Капкаев 1914 елда Санкт-Петербургта ачылган «Сыйрател-мөстәкыйм» («Туры юл») Бөтенроссия мөселманнар берлеген нигезләүчеләрнең берсе булып тора. 1920 елларда БАССР мөселманнары Үзәк диния нәзарәте казые.

[8] Баязитов Мөхәммәдсафа Гатаулла улы (1885–1937) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе. 1911 елдан Санкт-Петербургның 2 нче мәхәлләсе имамы, соңрак Санкт-Петербург ахуны һәм Петербург хәрби округы имамы, шул ук вакытта хәрби уку йортларында ислам мөгаллиме, Россия империясе Тышкы эшләр министрлыгы тәрҗемәчесе. «Нур» газетасының мөхәррире һәм нашире. 1914 елда Санкт-Петербургта Бөтенроссия мөселманнарының «Сыйрател-мөстәкыйм» берлеген оештыра һәм аның җитәкчесе була. 1915 елда мөфти итеп итеп билгеләнгәч, 1916 елда Уфада диния нәзарәтенең рәсми басмасы – «Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Ырынбургия» журналын чыгаруны яңарта. Февраль революциясеннән соң Сафа Баязитов мөфтилектән төшерелә.

аннан соң мөфти Солтановны сагынып йөрермез, яхуд идарәи руханиямезне телгә алырга җирәнә башлармыз! – диләр.

Ләкин мин һич тә, һич тә вакытка бу ихтималларны башыма китерергә теләмим.

– Ник? – диярсез.

Чөнки... Чөнки бу кешеләр милләткә фәкать сәлби якларыннан танылу белән бергә хөкүмәткә дә боларның чын хезмәт күрсәтә алганлыкларын без беремез дә белмимез. Алыйк Гыйниятулла Капкаевны. Мин бу кешене гомеремдә бер мәртәбә дә күргәнем юк. Ләкин минем аның хакында бик күп нәрсәләр ишеткәнем бар. Зате[1] мулла гаиләсендә туып үскән һичбер кеше, мин уйлыйм, Гыйнният казыйга бирелә торган мәшһүр «садака»лар мөнәсәбәте белән аның хакында ишетми кала алмаганнардыр.

Хуш, алыйк Гыйниятулла Капкаев әфәндене.

Бу кешенең образовательный бер цензысы юк, голүм дөньясы соң дәрәҗәдә накыйс[2] (Кышкар хәлфәсе), моның өстенә дә чирек гасыр идарәи руханиядә казый булып торган дәверендә бу кеше идарәи руханияне ислах тугрысында дип әйтим, бәлки идарәи руханиягә тәгъликъле эшләрне бик аз гына бер тәртипкә китерү тугрысында да һичбер вакытта һичбер төрле эш күрсәткәне юк.

Аның чирек гасыр идарәи руханиядә казый булып торуы фәкать сәлби нәтиҗәләр генә бирде. Шулай булгач, ни дип, нәрсә өчен дип, аны мөфти итәргә кирәк. Хөкүмәт даирәләренә бу кешенең хезмәт күрсәткән булуын тагы уйларга юл юк. Чөнки үзенең тугрыдан-тугры вазифасы булган идарәи рухания эшләрен эшләүдә дә бу кеше эшсезлектән башка бернәрсә күрсәтә алмагач, моның нинди даирәдә хезмәт итә алуы мөмкин? Гыйниятулла Капкаевның казыйлык сөрүеннән бер хатирә калса, ул да фәкать аның үзенең Уфада сатып алган пулаты гынадыр. Казыйлык ләвазимендә[3] елга сигез йөз сум вазыйфә[4] алып хезмәт итә торган кешенең зур бер пулатка ия була алуы, табигый, аның бөтенләй булдыксыз кеше түгел икәнен күрсәтә аладыр. Ләкин бу булдыклылык имтихан кылынырга бара торган бичара фәкыйрь шәкертнең унысына, йөзесенә генә түгел, бәлки меңнәренә инде күз яшьләре бәһасенә дә торгандыр. Без – мәдрәсәдә ятып, аннан һәр елны имтиханга бара торган шәкертнең казый әфәндегә «садака» өчен акча хәзерләп киткәнен күреп торган кешеләр. Бу булдыклылыкның бәһасен бик яхшы аңлыймыз. Садака бирү – яхшы эш, фәкыйрь кешегә аны алу да ярый торгандыр. Бәлки, әмма инде «садака» бирү вә «садака» алу – аларның хөкемнәре башкарак. Имтиханга бара торган шәкертләр арасында бер мөтәгариф[5]

[1] Зате – шәхсән үзе.
[2] Накыйс – җитешсез.
[3] Ләвазимендә – хезмәтендә.
[4] Вазыйфә – хезмәт хакы.
[5] Мөтәгариф – билгеле, танылган, мәшһүр.

сүз бар: – «садака» егерме бишлек кәгазь булса, үзең имам-хатыйп мөдәррис буласың, әмма инде садакаң бишлек кенә булса, имам була алуыңа да куан! – диләр.

Бу гынамы соң әле: идарәи рухания тирәсендә мирас низаглары йөрткән һәрбер мулла вә һәрбер мөәззин белә ки, эченә кредитный билет салынган чәйне идарәи рухания тирәсендәге «бәгъзы берәү»ләр яратып эчәләр... Чәе «садака» булган шикелле, эченә салынган билеты да «садака» була.

Вакытында Ризаэддин хәзрәт тә казый булып торды[1]. Ләкин ул Уфадан өстенә бер җонлы тун да ясый алмаган халәттә китте. Әмма Гыйниятулла әфәнде... ул инде Уфаның чын бае:

– Ходай «бәхет» биргәч, нишлисең соң!

Хәзергә Гыйниятулла хәзрәт тугрысында җитеп торсын, кирәк булса, без аңар тагы бер мәртәбә кайта алырмыз әле, килик Сафа мәхдүм хәзрәтләренә. Мин үземнең оптимистлыгым муҗибенчә[2], аның да мөфти була алуын да хәтеремә китерергә дә теләмим:

– Ник? диярсез.

Чөнки, «Сыйрател-мөстәкыйм» скандалы белә дә исеме былчыранган бу кешенең хәзер һичбер җәһәттән мөфтилек урынына тамгы итәргә хакы юктыр. Ул әллә нинди шөбһәле максудлар өчен, әллә нинди шөбһәле мөәссәсәләргә малны илтеп тыкмакчы булуы белән милләт алдында исемен былчыратса; башлаган эшендә вөҗүдкә чыгара алмаучылыгы белән шул эшне башлаткан даирә арасында да кадерен җуйган булырга тиештер.

Без «Новое время» гәзитәсендә[3] чыккан дача пожары мәсьәләләрен монда хәтергә алып тормыйча гына, бары Сафа мәхдүмнең голүме диния сахибе булмаганы шикелле, гали образовательный цензага да малик түгел икәнен генә хәтергә төшереп китәргә тиеш күрәмез. Кирәк голүме диния әрбабы булу алга сөрелсен, кирәк голүме дөньявия әрбабы булу алга сөрелсен, Сафа мәхдүмнең мөфтилек урынына цензасы юктыр.

Шөбһәле хәрәкәтләр дә, бөтен гомуми мәсьәләләремез дә вак интригачылыкта гаепләнә торган бу кешене мөфти итү рухани идарәне бетерү касды белән генә эшләнергә мөмкиндер. Менә шуңар күрә, бу көндә мин аның мөфти ителүен һич мөмкин күрмим. Моның өстенә Маклаковның[4] дахилия нәзарәте башыннан китүчелеге дә Сафа

---

[1] Ризаэддин Фәхреддин улы Фәхреддинов (1859–1936) – 1891 елдан Уфа шәһәрендә Оренбург мөселманнары Диния нәзарәтендә казый. 1906 елда бертуган Рәмиевләр чакыруын кабул итеп, Оренбург шәһәренә күченеп килә.

[2] Муҗибенчә – сәбәпле.

[3] 1868–1917 елларда Санкт-Петербург (Петроград) шәһәрендә басылган көндәлек сәяси һәм әдәби газета.

[4] Николай Алексеевич Маклаков (1871–1918) – Россия империясе дәүләт эшлеклесе, эчке эшләр министры (1912–1915), Дәүләт советы әгъзасы. 1915 елның 5 июнендә министр вазифасыннан азат ителә, әмма совет әгъзасы булып кала.

мәхдүмнең мөфтилек тамгысын[1] шактый бастырган дип риваять итәләр. Гүя ки, әүвәлдә ул дахилия нәзарәтендә беркадәр хисабтагы «егет» саналса да, соңгы алмашынудан соң аның зәмине[2] бөтенләйгә җуелган[3] имеш.

Менә шушы мөляхәзәләр[4] белән мин пессимистларча, тотарлар да Сафа мәхдүм яхуд Гыйниятулла Капкаевны мөфти итеп куярлар дигән сүэ заннарга[5] ышанмыйча, бу тугрыда татар әфкяре гаммәсенә колак салыныр дип уйлауда дәвам итәм.

Моннан соң инде мөфтилеккә әфкяре гомумия тарафыннан күрсәтелә торган затларга бераз тукталырга тугры киләдер.

Бәгъзы бер мәгълүмат җыелып җитүне көтеп, алар тугрысындагы мөляхәзәләрне язуны берничә көнгә кичектереп торырга тугры киләдер.

*(«Кояш». 1915. 26 июнь.)*

*Басмага әзерләде:*

***Хөснетдинова Гөлназ Азат кызы,***

*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

*К печати подготовила:*

***Хуснутдинова Гульназ Азатовна,***

*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела текстологии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*kh-gulnaz71@mail.ru*

---

[1] Тамгысын – зур теләген.

[2] Зәмине – җирлеге.

[3] Җуелган – югалган.

[4] Мөляхәзәләр – фикерләр, уйлар.

[5] Сүэ заннарга – начар фикерләргә.

УДК 398.8

*Л.Х. Дәүләтшина*

# ТАТАР ЙОЛА ФОЛЬКЛОРЫНЫҢ БҮГЕНГЕ ЯШӘЕШЕ: СОЛДАТКА ОЗАТУ ЙОЛАСЫ

Статья посвящена комплексному анализу обряда проводов в армию *(солдатка озату йоласы)* как культурного феномена, раскрывающего его историческую эволюцию, структуру и семантику. Научная новизна работы заключается в исследовании обряда как целостного комплекса, объединяющего ритуальные практики, фольклорные тексты (рекрутские песни, поверья) и мифологические верования. В научный оборот вводятся опубликованные источники и неопубликованные полевые материалы автора, демонстрирующие трансформацию обряда от эпохи рекрутчины до современности. Исследование показало, что ядро ритуала составляют уличные обходы с исполнением рекрутских песен; магические практики при уходе рекрута из дома, ритуальная трапеза (каша, хлеб и др.), а также символика границ, проявляющаяся в преодолении порога и прощании у ворот деревни. В заключении подчеркивается, что исследуемый обряд представляет собой устойчивый комплекс, функционирующий в фольклорной традиции по сей день и сохраняющий основную структуру и семантику в условиях меняющегося мира.

**Ключевые слова:** фольклор, традиция, татарская фольклористика, переходные обряды, рекрутский обряд, проводы в армию.

The article is devoted to a comprehensive analysis of the ceremony of sending off to the army (Soldatka Ozatu Yolasi) as a cultural phenomenon, revealing its historical evolution, structure and semantics. The scientific novelty of the work lies in the study of the rite as an integral complex combining ritual practices, folklore texts (recruitment songs, beliefs) and mythological beliefs. Published sources and unpublished field materials of the author are introduced into scientific circulation, demonstrating the transformation of the rite from the era of recruitment to the present. The study showed that the core of the ritual consists of street rounds with the performance of recruit songs; magical practices when a recruit leaves home, a ritual meal (porridge, bread, etc.), as well as the symbolism of borders, manifested in crossing the threshold and saying goodbye at the village gates. In conclusion, it is emphasized that the ritual under study is a stable complex that functions in the folklore tradition to this day and preserves the basic structure and semantics in a changing world.

**Keywords:** folklore, tradition, Tatar folklore studies, transitional rites, recruitment ceremony, sending off to the army.

Ир-егетләрне хәрби хезмәткә озату йоласы (рекрут йоласы) татар халкының традицион мәдәниятендә зур урын алып тора һәм ил тарихы белән бәйле вакыйгаларга барып тоташа. Фәнни әдәбиятта рекрут йоласының барлыкка килүе регуляр армия булдырган Пётр I заманына нисбәт ителә [5: 13]. Бу вакыйга 1705 елда егетләрне рекрутлыкка җыю турында указ чыгуга бәйле. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1722 елдан татарларны да хәрби хезмәткә ала башлыйлар [1: 97].

Рекрутлар гамәлдәге армиянең нигезен тәшкил итә, дәүләт хисабына тотыла, бердәм кием һәм корал белән тәэмин ителә.

Гаилә корып, тормыш көтәргә тиешле егетләрнең гомерлеккә йортыннан аерылуы авыр кичерелгән. Китүчеләрнең күбесе кире өенә кайта алмаган, рекрутлар яралардан, авырулардан һәм җәзалардан үлгәннәр, шуңа күрә ир-егетләрне хәрби хезмәткә озату аларны соңгы юлга озату буларак кабул ителгән. Әлеге вакыйгаларга җавап буларак, Россия территориясендә яшәүче халыкларда, ир-егетне үлемнән саклап калу максатыннан, рекрут йоласы барлыкка килгән. Билгеле булганча, һәр халыкның рухи мәдәниятендә кешенең биологик яки социаль статусын алыштыруга бәйле барлыкка килгән күчеш йолаларының (переходные обряды – *А. ван Геннеп термины*) булуы билгеле (бала туу, туй, соңгы юлга озату һ. б.). Рекрут йоласы да бу төр йолаларның берсе булып, ир-егетләрнең исән-сау әйләнеп кайтуын тәэмин итү максатыннан, халык яшәешенең бер өлешенә әверелгән һәм ритуаллар, ышанулар, фольклор текстларның берләшүе нәтиҗәсендә без бүгенге көндә солдатка озату йоласы дип атый торган йола комплексының гасырлар дәвамында яшәвенә сәбәп булган. Әйтергә кирәк, рекрут йоласы һәм аның белән бәйле фольклор – татар фольклористикасы фәнендә иң аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе. Әлеге йола белән бәйле халык авыз иҗаты әсәрләренә 13 томлы «Татар халык иҗаты» тупланмасының җыр томнарында, «Милли-мәдәни мирасыбыз» сериясендә чыккан китапларда, фольклорчы, диалектолог, этномузыкологларның хезмәтләрендә беркадәр игътибар бирелсә дә, солдатка озату йоласының тәртибе (повестка алу, урам әйләнү, кунак булып йөрү, озату кичәсе һ. б.), аның белән бәйле җырлар, ышанулар, ырымнар һ. б. бүгенге көнгә кадәр тулы бер комплекс буларак тикшерелмәгән.

Рекрут – татар теленә рус теле аша кергән француз сүзе (фр. *Récruter – «гаскәр туплау»*) булып, XVIII гасыр – XX гасыр башында Россия империясендә даими армиягә гаскәриләр туплау алымын һәм гаскәринең үзен атый. Татарлар арасында әлеге сүзнең «никрут» формасы киң таралган була. Пётр I үлгәннән соң, Россиядә аның кайбер тәртипләре кабат күздән кичерелә. Тарихтан билгеле булганча, патша армиясенә алынган кеше Екатерина II чорында 25 ел буена солдат хезмәтен үтәргә тиеш булса, алга таба бу вакыт – 20, 15, тагын да соңрак Александр II вакытында 6 елга калдырыла. Ике гасыр дәвамында халык җилкәсенә авыр йөк булып яткан рекрутчина Беренче бөтендөнья сугышы вакытында үзгәреш кичерә. Тарихтан билгеле булганча, бу вакытта хәрби хезмәткә алынучылар белән беррәттән сугышка яраклы барлык ир-атларны да чакыра башлыйлар, илдә гомуми мобилизация игълан ителә.

Илдә барган вакыйгаларның халык тормышында ни рәвешле чагылыш табуын шул заманда яшәгән кешеләрнең истәлекләре буенча күпмедер дәрәҗәдә күзаллап була. Ык буенда яшәүче татарларның рекрут йоласы белән бәйле җыр текстларын өйрәнгән фольклорчы галим Риф Мөхәммәтҗанов язмалары арасында XIX гасыр ахырында

туган кешеләрнең истәлекләре шактый. Шуларның берсе Башкортстан Республикасы Шаран районы Алпай авылында өч сугышта катнашкан Якуп Игъдиевтан (1896 елгы) язып алынган. «Беренче империалистик сугышка кадәр, никрутлар булып игълан ителгәч, ике атна буена өйдән өйгә йөртеп, җыру, наз әйтеп (Ык буе татарларында рекрут җырларын «назлар» дип атаганнар. – *Л.Х. Дәүләтшина иск.*), безне сыйладылар. Авыл өчен кадерле идек. Кыңгыраулы атлар хәтәр бизәлгән, бер-бер авылны китәсе көнне генә өчәр тапкыр урадык. Кайда туктасак, шунда сый, шунда наз әйтү, елашу, гармунга бию, кочаклашып саубуллашу. Соңгы көн бигрәк ямансу, бөтен авыл, туган-тумача, ата-ана, сөйгән кызлар озата чыга. Үзем дә ул күп җыру, наз әйтеп, аз яшь түкмәдем. Авыр була иде аерылышу» [7: 22].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яшәгән кешеләрнең истәлекләреннән күренгәнчә, хәрби хезмәткә алынган вакытларда, татар авылларында ир-егетләрне һәрвакыт җыр белән озатканнар, өйдән өйгә йөртеп, сый-хөрмәт күрсәткәннәр. Мәҗлес атна-ун көн буе дәвам иткән. Бөтен авыл, басу капкасын чыкканчы, аларны озатып калган. Татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә төрле җыр текстлары башкарылса да, аларның барысы да туган яктан аерылу, билгесез киләчәк турында уйлану мотивларын алга чыгарган, сагыш хисе белән сугарылган.

Совет чорында хәрби бурыч мәсьәләсенә мөнәсәбәт үзгәрә: солдатка алыну, армия сафында хезмәт итеп кайту һәр ир-егетнең бурычы дип игълан ителә һәм хәрби хезмәткә озатуның тантаналы бәйрәм рухында үтә торган йолалары барлыкка килә. Әмма шул ук вакытта халыкның традицион озату йоласы да, яңа гадәтләр белән баеп, тормыш үзгәрешләренә яраклашып дәвам итә. Солдатка алынган яшьләрнең үзләре генә җыелып, һәм гаиләдәге якыннары, сөйгән ярлары белән бергә хушлашу мәҗлесләре үткәрүләре менә шуннан килә.

Горур совет солдаты исемен йөртүче хәрбиләр тормышында тыныч вакытлар да, аянычлы сугышлар да булып торган. Аларның иң куркынычы – әлбәттә, Бөек Ватан сугышы. Бу чорда сугышка китүчеләрне озату үзгә төс ала, чөнки ил күләмендә дошман белән көрәшкә бөтен халык күтәрелә. Халкыбызның күп гасырлык тәҗрибәсен туплаган иҗаты сугыш чорларында үзгәреш кичерә, яңа шартларга җайлаша һәм үсештән туктамый. Халык йоласына туры китереп, сагышмоңнарын авыл көенә салып, туган ягы, якыннары белән саубуллашып фронтка киткән ир-егетләр сугыш кырында да рухи ихтыяҗларын фольклор әсәрләре аша канәгатьләндерәләр, җыр, бәет, мәзәк, тапкыр сүзләр телдән телгә күчеп таралалар. Бу чорда борынгыдан килгән һәм тирән кайгы-хәсрәт белән сугарылган җырлар алгы планга чыга, сагыну хисе халык иҗатын тулысы белән биләп ала.

Солдатлар китә – озатаек,
Басу капкаларын чыкканчы;

Озата бардым, карап калдым,
Күз керфеккәйләрем талганчы.

Солдатлар китә сайланып,
Билләренә каешлар бәйләнеп;
Исәннәр йөрсәк, бер кайтырбыз
Туган-үскән җирләргә әйләнеп.

Атларның җиктем мин карасын,
Һич белмәдем кая барасын;
Барасы җирләргә барып җиткәч,
Җәлләмәгез язу карасын [10: 28].

Бөек Ватан сугышы тәмамланган, илгә тыныч тормыш килгән, шулай да ир-егетләр ел да хәрби хезмәткә алынып торган, солдатка озатулар заманага бәйле үзгәрешләр кичереп, нигездә, традицион рәвештә дәвам иткән. Совет чоры узганнан соң, хәрби сафларда күп нәрсә үзгәрә. Бүгенге көндә хезмәт итү вакыты бер ел тәшкил итсә дә, армиягә озату йоласы хәзер дә яши, ватаныбызның төрле почмакларында бу йоланың үз традицияләре саклана.

Күрүебезчә, ир-егетләрне хәрби хезмәткә алуның инде күп гасырлык тарихы бар. Россиядә яшәгән халыкларның һәрберсенә кагылган бу күренеш аларның милли-мәдәни үзенчәлекләрен үз эченә алган солдатка озату йоласы формалашуга китергән, аның гасырлар буена калыплашып килгән тәртибен, ышану-гадәтләрен саклаган хәлдә дәвамлылыгын тәэмин иткән. Биредә гасырдан гасырга күчә килгән йола-гадәтләрнең, мифологик ышанулар белән сугарылып, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән төп үзенчәлекләрен барлап, солдатка озату йоласының хәзерге яшәешенә тукталып үтик.

Бу йола иң элек кеше күзе күрмәгән, кеше аягы басмаган ерак һәм куркыныч юлга чыгып китү процессын ничек тә җиңеләйтү, егетнең исән-сау әйләнеп кайтуын тәэмин итү максатыннан башкарыла. Чит якка, ерак юлга чыгып китәргә тиешле кеше, аның нәкъ менә солдат булуы да мәҗбүри түгел, һәрвакыт ниндидер йолалар аша үтәргә тиеш, чөнки ул үз өеннән чит юлга чыга. Ә юлга чыгучы кешенең һәр адымы ышанулар белән бәйле. Тупсадан уң аяктан атлап чыгу, киткән кеше артыннан идән себерергә ярамау, кире әйләнеп кермәү, утын күтәреп керү – болар барысы да я юлчы, я аны озатып калучылар тарафыннан башкарылырга тиешле мөһим гамәлләр.

Халык ышануларында юл, бигрәк тә билгесез юл, һәрвакыт куркыныч, кеше аягы басмаган, түбән рухлар, зыян салучы көчләр яши торган җир буларак тасвирлана. Юлның үлем, бәла-каза китерә торган җир булуы яңа йортка нигез сайлау йолаларында аеруча ачык күренә. Татар халкы өйне беркайчан да тыкрык, юл, җиде юл чатына салмый, чөнки мондый йортта яшәсәң, кайгы киләсе көн кебек ачык. *Тыкрыкта өй салырга ярамый. Чат бит ул. Яшәп булмый андый йортта. Бетә андый нигез, диләр. Безнең берәү төзегән иде тыкрыкта. Үзе*

*озак та тормады, үлеп китте. Инде аннан соң әллә ничә гаилә торып карады. Берәү дә яши алмый. Тыныч түгел анда* (И.В. Иванов (1929), Татарстан Республикасы Питрәч районы Керәшен Сәрдәсе авылы). Юл буена салынган йортларның тынычсыз булуы халык мифологиясендә юлда очраган мифологик персонажлар белән бәйле. Адаштыра торган урыннар да күбесенчә берничә юл кисешкән җиргә туры килә, шуңа күрә юлда җен зәхмәте кагылмасын, бәла-казалар килмәсен, юлчы өенә кире әйләнеп кайтсын өчен, билгеле бер йолалар үткәрелә. Һәр очракның (солдатка китү, соңгы юлга озату, күрше авылга кунакка бару, эш белән ерак юлга чыгу һ. б.) үз йола-гадәтләре бар, әмма аларның мәгънәсе бер үк: һәрберсе кешенең исән-сау әйләнеп кайтуын тәэмин итүгә, таныш булмаган җиргә әзерләп чыгарып җибәрүгә юнәлтелгән.

Солдатка озату йоласы да иң беренче чиратта юл семантикасына бәйле булып, төрле этаплардан оеша. Элек-электән килгән гадәт буенча, солдатка китәргә әзерлек повестка алуга ук башлана. Бу вакытта авылның һәр кешесе әлеге йолага үз өлешен кертә. Хәрби хезмәткә алынучы егетләр, бергә җыелып, бәйрәм киемнәрендә, көн саен диярлек рекрут җырларын башкарып, гармун белән урам әйләнәләр. Әлеге гадәтнең көндәлек тормыштан инде әкренләп югалуы күзәтелсә дә, гармун тартып, авылны яңгыратып җырлап йөрү традициясе әле бүген дә очрый. Рекрут җырлары төрле булып, гадәттә, бер буыннан икенчесенә күчә килә һәм күп вакытта авыл көенә башкарыла. Аларда туган яктан, туган йорттан, әти-әнидән аерылу мотивлары да, сагыш, киләчәк тормыш өчен борчылу да, батырлык, өмет хисләре дә чагыла. Татарлар яшәгән кайсы төбәкне алсаң да, рекрут җырлары халык хәтерендә саклана, буыннан буынга күчә. Әйтик, Марий Эл Республикасында бүгенге көндә дә яшьләр авыл көенә түбәндәге җырларны җырлап урам әйләнәләр.

Арыслан айга сикерә,
Каршысында тал булса.
Кайгырма, егет, кайгырма,
Газиз башың сау булса.

Әллә кайдан күренеп тора
Магистраль ташлары.
Ал булса да, гөл булса да,
Калды ич Куян яклары.

Солдатларга аш бирәләр
Калай тәлинкә белән.
«Смирно», диеп кычкыралар
Калын тавышлар белән.

Әй, дусларым, беләсезме,
Без бит Куян яклары.
Башларымның төрле уйлар
Уйлый торган чаклары.

Алма бакчасын чабыгыз,
Үткен булса чалгыгыз.
Су өстендә дулкын ничек,
Безнең шундый чагыбыз [6: 302].

Истәлекләргә караганда, XX гасыр урталарында әле бу хәрәкәткә үз авылы гына түгел, китәсе егетләр яшәгән күрше авыллар да кушылган, бер авылдан бер авылга барып, урам әйләнү гадәте булган. Армиягә китәсе егет иң элек йорттан йортка кереп саубуллашып йөри, аңа бүләккә дип әзерләп куелган кульяулык, сөлгеләр җыя. Берничә атнага сузылган урам әйләнү белән беррәттән, авылдашлары егетләрне кунакка да чакырып ала. *Бик матурлап гармун уйнап урам әйләнәләр иде. Көн дә урам әйләнәләр иде, җырлап, китә торган кеше. Мин кечерәк вакытта берәмләп-берәмләп кунакка йөртәләр иде китә торган кешене. Туган-тумачасы, дус-ишләре шулай итеп йөртә торганнар иде* (Газизова Р.Г. (1919), Марий Эл Республикасы Бәрәңге районы Куян авылы). *Повестка алгач, күрше-күлән, туганнар кунакка чакыра инде. Я үзеңне генә, я дустың белән бергә. Чәй эчкәннән соң, юл хәере бирәләр* (Дәүләтшин И.З. (1976), Татарстан Республикасы Мамадыш районы Түбән Козгынчы авылы). Шул рәвешле, рекрутлар үзләрен авыл кешеләреннән аерып куялар, ягъни икенче социаль статуска күчүләрен күрсәтәләр һәм авылның үзе, авылдашлары белән саубуллашалар.

Хәрби хезмәткә китәсе егет авыл социумында үз урынын билгеләп, социаль статусын күрсәтеп кенә калмый, бәлки авыл тирәсендәге сакраль мәгънәгә ия объектлар белән дә саубуллашып, үз ниятмаксатларын аңлатып, алдагы юлының уңышлы булуын тәэмин итәргә тырыша. Билгеле булганча, татар халык мәдәниятендә изге урын төшенчәсе шактый әһәмияткә ия. Изге дип чишмә дә, кабер дә, таш та, агач та саналырга мөмкин. Әлбәттә, бу очракта сүз очраклы объект турында түгел, ә бәлки могҗизасы булган яисә могҗизалы хәлләр белән бәйле объект турында бара. Бу төр объектларга карата халык традициясендә билгеле бер ритуаллар һәм таләпләр да яшәп килә: изге урын янына даими барып, аны карап, чүп-чарлардан арындырып тору; гомумән авыл яисә аерым бер кеше авыр хәлгә тарыса, изге урынга барып, бу хәлдән котылдыруны сорау; аның янында эшләргә рөхсәт ителгән һәм тыелган гамәлләр комплексы – болар барысы да авыл социумында билгеле кагыйдәләр.

Солдатка китәсе егетләр дә әлеге күренештән читтә калмый. Ерак юлга кузгалырга тиешле рекрут, китәренә берничә көн кала, изге урын янына барып, үз теләкләрен әйтә, Ходайдан исән-сау әйләнеп кайтырга ярдәм итүен сорый. Татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә очраган изге урыннарның күбесе, риваятьләрдән күренгәнчә, ислам динен таратып йөргән әүлия/яхшылар/шәех/ишан кaберләре белән бәйле. *Менә безнең Нурислам армиягә китәр алдыннан Ташамышка Акташына садака калдырам дип керде.... Аны өйрәттем. Башта бисмилланы әйт, аннары дога язып бирдем, шуны укырсың, дидем.*

*Аннары теләкләрен әйтә инде. Изге юл сорый. Садакасын сала. Белмичә бармыйсың инде, белеп барасың* [4: 5]. Әлеге таш Татарстан Республикасының Биектау районы Казаклар авылы янында урнашкан һәм, халык ышанулары буенча, бу урында изгеләр җирләнгән дип исәпләнә, шуңа да авырлык килгәндә, Акташ янына барып, садака бирү – авылда киң таралган күренеш.

Китәсе көн якынлашкан саен, рекрутларның аралашу урыны әкренләп авыл җирлегеннән бер йорт даирәсенә күчә. Биредә иртәгә китәсе дигән көнне кичтән озату кичәсе (провод, озату боткасы, озату ашы һ. б.) үткәрелә. Озату кичәсенә егетнең дуслары, сөйгән кызы, туган-тумача, күрше-күлән чакырыла. Табынга төрле-төрле ризыклар чыга, яшьләр җырлап-биеп күңел ача. Кайбер якларда махсус ризык – *озату боткасы* әзерләү гадәте булганлыгы да билгеле. Нинди дә булса ярмадан тәмле итеп ботка пешерелә, аның уртасына, күз ясап, сары май салына. Ритуаль ризык буларак аңланган һәм төрле йолаларда төрле вариантларда тәкъдим ителгән ботка табынның төп сые буларак уртада тора, аннан һәр кеше авыз итәргә тиеш була. Кунаклар ботка ашарга утыргач, китәсе егет озату җырын башлап җибәрә.

Боткалар да пешкән, майлар сипкән,
Ашыйсы килми, туганнар, нишлим соң.
Атлар гына җиккән, капка ачкан,
Китәсе килми аерылып, нишлим соң.

Ишектән лә чыктым, мин таелдым,
Әти-әни сездән үк аерылдым.
Капкадан ла чыктым, мин таелдым,
Бар туганнар, сездән үк аерылдым.

Карлыгачлар кара, муены ала,
Югары ла очып югала.
Бәхетле лә бала илдә кала,
Бәхетсезләр китеп лә югала.

Тәрәзәне ачтым, мин сызгырдым,
Болындагы печәннәр кипсен дип.
Болындагы печәннәр ай кипте инде,
Безгә китәр вакытлар җитте инде.

Җырлап бетергәч, егетне өстәл тирәли кояш уңаена өч тапкыр әйләндерәләр, ата-анасы, әби-бабасы бәхилли, теләкләрен тели [2: 232].

Озату кичәсе үткәргәннән соң, икенче көнне иртән егетнең исән-имин әйләнеп кайтуын тәэмин итә торган магик йола-гадәтләр башкарыла. Өйдән чыгып китәр вакыт җиткәч, өй эчендәге кешеләр өстәл артына җыелалар. Егетнең әнисе алдан ук әзерләп куйган ризыгын улына каптыра һәм махсус урынга сакларга куя. Татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә әни кулыннан алына торган ризыклар, аларның саклану урыннары да күптөрле. *Өстәл янында утырганда, әни бер телем ипи бирә, аны тешлисең дә кире әнигә бирәсең, ул аны пич өстенә*

*куя. Кайтканчы тора инде ул шунда* (Татарстан Республикасы Мамадыш районы Түбән Козгынчы авылы). *Энемнең сыныгын кыстырып куйган идек. Кибән башын кисеп, бер тешли дә, матчага элеп куясың* (Татарстан Республикасы Биектау районы Өлә авылы). *Озатыр алдыннан сыек кына камыр ясыйбыз. Егет шунда кулын тыгып, матчага кулын баса, аның кул эзен үзе кайтканчы саклыйбыз* (Татарстан Республикасы Апас районы Багыш авылы). *Ишектән чыгар алдыннан өч йотым сөт, өч кабым аш ашый. Калган ашын өйдә калган киеменең кесәсенә сала, һәм ул, үзе кайтканчы, шунда тора* (Төмән өлкәсе Төмән районы Турай авылы). *Китәсе көнне терлек суясың. Каз суясыңмы инде анда, тавык суясыңмы. Шуның ботын бирәсең инде икмәк белән. Аны кимереп бетерсә – сөяген, кимереп бетермәсә, ризыгын чорнап-төйнәп куябыз инде сандык төбенә* (Татарстан Республикасы Питрәч районы Янсуар авылы). Татар халкының бу гамәлләре артында «киткән кеше исән кайтсын дип, ризык һәрвакыт теләп тора» дигән ышану ята.

Мич яки өстәл янынннан егетнең кеше күзе күрмәгән чит якларга юлы башлана, әмма аңа әле, юлга чыкканчы, берничә чикне үтәргә кирәк. Бу чикләрне ничек үтүенә карап, аның исән-сау әйләнеп кайту-кайтмавы да тәгаенләнә. Иң беренче чик – ул ишек тупсасы, шуңа күрә тупса аркылы чыкканда саклау магиясе актуальләшә. Татарстан Республикасының Питрәч районында егетне, «Исән-сау йөреп кайт» дип әйтеп, тышкы ягы белән өскә каратып салынган тун аркылы атлатып чыгаралар. Саратов өлкәсендә яшүче татарлар рекрутны тупса аркылы йөзе белән түгел, ә киресенчә «йөзе белән кайтсын дип», аркасы белән чыгаралар. Төмән өлкәсенең Турай авылында исә ана кеше, «үз кулым белән озаттым, үз кулым белән каршы алырга насыйп булсын» дип, улын күкрәгеннән, аркасыннан ике кулы белән сыпыра. Шул ук өлкәнең Янтык авылында теләү үткәрү гадәте саклана. Егет китәсе көнне иртәдән тавык суела һәм аның чыгып китәр вакыты җиткәч, тавыкны рекрутның башы, култык асты, биле тирәли өч кабат әйләндерәләр. Ишектән чыгарганда, күп якларда егетнең кесәсенә «Үзеңнең туфрагың белән йөре, үзеңнең туфрагыңа кайтып бас», дип, туфрак салынган кечкенә янчык салып җибәрәләр. Бары шушы ым-хәрәкәтләрне башкарганнан соң гына, ана күңелендә улының исән-имин кайтачагына ышаныч туа.

Йорт, ихата эченнән саубуллашып чыгып киткәннән соң, егетләр һәм аларны озатучылар соңгы чиккә – басу капкасына таба юл тоталар. Белүебезчә, элек авылга керә торган урында капка торган һәм аның каравылчысы булган, һәр килгән-киткән кеше шуннан исәнләшеп-саубуллашып узган. Бу үзенә күрә «авыл дөньясына» керү урыны булып исәпләнгән. Бүгенге көндә авыл капкалары инде булмаса да, авылга барыбер билгеле бер җирдән генә кайтып керергә һәм чыгып китәргә мөмкин. Бары шушы чикне узганнан соң гына, рекрутлар авыл белән хушлашалар һәм чын мәгънәсендә юлчыга

әвереләләр. Шуңа да өйдән басу капкасына кадәрге юл үтү магик гадәтләр белән сугарыла.

Бу аралыкны бары китәсе егет үзе, аның әнисе һәм якыннары гына уза ала. Әмма авылның башка кешеләре бу йолага катнашмый дигән сүз түгел. Аларның да бу көнне үз вазифалары бар. Күп очракта авылда яшәүчеләрнең барысы да диярлек капка төбенә чыгып, хәерле юл теләп, юл хәере биреп, китүчеләрне озатып кала. Мамадыш районында таралыш тапкан гадәт буенча, кызлар чиккән кулъяулык бирәләр һәм егетләр аларны бер-берсенә бәйләп, муеннарына урыйлар. Басу капкасыннан чыгып киткәндә, егет кеше озын бау булып сузылган кулъяулыкларны, үзе кайтканчы саклансын өчен, анасына биреп калдыра. Бу кулъяулыклар егетнең туган йортына таба сузылган юлын символлаштыра һәм аны туган нигезе белән бәйли. Саратов татарларында кулъяулыкны басу капкасына, я булмаса авыл исеме язылган тактага бәйләп калдыру гадәте киң таралган [3: 49]. Аксубай якларында рекрут өйдән өйгә кереп, саубуллашып, авылдашларыннан фатиха алып чыгарга тиеш. Бу йола барышында һәр өйдән кулъяулык бирү гадәте дә бар. Егет бу кулъяулыкларны бер-берсенә бәйләп, муенына чорный бара. Авылдан чыгып киткәндә, аларны басу капкасына яисә шунда үскән агачка ныклап бәйләп китәргә тиеш була. Егет кайтканчы кулъяулыкның өзелеп төшмәве – аның туган җиренә исәнимин әйләнеп кайтачагына бер ишарә буларак кабул ителә. Шушы юл белән егетләр туган нигезгә бәйлелекләрен символга әйләндереп, ерак юлга чыгып китәләр һәм беренче тукталышка – военкоматка юл тоталар. Военкоматка кадәр хәрби хезмәткә китүче егетне туганнары, дуслары озата бара. Сугыш чорымы, тыныч вакытмы – кайчан гына булса да, җыр-бию туктамаган, хәрби хезмәткә китүче ир-егетләр авыл көен уйнап, тирә-якны яңгыратып, моң-зарларын җырга салып, юлга чыккан.

Сау бул, Ярмәк, сау бул, Ярмәк,
Юкәле тауларың белән.
Сау бул, Ярмәк, рәхәт яшә лә
Калган яшьләрең белән.

Әткәем-әнкәем, сау булыгыз,
Еллар кайтмый улыгыз.
Бу китүдән кайта алмасам,
Туганнарым, сау булыгыз.

Сандугачлар килгән безгә,
Китәрләрме икән көзгә?
Язгы сабантуйларына
Кайтырбыз микән без дә?..

Каршыбызда Юкәле тау
Тагын яшәрер әле.
Ходай гомерләрне бирсә,
Бергә яшәрбез әле [8: 107–108].

Җыр-моң, гармун көе белән үрелеп барган бу шау-шулы күренеш военкомат ишегалдына кадәр дәвам итә, аннан инде якыннары, егетне калдырып, өйләренә кайтып китә.

Авыл капкасыннан егетне һәм аны военкоматка кадәр илтүчеләрне озатып җибәргәннән соң, ана кеше һәм якыннары өйгә әйләнеп кайталар һәм йорт беркадәр вакыт гомум авыл яшәешеннән читләшеп тора. Егет чыгып киткән йорттан беркемгә бернәрсә бирмиләр, өстәлне җыештырмыйлар, идән себермиләр. Татарлар яшәгән күп төбәкләрдә киткән кеше артыннан, «озын гомерле булсын» дип, утын яисә чыра күтәреп керү гадәте киң тарала. Себердә исә, гадәттә, ике чыра алып керәләр һәм берсен, егет кайтканчы дип, алып куялар. Ул исән-сау әйләнеп кайткач, күсәйтен чәе дип аталган мәҗлескә чәйне шушы чыра белән кайнаталар [9: 453]. Бу гадәтләр киткән кешенең туган нигезе белән бәйләнешен саклауга юнәлтелә, һәм юлчы «суны чыкканчы», йортның шушы статусы саклана. Әлеге сүз-формула да борынгы ышануларга барып тоташа. Элек ана кеше баласын беренче суга кадәр озатып бара торган булган, бары шуны кичкәннән соң гына, егет авылдан чыгып киткән дип исәпләнгән. Бүген исә андый гадәт гамәлдән төшеп калган, әмма «суны чыкканчы» дигән сүз һаман да халык күңелендә яши һәм, нигездә, бер көн дигәнне аңлата. Шулай итеп, егет киткәннән соң, бер көн тирәсе вакыт узгач, йорт гадәттәге тормышы белән яши башлый.

Хәрби хезмәткә киткән ир-егетнең исән-имин кайтуын солдатка озату йоласы гына тәэмин итми, йөрәк парәсе читтә йөргән кешенең һәр гамәле аны көтүгә, аның исән-имин кайтуын тормышка ашыруга юнәлдерелгән була. Көндәлек искә алулар, теләкләр белән беррәттән һәр җирлекнең үзенең калыплашкан йола-гадәтләре дә яшәп килә. Әйтик, Татарстанның Саба районы Олы Шыңар, Лаеш районы Атабай авылларында Сабан туен үткәргәндә нәзер аты, нәзер атын котлау дигән гадәт билгеле. Билгеле булганча, Сабан туенда иң беренче килгән атка иң мәртәбәле бүләкләр бирелә, аның исеме телләрдән төшми. Бу якларда халык соңга калып килгән ат турында да онытмый, ул гарьләнеп елый дип ышана. Шуңа да соңга калып килгән атка атап, алдан ук нindидер эшнең уңышлы килеп чыгуына ышанып, вәгъдә билгесе – махсус бүләкләр бирелә. Нәзер аты күп вакытта беренче килгәненә караганда да күбрәк бүләккә ия була. Әлеге бүләкләр арасында махсус адарынып, армиядә йөрүче улы исән-сау кайтсынга, озак вакытлар авырып ятучы туганы терелсенгә һ. б. шундый очраклар уңышлы тәмамлансынга, алдан ук атап, нәзер итеп бирелгәннәре дә күп була. Гомумән алганда, нindидер эшне башкару алдыннан, уңай килеп чыккан очракта, үз-үзеңә берәр йөкләмә үтәргә вәгъдә бирү, ягъни нәзер әйтү гадәте – татарлар арасында киң таралган күренеш.

Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, солдатка озату йоласы гасырлар дәвамында калыплашкан ритуалларны, аның белән бәйле ышану, ырым, җыр текстларын берләштереп, тулы бер йола

комплексы хасил итә. Бу йоланың бер генә сүзе дә, ымы, хәрәкәте дә мәгънәсез түгел, аларның һәрберсе егетнең туган нигезе белән бәйләнешен өзмичә, исән-сау кире әйләнеп кайтуын тәэмин итә һәм мифологик ышануларга, халыкның тормыш тәҗрибәсенә нигезләнә. Бүгенге болгавыр заманда да солдатка озату йоласы үзенең төп калыбын саклый һәм йола-гадәтләрнең бер буыннан икенче буынга күчүен тәэмин итә.

**Әдәбият**

1. *Абдуллин Х.М.* Татары в регулярной армии в период Отечественной войны 1812 г. и заграничных походов 1813–1814 гг. // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2024. Т. 14. № 3. С. 96–107.

2. *Баязитова Ф.С.* Керәшеннәр: Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. Казан, 1997. 248 б.

3. *Давлетшина Л.Х.* Мир вокруг нас: о современном состоянии мифологической традиции татар. Казань: ИЯЛИ, 2024. 120 с.

4. *Завгарова Ф.Х.* Типология сюжетов почитания культового камня у татар Заказанья // Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре. (Фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы). Өченче китап. Казан, 2007. Б. 4–11.

5. *Кормина Ж.В.* Проводы в армию в пореформенной России. Опыт этнографического анализа. М.: Новое литературное обозрение, 2005. 376 с.

6. *Мөхәмәтшина Л.М.* Күңелдәге җырлар // Милли-мәдәни мирасыбыз: Марий Эл татарлары. Бәрәңге. Казан, 2021. Б. 288–311. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).

7. *Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортостан Ык буе татарларының йола иҗаты. Практик эш материаллары. Уфа, 1984. 72 б.

8. *Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Самара татарларында заман фольклоры // Милли-мәдәни мирасыбыз: Самара өлкәсе татарлары. Казан, 2015. 360 б.

9. Татар халык иҗаты: 25 томда. 2 т.: Йола фольклоры / төз., текст, иск. һәм аңл. әзер., кереш сүз авт. Л.Х. Дәүләтшина. Казан: Татар. кит. нәшр. 2022. 541 б.

10. Утлы еллар кайтавазы: Бөек Ватан сугышы чорында татар халык иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 199 б.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире*

***Давлетшина Лейла Хасановна,***
*доктор филологических наук, заведующий отделом народного творчества Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*leyla.davletshina@yandex.ru*

УДК 9-05

***Р.Ә. Абзалина***

# КҮҢЕЛ МАТУРЛЫГЫН СУРӘТЛӘРЛЕК ПУМАЛАЛАР БАРМЫ ДӨНЬЯДА?..
## (К. Насыйри портретын ясау тарихы)

Статья посвящена истории создания общеизвестного портрета ученого-просветителя Каюма Насыри (1825–1902), ставшего хрестоматийным. Автор, опираясь на воспоминания современников К. Насыри, повествует, как последующие поколения ученых и художников старались воссоздать образ ученого-просветителя и энциклопедиста, который никогда не фотографировался. Каждое воспоминание, оставленное современниками о нем, говорит об их собственной степени возможного понятия его учености и воспитанности, самого главного его намерения – на что суждено было ему посвятить всю свою жизнь. В воспоминаниях современников Каюма Насыри личный характер и творческое лицо раскрывается по разному: если одни не очень приветствовали его малословность в общении с людьми, особое отношение к своему внешнему виду, то другие, особенно земляки, почти каждую черту его характера, также образ его жизни считали примером, хотя и не досягаемым для всех желающих стать праведными как он. Они прекрасно понимали, что каждое его деяние идет от его стремления к довольству Всевышнего, для пользы общества, не забывая о своем статусе в обоих мирах. Земляки лучше всех понимали его ум, мудрость и желание просветить свой народ полезными и нужными знаниями, накопленными восточно-западным опытом в мировой цивилизации. Он сам добился этого, и мы – его потенциальные последователи хотя и очень медленно идем к пониманию его.

**Ключевые слова:** Каюм Насыри, портрет, современники-земляки, воспоминания, графика, художник Байназар Альменов, татарская культура.

The article is devoted to the history of the creation of the well-known portrait of the enlightenment scientist Kayum Nasyri (1825–1902), which became a textbook. The author, based on the memoirs of K. Nasyri's contemporaries, tells how subsequent generations of scientists and artists tried to recreate the image of a scientist, educator and encyclopedist who had never been photographed. Every memory left by his contemporaries speaks about their own degree of possible understanding of his scholarship and upbringing, his most important intention – what he was destined to devote his whole life to. In the memoirs of Kayum Nasyri's contemporaries his personal character and creative personality are revealed in different ways: if some did not really welcome his laconicism in communication with people, his special attitude to his appearance, then others, especially his fellow countrymen, considered almost every feature of his character, as well as his way of life, an example, although not attainable for all who wish to become righteous like him. They understood perfectly well that each of his actions came from his desire to please God for the benefit of society, not forgetting about his status in both worlds. His fellow countrymen understood better than anyone his mind, wisdom and desire to enlighten his people with useful and necessary knowledge, accumulated by the East-West experience in world civilization. He himself achieved this and we – his potential followers, although very slowly move towards understanding him.

**Keywords:** Kayum Nasyri, portrait, contemporaries, fellow countrymen, memories, graphics, artist Baynazar Almenov, tatar culture.

Әлеге мәкалә мәгърифәтче, галим Каюм Насыйриның (1825–1902) киң җәмәгатьчелеккә билгеле, популяр портретын ясау тарихына багышлана. Автор галимнәр һәм рәссамнарның, К. Насыйриның замандашлары истәлекләренә таянып, аның образын тудырырга тырышулары турында сөйли.

Ислам дине кануннары мөселманнарга кеше һәм хайван-җәнлек сурәтләрен өй-мәктәп диварларына элергә рөхсәт итми. Халыкка ул андый йорттан фәрештәләр кача дип, бик катгый тәртиптә кереп калган. Фото мәсьәләсендә дә шулайрак. Ләкин күренекле мөселман татар галимнәре Ш. Мәрҗани, Р. Фәхреддиновның фотопортретлары булган. Ш. Мәрҗани үз портретын инглиз энциклопедиясенә сораткач ясаткан. Р. Фәхреддиновның балалары белән эшләнгән гаилә фотолары бар. Ул диварга элү өчен түгел, истәлек итеп альбомнарда сакларга дип фәтва калдырган.

Күренекле татар мәгърифәтчесе, педагог, галим-энциклопедист Каюм Насыйри бер тапкыр да фотога төшмәгән. Ләкин менә тууына 200 еллап вакыт үткәннән соң, нигездә, рәссам Б. Әлминов ясаган портрет аша аның тышкы кыяфәте, холкы, галимлеге белән бергә үрелеп, бик анык булып күз алдына килеп баса: озынча чандыр йөз, үзе белгәннәрне башкаларга белдерү тактикасын һәм стратегиясен уйлап торган тәвәккәл уйчан күзләр, сүзләрен үлчәп кенә чыгара алган иреннәр, киң маңгай. Истәлекләрендә чәчләрен бераз озынчарак йөртә дип язылса да, гомердә дә яланбаш итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирмәгән, үзенә бик тә килешле кырпулы бүрек. Заманына күрә бик фасонлы, буйлы ак күлмәк һәм урта озынлыктагы тездән бераз түбән җилән яки тун.

Совет чорында Каюм Насыйриның иң беренче портретын аның тууына 100 ел тулуны бәйрәм итәргә җыенганда Госман Арсланов дигән рәссам ясаган була. Истәлекләр буенча бик тә ачык итеп күз алдына китерергә ярдәм иткән бу портрет голәманы канәгатьләндереп бетерми. 1944–1945 елларда инде аның 120 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә татар Ломоносовының кыяфәтен бераз тантаналырак итеп күзаллау ихтыяҗы яңадан баш калкыта. Бу эшне күренекле галим, Казандагы Тел, әдәбият, тарих институты директоры Мөхәммәт Хәйрулла улы Гайнуллин рәссам, график Байназар Мостафа улы Әлминовка махсус заказ белән ясата.

1944 ел, Каюм Насыйриның 1945 елда үткәреләсе 120 еллыгына әзерлек вакыты. Әле ул вакытта Казанда Каюм Насыйрины хәтерләгән, аннан дәресләр алган шәкерт-бабайлар исән. Бу эшләрдә Мөхәммәт Гайнуллин Б. Әлминовка ярдәмче консультант итеп язучы Мөхәммәт Галине (1893–1952) билгели. М. Гали белән Б. Әлминов, икәүләп, Казан буйлап Каюм Насыйрида укыган бер бабайны эзләп табып, аның белән бик озак сөйләшкәч, «Әлеге карт рәсемгә төшәргә риза булмаса да, үзенең кыяфәте белән минем күз алдына килә башлаган Каюм Насыйри образын байтак кына көчәйтте», – дип искә ала үзенең «Каюм Насыйриның портреты ничек туды» дигән мәкаләсендә

Б. Әлминов. «Шуннан соң мин эшкә керештем. 5–6 вариант ясагач, портретны тотып, Мөхәммәт абый белән теге Каюм Насыйрида укыган бабайга яңадан бардык. Рәсемнәрне күрсәттек, кайсы вариантның кай ягы белән Каюм Насыйрига якынрак булуын сораштык. Шуннан соң кайтып, мин тагын бер портрет ясадым. Монысын да күрсәттек. Картыбыз хуп күрде: «Нәкъ үзе», – диде. Әйткән фикерен раслатыр өчен булса кирәк, ул бездән рәсемне үзенең элекке сабакташына күрсәтеп алырга киңәш итте. Без ... бабайны эзләп таптык. Танышып, хәл-әхвәл сорашканнан соң, аңа соңгы портретны күрсәттек һәм аның кем икәнлеген әйтеп бирүен үтендек. Карт шунда ук:

– Бу безне укыткан Каюм хәлфә, – диде.

Безгә шул гына кирәк иде дә.

Мөхәммәт ага Гали институтның бер утырышында шушы портрет вакыйгасын сөйләп бирде һәм ул гыйльми советта расланды. Сезнең күз алдыгыздагы портрет шулай туды. Мин шуннан соң да Каюм Насыйриның портретын берничә вариантта ясадым» [2].

Якташы буларак та һәм туган авылым Олы Ачасырда 1982–1997 елларда Каюм Насыйри исемендәге архитектура-этнография музеен төзегәндә дә минем өчен бу мәсьәлә бик актуаль булып, Б. Әлминов фотога төшмәгән Габделкаюм Габденнасыйр аганың мондый эчтән нурлы голәма портретын ничек ясый алды икән, дигән уй башымнан чыкмады.

«Совет мәктәбе» журналының 1975 елгы өченче санында басылып чыккан мәкалә бу мәсьәләгә тулы ачыклык керткән булыр иде дә бит, ләкин мин аның белән таныш булмыйча, үземчә мәгълүмат эзләвемне дәвам иттем. Каюм Насыйриның фикердәш имамнары Гайнеддин (1810 елгы) һәм Сәгъдеддин Таһириларның (1820 елгы) ага-энеләре Гыйрфанеддин Сәгъдеддин улының (1854–1902) оныгы Габбаз Габделхәбир улы аша миңа килеп ирешкән риваятьләрнең берсе буенча: «1945 ел башында Каюм Насыйриның 120 еллык юбилеена әзерләнеп йөргән вакыт, Ширданга 6 рәссам кайтып төшә. Каюм Насыйриның ниндирәк кыяфәттә булуын авылдашларыннан сорашып, алар һәммәсе К. Насыйри портретының үз вариантларын ясыйлар. Шулар арасыннан авыл кешеләре сайлап, менә бу Каюм Насыйрига охшаш дигәне Б. Әлминовныкы булып чыккан». Менә монысы инде – күрше авыл халкы хатирәсе.

Чынлап та, 1945 елның гыйнвар-февраль аенда Югары Ширданга Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре экспедиция белән кайталар. Галимне күргән-белгән кешеләрдән истәлекләр яздырып, авыл күренешләрен һәм кешеләрне фотога төшереп, соңыннан истәлекләрне бастырып та чыгаралар. Бу материаллар Мирасханәдә 11 фонд, 3 тасвирлама, 7 саклау берәмлеге булып теркәлгән. Хәмит Ярми көндәлегендә: «Югары Ширдан авылында без Ибәтуллин Әхмәдулла абзыйда тордык, аның улы Абдулла Паратскийда заводта эшли иде», – дип язып куйган [8].

Бу вакыт Югары Шырданга кайткан галимнәр арасында Хәмит Ярми, Гомәр Хисаметдинов, Халидә Гатина бар, рәссамнар турында истәлек теркәлмәгән.

Каюм Насыйри турында истәлекләрендә Габдулла бине Таҗетдин әл Кәчмәри аның тышкы кыяфәтен болай тасвирлап калдыра: «Габделкаюм әл-Насыйри әфәнде урта буйлы, зур башлы булып, чәчен җитүрәк йөртә иде. Борын вә авыз килешле, төсе ак түгел, бәлки богдай төсендәрәк, йөзе ачык түгел, караңгырак иде. Күзләре зәгыйфь булудан язуны күзенә бик якын китереп карый иде. Мыекны җитүрәк йөртә. Сакалы сирәк булып, артык озын җибәрми иде. Йөрүе әкрен, алдына карап турырак басып йөри. Хәлен белгән адәмнәр, элек русча укып йөргән вакытларында европачарак та киенеп йөргән, диләр» [5].

Габдулла бине Таҗетдин әл Кәчмәри Каюм Насыйридан: «Миңа рәсемегезне һәдия кылсагыз, тәзкирә – ядкәр булыр иде, дидем. Җавабында: “Рәсем алдыртмадым”, – диде, бәлки “Алай булса, сезгә менә тәзкирә”, – дип, бәгъзысы хадис, бәгъзысы хәкимнәр сүзеннән гыйбарәт сигез кисәк үз каләме илә язылган язуын бирде» [5].

Шул ук җыентыкта Кукмара районы Пычак авылында яшәгән Мөхәммәтхәниф Мозаффари Каюм Насыйри турында атасы Мөхәммәтҗан Мозаффаридан ишеткән истәлеге урын ала: «Мин Шиһап хәзрәт мәдрәсәсендә шәкерт вакытымда Габделкаюм әфәнде белән күп катыштым. Аның үз сүзенә караганда, уң күзенә кызамык илә ак төшкән вә сул күзе тумыштан сукыр булган. Уң күзе яхшы күрә иде. Ләкин даим күк күзлек истигъмаль кылды. Аягында савырлы читек-кәвеш, өстендә ак көмеш тамгалы постау казаки, борынгы әйләнмә якасыз зәңгәр постау чикмән, зәңгәр постау чалбары кәвеш йөзенә төшеп тора иде. Башында бер карыш киңлегендә камчат бүрек, кулында җәйләрдә зонтик, кышын кыска таяк тота, төлке тамак толып вә яхшы туннары да бар иде. Шырданда утыз-кырык умартасы булган. Умартасы кырык баштан артмады, утыздан кимемәде дип сөйли иде. Йөргәндә алдына гына карап йөри, һичкемнең кибетенә кереп сөйләшеп утырмый, урамда да сөйләшеп тормый. Сөйләшергә теләүче булса: “Фатирыма бар, шунда сөйләшербез”, – дия иде. Каһкаһә белән көлгәнен ишетмәдем, тәбәсеме (елмаюы) дә аз булгандыр.

Сурәт алдыру мәсьәләсенә килсәк, Каюм әфәнденең аңа хилаф булмавы беленә. Ул үзе сурәтләр тоткан. Бервакыт эткәмезгә Шиһап хәзрәт сурәтен күрсәткән. Ләкин инкяр галәмәте бер дә беленмәгән» [6].

Гомумән, Каюм Насыйри тарикать әдәпләрен нык белгән генә түгел, ул аларны тоткан: үзенә кагылмаган эшкә кысылу һәм мөгамәлә күрсәтүне кирәк санамаган. Каюм Насыйриның үз вакытында алдырган фото һәм рәсемен аның хакында язучылар да күрмәгәннәр һәм безнең дә күргәнебез юк әле. Әдәбият кабинетларында урын алган һәм хрестоматия-дәреслекләргә урнаштырылган рәсем аны күрүчеләрнең истәлекләреннән чыгып кына эшләнгән. Гомеренең соңгы елларында аның рәсемен сорап килүчеләр булган. Ләкин Каюм

Насыйри аларга: «Рәсем алдырганым юк», ә алдырып бирүен сораучыларга: «Ач вакытта да хәлемне сорамадылар, хәзер соң инде», – дигән мәгънәдәрәк җавап биргән [1].

Аның бу турыда бәхәс корып, сөйләшеп торып, вакыт әрәм итәсе килмәгәнлегеннән дип тә аңларга кирәк.

Каюм Насыйри гомеренең һәр минутының кадерен белә. Малны да таба, тота белә, аны тиешле урыннарга тарата да белә. Васыятьләрендә үзе өчен хаҗга барасы кешеләргә хәтле язып калдыра. Кыз туганы, ата-ана хакын хаклый.

Шулай да ул үзенең төп эшен татар фәнен аякка бастыруда, кешегә файдалы гыйлемнәрне аңлаешлы татар телендә татар кешесенә язып, аңлатып бирүдә күрә. Ул бу фәннәрне Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәгърифәтеннән яңарта. Аның барлык хезмәтләре «Менә күрегез, мин нинди кәттә галим», – диюдән түгел, үзе белгәннәрне белмәгәннәргә белдерү, кешеләрнең көнкүреш ихтыяҗларын җиңеләйтү, файдалы итү өчен башкарылган.

«Каюм Насыйри 1865 елда Казанның ямщик Мөсәгыйть кызына өйләнгән булган. Бер елдан соң хатыны бала хастасыннан үлә. Шуннан соң Насыйри ялгыз, гаиләсез яши», – диелгән галимнең тууына 120 ел тулу уңаеннан үткәрелгән гыйльми сессия материалларында [1].

Югарыда бер искә алынган Габбаз абый Хәбировтан (1913–1995) килеп ирешкән риваять буенча, ул яңадан өйләнгән була. Ләкин озак яши алмый. Хатынның эти-әнисен, бар туганнарын чакырып, мәҗлес җыя, кунак иткәч: «Кызыгыз бик күркәм, бер сүзем юк. Ләкин мин гаилә тормышы өчен яратылмаганмын ахры. Фән белән мавыгып, үземнең гаилә кешесе икәнен бөтенләй онытам. Кызыгызны алып кайтып, ышанычлы кешегә урнаштырыгыз», – дип кайтарып җибәргән», ди.

Каюм Насыйри мәгърифәт өчен дөнья ләззәтләреннән ваз кичкән дип әйтү дөрес түгел. «Мине Алла китап язар өчен яраткан, бу көннән язмый утыру аның хөкеменә каршылык булыр дип куркам», – ул бу эшне чын күңелдән үзе дә ләззәт алып башкара белгән [7].

Каюм Насыйри турында истәлек калдырган бик күп кешеләр аның янына төрле киңәшләр, бигрәк тә авыл муллалары төрле авырулардан дәва сорап килә торган булганнар. Ул һәр кешене кабул итә, башта хәлен сорый, чәй янында булса, янына утыртып, чәй эчәргә тәкъдим итә. Зыя Бәхтияровның астрономия дәреслеген язуын бик хуплап, китап табып биреп ярдәм итә. Киңәш, ярдәм сорап килгән кешеләрнең берсен дә кире бормый. Купшы сүзләр белән түгел, туптуры кыска итеп аңлатып бирә. Тар фикерлелекне бер дә яратмый: «Дөньяда шуннан башка бернәрсә дә юк дип беләсеңме әллә?» – ди ул һәрвакыт бер нәрсә турында сорап йөдәткән кешеләргә.

Хатип Алишев дигән кеше аның элеккеге Мәрҗани, хәзер Каюм Насыйри урамында торган йортын хәтерләп болай яза: «Ишектән кергәч тә, аның өенең алгы ягында һөнәр кирәк-яраклары (зур гына

пыяла савыт, бер станок һ. б. нәрсәләр) күзгә ташлана. Уртада мич, мич яныннан ишексез генә бүлмә корылган, мич артыннан почмакка кереп китә. Анда стенага кара такта эленгән. Шунда берничә бала укыйлар. Бүлмә янында тәбәнәк аяклы өстәл. Утыргычлар юк. Өстәл өстендә язылган кәгазьләр, китаплар, глобус, җәзбәләр һәм башка геометрия кораллары бар. Мин аннан бер айлап чамасы геометрия укыдым. Шул вакытта аның өстәлендәге бу нәрсәләр турында мин аннан сораша идем. Ул миңа аңлатып сөйли иде. Шул ук бүлмәгә эленгән бер кием яңа чабата тора. Ул аны үзем тукыдым дия торган иде. Ул күптөрле һөнәрләр, гыйльми мәсьәләләр турында сөйләргә ярата иде. Электрик белән нәрсә көмешләү, көзге ясау, кимьяви (химический) нәрсәләр һәм башкалар турында сөйли иде. – Хатыннарның икмәк пешерү, икмәкне изү, салу эшләре дә кимья гыйлеме белән эшләнә», – ди торган иде.

– Һади балалар өчен төзегән әлифбасын миннән күреп төзеде, – дип сөйләгәне исемдә.

Мәдрәсәләрдә хисап, тарих, һәндәсә һәм һәйәт (астрономия) кебек фәннәр укылмауга бик пошынып сөйли иде. «Укытмыйлар бит шул кирәкле фәннәрне», – ди торган иде.

Аны Печән базарында «Сукыр Каюм» дип йөртәләр иде. Мин аның әсәрләрен укып, бик күп файдаландым.

Каюм Насыйриның юбилее булачагы турындагы хәбәрне ишеткәч, бер гарәп шагыйренең: «Күзләр олы йолдызларны кечкенә күрәләр. Ләкин аның гөнаһысы йолдызда түгел – күз кабагында» [1], дигән сүзләре искә төшә. Ничә буын Кизләү ишаннары, аннан алдарак Тау ягы – Тәтеш имамнары дәвамчысы Хатип Алишев-Әлмәти сүзләренә өтер дә өстисе килми. Ләкин хәзерге көнгә кадәр чын йолдызлар да, аларны адекват күрә алган күзләр дә, сирәк булса да, туа тора – моңа ышанасы, омтыласы килә...

Каюм Насыйри – татар мәдәниятендә галимнәрнең җанлы әйберләрне сурәтләүгә традицион карашын катгый рәвештә үзгәрешсез дәвам иткән мөселман галиме. Заманының кая таба барганын чамаласа да, ул моңа бик тыныч караган һәм нык позициядә кала белгән. Бик күп сорауларга хикмәти Хуҗа Насреддин кебек җавап биргән: «Нигә туныңны тышка әйләндереп йонлы ягын өскә куеп кидең?» – дигәнгә дә: «Җәнлекләр табигатьтә шулай йөри, минем табигатькә каршы барасым килми», – ди. Гәрчә моңа күнекмәгән кешегә туннарның яңа мода «доха» дигәне дә барлыгын аңлатып торуны файдасыз саный. Кеше турында фикер йөрткәндә, аның тышкы кыяфәте түгел, ә эчке дөньясы – күркәм холкы, белеме-зирәклеге мөһим, ди. Күркәм холык йөзгә якты нур булып эчтән бәреп чыга, үзе һәм үз чорына гына түгел, тирә-юньгә һәм вакытлар кичеп үз эшен эшләп мәгърифәт таратуын дәвам итә. Каюм Насыйри портреты – шуның бер мисалы.

**Кулланылган чыганаклар һәм әдәбият**

1. *Алишев Хатип Әлмәти.* Хатип Алишев истәлекләре. Каюм Насыйри (1825–1945). Казан: Таткосиздат, 1948. Б. 141.

2. *Әлминов Б.М.* Каюм Насыйриның портреты ничек туды // Совет мәктәбе. 1975. № 3. Б. 62.

3. *Гали М.* Зыя Бәхтияров истәлекләре. Каюм Насыйри (1825–1945). Казан: Таткосиздат, 1948. Б. 140.

4. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәге. К. Насыйри фонды: 11 ф., 3 тасв.

5. *Кәчмәри Г.Т.* Габделкаюм әл-Насыйри // Әдәби мирас. Өченче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 65.

6. *Мозаффар М.* Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында // Әдәби мирас. Өченче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 62–63.

7. *Хуҗаши әл Насреддин әл Хуҗаши.* Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри әфәнде белән мөсахабә // Әдәби мирас. Өченче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 73.

8. *Ярми Х.* Ю. Шырданда язылган көндәлек. 1945 ел. 6 январь – 11 февраль // ТР ММ. В 20320. 18 б.

***Абзалина Рәмзия Әсрареддин кызы,***
*Татарстан Республикасы Милли музее өлкән фәнни хезмәткәре*

***Абзалина Рамзия Асраровна,***
*старший научный сотрудник Национального музея*
*Республики Татарстан*
*globus54@list.ru*

УДК 355.292.3

*Г.М. Дәүләтшин*

## ФРОНТ ҺӘМ ФӘН ЮЛЫН УЗГАН ГАЛИМНӘР

В статье дается обзор жизни и научной деятельности ученых-фронтовиков, трудившихся после Великой Отечественной войны в ИЯЛИ: Я. Абдуллина, Ш. Абилова, Б. Гиззата, А. Каримуллина, И. Надирова, М. Мухарямова, Г. Юсупова и др. Опираясь на источники разного характера и личные воспоминания, автор описывает боевой путь и военные подвиги своих коллег, воспроизводит их жизненный путь как выдающихся личностей и авторитетных научных деятелей, создает своеобразный коллективный портрет поколения ученых-фронтовиков. Очерчиваются основные направления их деятельности, устанавливается вклад каждого из них в татарскую гуманитарную науку, перечисляются знаковые труды, актуальные для исследователей по сей день.

**Ключевые слова:** ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, Великая отечественная война, ученые-фронтовики, татарская гуманитарная наука, воспоминания.

The article provides an overview of the life and scientific activities of front-line scientists who worked at the Institute of Language, Literature, and History after the Great Patriotic War: Ya. Abdullin, Sh. Abilov, B. Gizzat, A. Karimullin, I. Nadirov, M. Mukharjamov, Kh. Yusupov and others. Relying on various sources and personal recollections, the author describes the military path and feats of his colleagues, reproduces their life path as outstanding individuals and authoritative scientists and creates a collective portrait of the generation of front-line scholars. The main areas of their activity are outlined and each of them is credited with their contribution to Tatar humanitarian science. The article also lists notable works that are still relevant for researchers today.

**Keywords:** G. Ibragimov Institute of Language, Literature, and History, Great Patriotic War, front-line scholars, Tatar humanitarian science, memoirs.

Бөек Ватан сугышы чоры совет халкы өчен дәһшәтле, авыр сынау буларак тарихка кереп калды. Җәмгыятьнең бөтен өлкәләренә тәэсир иткән кебек үк, фәнгә дә сугышның йогынтысы зур булды.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (ул вакытта Тел, әдәбият һәм тарих татар фәнни-тикшеренү институты) сафларын фронт авырлыкларын үз җилкәләрендә татыган, яраланып, кабат сафка баскан, инде шактый тормыш тәҗрибәсе туплаган, ил язмышы, халык тарихы һәм мәдәнияте белән тирән кызыксынган фронтовиклар тулыландыра.

Фронт юлын лаеклы узып, озак еллар Тел, әдәбият һәм тарих институтында хезмәт иткән галимнәрнең саны дистәдән артып китә. Аларның һәрберсенең фәнгә алып килгән үз юлы, үз тарихы бар. Сугыштан соңгы чорда дистә еллар дәвамында ветераннарга карата җылы мөгамәлә, ихтирам хисе һәрдаим сакланып килде. Бу хакта шәхсән үзем күреп тә, төрле елларда төшкән, Институт архивында

сакланган фотосурәтләрдән чыгып та һич шикләнмичә әйтә алам. Әлеге мәкаләнең максаты – агымдагы Ватанны саклаучылар елында һәм Бөек Ватан сугышында җиңүнең 80 еллыгын билгеләп узган көннәрдә фронтовик галимнәрне искә алу.

Казан дәүләт университетының СССР тарихы кафедрасында археолог А.Х. Халиков җитәкчелегендә аспирантураны тәмамлаганнан соң, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни архив җитәкчесе итеп билгеләндем. Архив татар тарихы һәм мәдәниятенә, борынгы кулъязмаларга, аерым шәхси фондларга бай иде. Биредә бик күп шәхесләр белән танышырга, аларның фикерләрен, истәлекләрен тыңларга мөмкинлек туды. Ике елдан соң, коллективның профком (ул вакытта местком) рәисе итеп сайландым. Бу җәмәгать вазифасын 6 ел (1979–1983 һәм 1987–1989) башкарырга туры килде. Шулай итеп, яңарак кына эшкә килгән, әле тәҗрибәсез, шактый дәрәҗәдә романтик рухлы яшь егеткә коллективка якынаю, байтак кешенең хәл-әхвәле белән танышу мөмкинлеге туды.

Шактый катлаулы елларда оешкан, кайчак тетрәнүләр кичергән (ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августындагы «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»гы, Татарстан өлкә комитеты бюросының 1944 елның 6 сентябрендәге «Татар тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтының эше һәм хаталары турында» карарлары гына да ни тора!) бу Институтта һәрберсе аерым игътибарга лаек галимнәр эшли иде.

Сүземне Институтта элгәрерәк (әле оешкан гына вакытында ук) эшләгән шәхестән башлап китәм.

**Хәсән Габдрахман улы Шабанов** (1901–1956) хәзерге Пенза өлкәсенең Мачали авылында туа. Ул – ике сугыш ветераны, Гражданнар сугышында да катнашкан.

Хәсән 1923 елда үз авылында мәктәп ача, 1932 елда Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлый. Алга таба Казандагы 80 нче татар мәктәбен җитәкли. Аннан шәһәр мәгариф бүлеге мөдире итеп күчерелә. 1939–1941 елларда Х.Г. Шабанов – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры. 1943 елда фронтка җибәрелә. Өлкән лейтенант Шабанов Берлинга кадәр барып җитә. Җиңүнең икенче көнендә аны снайпер яралый. Госпитальдә дәваланып Казанга кайткач, Хәсән Шабановны Татарстан китап нәшриятына – өлкән, аннары баш редактор итеп куялар. Ул балалар өчен берничә җыентык бастырып чыгара.

Мин Институтка килгәндә, **Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмов** (1922–1993) директор булып эшли иде.

Ул Башкорстанның татар әдәбиятына Дәрдемәнд, Мирсәй Әмир кебек классикларны биргән Җиргән авылында туа. 1940 елда 18 яшьлек Мидхәт, Казан элемтә техникумында укуын ташлап, Сызрань Танк училищесына керә, анда хезмәт итә. Хыялы – Кызыл армия командиры булу. Фронтка яшь танкист 1942 ел башында алына. СССР

өчен сугышның иң авыр чоры була бу. М. Мөхәррәмов, танкта каты пешеп, госпитальгә эләгә, ләкин 1942 елның декабрендә яңадан сафка баса. Курск сугышы вакытында ул элемтә офицеры булып хезмәт иткән корпус зур батырлыклар күрсәтә һәм гвардия корпусы була. Әмма 1944 елның гыйнварында гвардия капитаны М.К. Мөхәррәмовның, каты яралану сәбәпле, героик юлы өзелә, хәрби карьерасына нокта куела. Аны авыр хәлдә Ташкент госпиталенә җибәрәләр. Ике аягы да нык яраланган була. Биредә аңа уң аягын ампутацияләү белән килешергә туры килә.

Мидхәт Мөхәррәмов 1948 елда Казанда юридик институтны бишле билгеләренә генә тәмамлый. Әмма күңеле белән тарих фәненә тартыла. Ул 1951 елдан Тел, әдәбият һәм тарих татар фәнни-тикшеренү институтына эшкә кереп, гыйльми сәркатип вазифасын башкара, аннан тарих бүлеген җитәкли. Тарихчы, тарих фәннәре докторы (1964), профессор (1967), ТАССРның, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе (1972, 1982), Ленин, I һәм II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, ике тапкыр Кызыл Йолдыз орденнары кавалеры Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмов 18 ел (1963–1982) дәвамында Тел, әдәбият һәм тарих институтын җитәкли. Совет чоры кысаларына карамастан, Мидхәт Кәрим улы иң беренче чиратта Институт хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән хезмәтләрнең сыйфатына, архивларда күп эшләүче галим буларак, аларның фактик материалларга нигезләнүенә игътибар итә.

Галимнең «Татарстан АССР тарихы» (икенче том), «Татариянең партия оешмасы тарихы турында очерклар», «Татарстанда Октябрь инкыйлабы һәм милли дәүләт төзелеше» кебек капиталь хезмәтләрне әзерләүгә керткән шәхси өлеше гаять зур.

М.К. Мөхәррәмовның ныклы дәлилләнгән сүзенә югары партия, хөкүмәт оешмалары да колак салалар иде.

Мидхәт Кәрим улы Институт хезмәткәрләренә хөрмәтле, сакчыл карашта булды. Берәрсе турында кыек сүз әйтелсә, җитәкче буларак, «бу безнең эш» дип, һәрчак аны яклап чыкты.

Хәтердә, Институтта даими рәвештә, аеруча Равил Әмирханов тырышлыгы белән, хезмәткәрләр тарафыннан яратып укылган «Фикер» исемле стена газетасы әзерләнә иде. М.К. Мөхәррәмов та аның белән танышып барды. Бервакыт ул андагы язмалар арасында күренекле галим Хәлиф абый Курбатов турында, шаяртып, аның авыруына ишарәләп язылган юлларны күреп, «Хәлиф Рәхимович укыдымы, ул бу шаяруны ничек кабул итәр икән? – дип борчылып сорап куйды.

Кабинетына кергән өлкәннәрне, аеруча хатын-кызларны, Мидхәт аганың, урыныннан торып, култык таякларына таянып каршы алуы истә калган.

Бөек Ватан сугышында катнашкан галимнәргә профком тарафыннан игътибар шактый зур иде. Әмма шунысы сәер: аларның профкомга ниндидер гозерләр белән мөрәҗәгать итүләрен хәтерләмим дә диярлек. Бер елны директорыбызга санаторий юлламасы белән кыенлык туганны ишетеп, янына кердем. Башкалар алдында бераз

шаяртып: «Менә Гамирҗан нәрсә әйтер?» – дип куйды. Мин югалып калдым: «Ничек инде, сезгә...» – дип кенә әйтә алдым.

Ул елларда зур бәйрәмнәрне бергә җыелып уздыру гадәткә кергән иде. Аларда М. Мөхәррәмов та актив катнаша: Институт эшендәге уңышлар, алда торган мәсьәләләр турында кыска гына чыгышыннан соң, коллективның күңелен күтәрерлек шаяртуларга күчә иде.

М.К. Мөхәррәмов 70 яшен тутырып вафат булды. Бу шәхесне якыннан белгән замандашлары аны хаклы рәвештә батырлык, намуслылык эталоны, күп кенә кешелек сыйфатларының гәүдәләнеше дип саныйлар. Күпләр, галимнең фәнни казанышларын күздә тотып, хезмәтләренең Ватан историографиясендә зур әһәмияткә ия булуын билгеләде. Өченчеләр аңа «тормышка юллама» тапшырганы, нәтиҗәле ярдәм күрсәткәне һәм тарихчы һөнәрен үзләштерүдә булышканы өчен чын күңелдән рәхмәтле булдылар, дип искә ала коллегасы Р.Г. Әмирханов.

Мидхәт Кәрим улы турында аның хезмәттәшләре тарафыннан күп кенә истәлекләр язылган (Әкъдәс Борһанов, Әлфия Галләмова, Равил Әмирханов һ. б. хезмәтләре). Галимнең тууына 100 ел тулуга багышлап, саллы гына «Памяти М.К. Мухарямова. История. Профессия. Судьба» (2022) исемле китап та дөнья күрде.

М.К. Мөхәррәмов җитәкчелек иткән вакытта ук, Институтта ул чор өчен исеме дә, җисеме дә ятрак булган иҗтимагый фикер тарихы бүлеге оештырыла. Аның җитәкчесе итеп, тиздән директор урынын да биләячәк **Яхъя Габдулла улы Абдуллин** (1920–2006) билгеләнә.

Я.Г. Абдуллин – философ, философия фәннәре докторы (1978), профессор (1981), ТР ФА шәрәфле әгъзасы (1995), Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе.

Я.Г. Абдуллин 1920 елда Теләче районының Олы Кибәхуҗа авылында туа. Аны 16 яшендә үк район газетасына эшкә алалар. Испаниядә сугыш башлангач, Яхъя, үзен Кызыл армия сафларына алуны сорап, СССР Оборона халык комиссары Климент Ворошиловка хат яза. Финляндия белән сугыш башлангач, ул бу үтенечен җирле хәрби комиссариатка җибәрә. Егетнең теләге 1941 елны гына тормышка аша. Берничә мәртәбә яраланса да, ул сугышның иң дәһшәтле бәрелешләрендә: Сталинград оборонасында, Ленинград блокадасын өзү, Европаны азат итү һәм Берлинны алу өчен барган сугышларда катнаша. I дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, ике Кызыл Йолдыз ордены һәм 15 медаль белән бүләкләнә. Кызы Айгөлдә саф татарча язылган, берничә дәфтәрдән торган сугыш көндәлекләре саклана. Язмаларның бер өлеше басылып чыкты инде. Алар шактый дәрәҗәдә җентекләп язылган. Мәсәлән 1945 елның 2 маенда ул болай дип яза: «Ниһаять, 2 майда Берлин капитуляцияләде. Кояшлы көн. Җылы. Без урамнарга ташланабыз. Шпрее ярындагы бер паркка чыктык. Агачлар яфракларда, чәчәкләрдә. Безнең йөрәкләрдә дә шатлык. Паркка немец хатын-кызлары да чыкты, Интернационалны җырлыйлар, мөгаен, безгә ярарга тырышып. Ә паркта җимерек йортлар. Берлин хәрабәләр эчендә».

1986 елда мине фәнни архивтан Яхья Габдулла улы эшләгән иҗтимагый фикер тарихы бүлегенә күчерделәр. Я. Абдуллин талантлы, тырыш яшьләрдән торган коллектив туплаган иде. Ул вакытта ук күпләргә билгеле Ә.Г. Кәримуллинның да әлеге бүлектә эшләве нур өстенә нур булды, яшьләр белән өлкәннәр арасындагы эшлекле баланс булдырылды.

Күп еллар партия оешмаларында эшләвенә карамастан, Яхъя Габдулла улы гуманитар фәннәр өлкәсендә «Татар иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер тарихы» дигән фәнни юнәлешкә нигез сала, аның концепциясен булдыра, бу өлкәдә ислам дине һәм мәдәниятенең дә урынын билгели. Галим фәлсәфи, иҗтимагый-сәяси, тарихи, хокукый, әхлакый-этик һәм эстетик карашлар системасы буларак мәгърифәтчелек хәрәкәтенең эчтәлеген ача. Шиһабетдин Мәрҗани, Габденнасыйр Курсави, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри, Шәмсетдин Күлтәси кебек зыялыларның тормышына, иҗатына, иҗтимагый-фәлсәфи мирасына тәфсилле характеристика бирә. Я.Г. Абдуллин татар иҗтимагый фикере тарихының җәдитчелек кебек катлаулы күренешенә фәнни тарихи-фәлсәфи анализ ясый.

Галимнең татар мәгърифәтчелеген фәнни яктан өйрәнүе нәтиҗәләре «Татарская просветительская мысль: (Социальная природа и основные проблемы)» (1976), «Мәгърифәт яктылыгы», «Милләт язмышы: уйланулар» (2000), «Ислам һәм аның татар халкы тормышында урыны» китапларында һәм фәнни басмаларда дөнья күргән мәкаләләр сериясендә (Мәгърифәт нуры ачар..., 1987; Джадидизм среди татар. Возникновение, развитие и историческое место, 1998 һ. б.) чагылдырыла.

Я.Г. Абдуллин бүлек мөдире, Институт директоры булган елларда уздырылган семинарларда бик күп яңа, кызыклы фикерләр әйтелә. Бу фикерләр соңрак Татарстан, Россия күләмендә дә яңгырый башлый. Яхъя Габдулла улы үз фәнни мәктәбен булдыруга ирешә. Бүлек җитәкчеләре буларак Ф.М. Солтанов, Р.М. Әмирханов аның эшен уңышлы дәвам итәләр.

**Җәмил Ибраһим улы Гыйльманов** (1925–1991) – тарих фәннәре докторы, профессор, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре – 1925 елның 3 июлендә хәзерге Самара өлкәсенең Кошкин районы Теплый Стан авылында укытучылар гаиләсендә туа.

1943 елда ул Кызыл армия сафларына алына. Икенче Орджоникидзе (хәзер Владикавказ) хәрби-пехота училищесына укырга керә. Аннан соң 1945 елның мартында фронтка эләгә һәм укчылар ротасы командиры итеп билгеләнә. Аның подразделениесе хәрәкәттәге 4 нче Украина фронтында Польша, Чехословакия, Германияне фашистлардан азат итүдә катнаша.

Училищеда ук гомерлек дустына әйләнгән полковник Дмитрий Азов Җ. Гыйльмановның батырлыгы, хәрби осталыгы турында үзенең истәлекләрендә болай дип яза: «З.И. Гильманов годился своим

подчиненным в сыновья, но по должности был старшим офицером, их командиром. Неторопливо и деловито подавал команды. Голос у него уверенный. Мины летели в цель... Зямиль прекрасно ориентировался на местности, обладал исключительной требовательностью к подчинённым. Решения принимал быстро и всегда обоснованно… В самый сложный момент З. Гильманов с миномётными расчётами подбирался почти вплотную к атакующим. И сам прямой наводкой бил по вражеским силам… Недавний выпускник училища получил тогда за один из таких боев первый орден Красной Звезды».

Җәмил Ибраһим улы сугышта күрсәткән батырлыклары өчен I дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Германияне җиңгән өчен» һәм «Японияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә. Ул сугыш көндәлеге алып бара.

Чехословакиянең Вратимов шәһәрен фашистлардан азат иткәндә күрсәткән батырлыгы өчен, чех партизаннары Җ.И. Гыйльмановны 30 ел узгач эзләп табалар. Бу очрашудан соң аңа «Вратимов шәһәренең Мактаулы гражданины» исеме бирелә. Күп еллар үткәч тә, ветеранга бу чех шәһәре кешеләреннән рәхмәт хатлары килә.

Җ.И. Гыйльманов 1945 елда японнарның Квантун армиясенә каршы маньчжур операциясендә катнаша, аннан соң илнең Чукоткадагы дәүләт чикләрен сакларга калдырыла. Галим андагы хезмәтнең бик авыр шартларда булуын ассызыклый (*Шишкина Д.* Зямиль Ибрагимович Гильманов: военные страницы биографии // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2006).

Җәмил Гыйльманов, Казан университетын тәмамлаганнан соң, (1952) КПССның Яшел Үзән шәһәр комитетында лектор булып эшли. 1958–1962 елларда Казан авиация институтында укыта, бер үк вакытта Бөтенсоюз «Белем» җәмгыятенең Татар бүлеге идарәсе рәисе урынбасары була. 1962–1964 елларда «Татарстан коммунисты» журналы баш мөхәррире һәм башка журналларның редколлегия әгъзасы вазифаларын башкара.

1964–1990 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтының тарих бүлеге мөдире була. Чирек гасырдан артык ул җитәкләгән бүлектә М.К. Мөхәррәмов, Х.Х. Хәсәнов, С.Х. Алишев, Р.Г. Фәхретдинов, Ю.И. Смыков, Р.Г. Әмирханов, К. Нәҗипова кебек галимнәр эшли. Бу чорда тарих бүлеге элекке төбәкчелек тарихыннан югары профессиональ тарих язу дәрәҗәсенә ирешә. Хәрби хезмәттә, сугыш елларында ук формалашкан тугры дуслык эталоны Гыйльманов һәм Мөхәррәмов мөнәсәбәтләрендә дә сизелеп тора иде. Хезмәттәшләре Җәмил Ибраһим улын аталарча кайгыртa белүче җитәкче буларак искә алалар.

Җ.И. Гыйльманов, Татарстан тарихчыларыннан беренче булып, республиканың Икенче бөтендөнья сугышы елларындагы Җиңүгә керткән гомуми өлешен, тылда һәм фронттагы хезмәт һәм сугышчан батырлыкларны комплекслы рәвештә ачып сала. Галимнең «Татария в годы суровых испытаний 1941–1945 гг.», «Трудящиеся Татарии на

фронтах Великой Отечественной войны» исемле китаплары дөнья күрә. Ул – «Татарстан АССР тарихы (борынгы заманнардан безнең көннәргә кадәр)» хезмәте авторларының берсе. Аның «Без сугышта юлбарыстан көчлебез» дигән китабы, тагын уннан артык җыентыгы бар. Җәмил Гыйльманов шулай ук өч томлы «Герои Советского Союза – наши земляки», «История Казани» (ике томда) һәм башка коллектив хезмәтләрне бастыруда актив катнаша. Берничә китап (шул исәптән безнең республикада тупланган бер дивизиянең сугышчан юлы турында) аның авторлыгында да чыгарыла. Ул Советлар Союзы герое Дмитрий Карбышевның чыгышы белән татар булуын ачыклый. Үзе сугыш кичкән командирның бу хезмәтләре тагын да ышанычлырак булып кабул ителә.

Институтның тагын бер ветераны – **Фәтхелбәян Нурлыгаян улы Гыйззәтуллин** (Бәян Гыйззәт) (1918–1991). Ул 1918 елның 16 июлендә хәзерге Башкортстанның Кушнаренко районы Талбазы авылында крестьян гаиләсендә туа. 1934 елда Уфага барып, Башкорт дәүләт медицина институтының рабфагына укырга керә. Әмма аны тәмамлагач, матур әдәбиятка һәм сәнгатькә мәхәббәт аны Казан дәүләт педагогика институтына алып килә. 1941 елда егетне аспирантурада калдыралар.

Бөек Ватан сугышы башлана. 1941 елның декабрендә Бәян Гыйззәт Ватанны саклаучылар сафына баса. Көнбатыш, Өченче Белоруссия фронтларында барган канлы бәрелешләрдә катнаша, яралана, госпитальдә дәваланып чыккач, хәрби училищега укырга җибәрелә. Офицер званиесендә ул яңадан фронтка китә. Курск дугасы янындагы мәгълүм канкоешларны исән-имин кичеп, Кенигсбергка кадәр сугышчан юл уза. Фронттагы батырлыклары өчен Бәян Гыйззәт ике мәртәбә Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

1945 елда сугыштан кайткач, Б. Гыйззәт Татар дәүләт академия театрына әдәби бүлек мөдире булып эшкә керә. Шул ук елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантурада да укый һәм 1951 елда «Гафур Коләхмәтевнең иҗаты» дигән темага диссертация яклый. 1953 елдан башлап, ул – Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми хезмәткәре. 1968 елда Фәтхелбәян Гыйззәтуллин сәнгать бүлегенә нигез сала. 1981 елга кадәр бүлек мөдире була. Анда театр тарихы буенча гына түгел, ә бәлки музыка, декоратив сәнгать төркемнәре дә оеша. Биредә И.И. Илялова, М.Н. Нигъмәтҗанов, Д.К. Вәлиева, Д.Ә. Гыймранова, М.Г Арсланов, Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова кебек белгечләр зур фәнни казанышларга ирешә.

Бәян Гыйззәтнең әдәби-фәнни эшчәнлеге тулысынча диярлек татар драматургиясе һәм татар театр сәнгате белән бәйле. Аның драматургия һәм театрга кагылышлы тикшеренүләре «Егерменче йөз башында татар әдәбияты» (1954), «Татар совет әдәбияты тарихы» (1960), «Заман сулышын тоеп» (1967), «Татар совет театры» (1975), Мәскәүдә рус телендә чыккан «История татарской советской литературы»

(1965), «История многонациональной советской литературы» (1972) исемле китапларда урын ала. Таҗи Гыйззәт иҗатын яктырткан монографиясе 1957 елда аерым китап булып басылып чыга. Мәскәүдә Сәнгатьләр тарихы институтында әзерләнгән «История советского драматического театра» исемле алты томлы коллектив хезмәттә дә ул, авторларның берсе һәм редколлегия әгъзасы буларак, татар театрының үсеш этапларын яктырткан фәнни очерклары белән катнаша. Болардан тыш, Бәян Гыйззәтнең драматургия һәм театр сәнгате турындагы мәкалә һәм очерклары төрле җыентыкларда, әдәбият һәм театрга бәйле белешмә-энциклопедияләрдә, көндәлек матбугат битләрендә күпләп басылган. Галиәсгар Камал, Гафур Коләхмәтев, Габдулла Кариев, Кәрим Тинчурин, Мирхәйдәр Фәйзи, Хәлил Әбҗәлилов, Гадел Кутуй, Һади Такташ, Гамир Насрый һ.б. бик күпләргә багышланган иҗади портретлар, аерым әсәр яки спектакльләр турында рецензияләр, сәнгатьнең бүгенге актуаль мәсьәләләрен күтәргән тәнкыйть мәкаләләре – болар һәммәсе Бәян Гыйззәтнең, галим һәм тәнкыйтьче буларак югары урыны, иҗат активлыгы турында сөйлиләр.

Фәнни-әдәби иҗат өлкәсендәге хезмәтләре өчен Б. Гыйззәт «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнә, шулай ук аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Б. Гыйззәт – 1957 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Үз гомерендә Бәян Гыйззәт күп тикшеренүләр алып бара. Аның әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышланып, вакытлы матбугатта чыккан мәкаләләренең саны гына да 200 гә җитә. Ул җәмәгать эшендә дә актив катнаша. Язучылар берлегенең тәнкыйть секциясе җитәкчесе, Россия театр җәмгыяте әгъзасы була, шәһәр советы депутаты итеп сайлана.

Гыйззәтуллин Фәтхелбәян Нурлыгаян улы 1991 елның 25 маенда Казан шәһәрендә вафат була. Якын дусты, татар әдәбиятын укыту буенча күп хезмәтләр авторы Шамил Әхтәмов үзенең «Бәян Гыйззәт хатлары» исемле мәкаләсендә (Казан утлары, 1998, № 7) аны болай искә ала: «Минем күңелемдә Бәян һаман исән кебек. Озын буйлы, мәһабәт, төз гәүдәле Бәян, яшьләр шикелле җитез атлап, Ленин урамыннан Фәннәр Академиясенең Казан бүлегенә киләдер кебек. Бина алдындагы бакчада үткән гасырның атаклы математигы Лобачевский бюсты яныннан үтәр, йортка кергәч, хезмәттәшләре белән исәнләшер, хәл-әхвәл сорашыр, көнүзәк мәсьәләләр турында сөйләшер Фәтхелбәянның эш көне шулай башланып китә иде...».

Чираттагы ветераныбыз – **Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин** (1925–2000). 1925 елның 25 маенда ТАССРның Мамадыш кантоны (хәзер Саба районына керә) Чәбия-Чурчи авылында туа. Әтисе Гыйбадулла Кәримулла улы – агроном, әнисе Сафия Гата кызы – авыл укытучысы. Ул 1930 елда күмәкләштерү чоры корбаны була. Башлангыч белемне Әбрар туган авылында, урта белемне Байлар Сабасын-

да ала. Мәктәпне тәмамлагач, ул туган авылында хисапчы, Нырты фабрикасы шифаханәсендә, аннары Олы Арташ авылында башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Хыялы – география укытучысы булу. Әмма теләген сугыш өзә.

1943 елда 18 яшьлек Әбрар Кәримуллин Кызыл армия сафларына алына һәм, «Житомир» хәрби училищесында алты айлык курсны тәмамлагач, минометчы буларак фронтка җибәрелә. Ул сугышкан данлы 110 гвардия укчы дивизиясе Бөек Ватан сугышының хәлиткеч бәрелешләрендә катнашып, махсус исемнәргә, югары сугыш орденнарына лаек була, Курск дугасы, Днепрны кичү сугышларында катнашып, Украина, Молдавия, Румыния, Венгрия, Чехословакияне фашистлардан азат итүдә данлы юл уза. Су асты машинасы белгече, разведка офицеры һәм миномётчы Ә. Кәримуллин батырлыклары өчен I дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденына, ике тапкыр «Батырлык өчен» һ. б. медальләргә лаек була. 1944 елда, фронтта, Ә. Кәримуллин КПСС сафларына баса. Бөек җиңүдән соң, аны Ерак Көнчыгышка Япониягә каршы сугышка җибәрәләр. Монда хәлләр тагын да авыррак була. Кытай, Монголиядә үлем үзәннәрен, Хинган таулары аша үтә, өч тапкыр яралана. Ниһаять, Ә. Кәримулин 1947 елда гына туган ягына кайта ала. Әтисе дә сугыштан яраланып кайта, озак тормый, шул ялардан 1947 елда вафат була. Әбрар тулы ятим кала.

Ә. Кәримуллин Саба районының Икшермә МТСында трактор бригадасында, «Ильич истәлеге» коллектив фермасында бухгалтер булып эшли.

1948–1953 елларда Ә. Кәримуллин КДУның Тарих һәм филология факультеты татар бүлегендә белем ала. Исемле стипендияләр алып укыса да, акча ашарга да җитми. Читтән ярдәмгә өмет юк. Аңа уку барышында һәм каникуллар вакытында эшләп көн күрергә туры килә.

Университетны тәмамлаганнан соң, 1953 елдан 1964 елга кадәр Әбрар Кәримуллин Казан университетының Фәнни китапханәсендә башта өлкән китапханәче, аннары бүлек җитәкчесе, фәнни эшләр буенча китапханә директоры урынбасары булып эшли. Андагы сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләренә караган гарәп шрифтындагы язма мираска бай була. Әмма тикшеренүчеләр өчен аларның эшкәртелмәве, тасвирланмавы фәнни өйрәнүләргә киртә булып тора. Татарлар революциягә кадәр китапсыз, грамотасыз халык булган, аларга уку-язуны совет хакимияте генә биргән, дигән ялган күрсәтмә дә моңа йогынты ясамый калмый. Ә.Г. Кәримуллин җитәкчелегендә гарәп графикасындагы татар китаплары рекаталогизацияләнә, ягъни каталог карточкаларын алыштыру белән бәйле китапханә каталогы тулысынча эшкәртелә, укучыга яңа тасвирлау нигезендә тәкъдим ителә. Нәтиҗәдә фәнни өйрәнү көчәя һәм бай рухи мирас кулланыла башлый. Автор һәм галимнәргә ислам һәм татар дөньясын өйрәнүдә зур мөмкинлекләр ачыла. Әбрар Кәримулин татар әдәбияты, әдәбият тарихы һәм белеме, халык

авыз иҗаты, Татарстан һәм татар халкы тарихыннан аерым-аерым күрсәткечләр төзеп, бастыра. Галимнең әдәби теория, лингвистика һәм библиография турындагы беренче мәкаләләре 1950 еллар башында ук вакытлы матбугатта чыга башлый. Шулай итеп, Ә.Г. Кәримуллин тарафыннан татар фәнни библиографиясенә нигез салына һәм үстерелә.

Бу елларда Ә.Г. Кәримуллин инициативасы белән һәм аның катнашында татарлар яшәгән республика, өлкәләргә даими рәвештә археографик эзләнүләр оештырыла башлый. Университет китапханәсе тагын да меңләгән татар, Шәрык кулъязмалары белән байый. Моңа кадәр билгеле булмаган әсәрләр, исемнәр ачыла.

Ә.Г. Кәримуллин инициативасы белән китапханә Европа, Азия, Америка, Австралия кебек илләрнең 200 дән артык фәнни учреждение, югары уку йорты белән элемтә урнаштырыла, алардан китапханәгә, КДУ басмаларына китап алмашу тәртибендә, йөзләрчә һәм меңнәрчә китап, журнал, газета килә.

Әмма бу Татарстан, Россия җәмәгатьчелеге өчен, нигездә, көтелмәгән ачышлар бертөсле генә кабул ителми. Аеруча аның «Әдәби җыентык һәм альманахлар библиографиясе: 1917–1960» исемле хезмәтеннән соң, Сталинны, репрессияләнгән язучыларны, революциягә кадәр тудырылган язма мирасны күтәрүдә, панисламизмда һ. б. ларда гаепләп, Әбрар Кәримуллинга партия оешмалары тарафыннан каты шелтә белдерелә, «сәяси яктан җитлекмәгән хезмәткәр» буларак 1963 елда ул эшеннән алына.

Әбрар Гыйбадулла улы 1964–1992 елларда Тел, әдәбият һәм тарих институтының сәнгать һәм халык авыз иҗаты, татар иҗтимагый фикере тарихы бүлекләрендә эшли. Институтта ул татар театры тарихы буенча библиографик күрсәткеч төзү белән шөгыльләнә. 1968 елда «Татар сәхнәсе: 1917–1967 еллар» дигән монографик хезмәтен язып тәмамлый. Хезмәттә рус һәм татар телләрендәге 8 000 нән артык әдәбият исеме тәкъдим ителгән. Китапта Татарстанда һәм аннан читтә эшләгән барлык татар театрлары турында мәгълүмат тупланган. Бу үзенә күрә татар театры энциклопедиясе булды, Ватан библиографиясе практикасында аның аналоглары юк иде.

Иҗтимагый фикер тарихы бүлегендә дә Әбрар абыйга карата ихтирамыбыз бик зур иде. Аз сүзле булса да, аның күпсанлы чыганаклар белән нигезләнгән төпле фикерләрен без көтеп ала идек. Ул 1976 елда университетта минем кандидатлык диссертациясе хакындагы фикер алышуда да катнашып, кыйммәтле фикерләрен җиткерде.

Әбрар Кәримуллин 1968 елда, КДУда «Татар басмасының барлыкка килүе һәм татар филологиясендә яңа чыганаклар: XVII – XIX гасырның беренче яртысы» темасы буенча кандидатлык, ә 1978 елда «XX гасыр башының татар китабы» фәнни хезмәте нигезендә Ленин исемендәге СССР дәүләт китапханәсендә докторлык

диссертациясе яклый. Бу диссертацияләр аспирантура үтмичә, фәнни җитәкчесез языла.

1987 елда галим Татарстанның атказанган фән эшлеклесе булып танылa.

Ә. Кәримуллинның «У истоков татарской книги: от начала возникновения до 60-х годов XIX века» (1992) трилогиясе Татарстанда гына түгел, илебезнең барлык почмакларында һәм чит илләрдә дә зур танылу яулый. Күренекле чит ил белгечләре аңа зур бәя бирде.

Ә. Кәримуллин трилогиясе беренче тапкыр татар басма сүзенең 1917 елга кадәрге тарихын комплекслы рәвештә өйрәнә, татар халкының рухи мирасын китап басу яссылыгы аша яктырта. Кәримуллин татарларның төрки телле халыклар арасында беренчеләрдән булып китап баса башлауларын раслый. Инкыйлабка кадәрге татар китабы, исем саны буенча рус һәм латыш китапларыннан гына калышып, ә тиражы буенча рус китабыннан соң икенче урында торып, татарларның югары грамоталы халык булуын раслый. Китап татар һәм башка мөселман халыкларын агартуга өлеш кертә, укучыларны татар басмалары аша дөнья әдәбияты әсәрләре, шул исәптән рус классиклары белән дә таныштыра. Галим татар китабы тарихына һәм биобиблиографиягә караган күпсанлы хезмәтләре өчен 1991 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 1992 елда Татарстан Фәннәр академиясе оешуга, ул гуманитар фәннәр өлкәсендә, беренчеләрдән булып, хакыйкый әгъза (академик) булып сайлана.

Әбрар Гыйбадулла улы үз халкының килеп чыгышы һәм аның исеме тарихы белән бик кызыксына. «Татары: этнос и этноним» дигән хезмәт яза. Бу хезмәт өч тапкыр: татар һәм рус телләрендә 50000 артык тираж белән басылып чыга, япон, төрек, гарәп телләренә тәрҗемә ителә һәм укучыларда зур кызыксыну уята. Ул елларда бу китап һәр зыялы кешенең кулында булды.

Аның «Прототюрки и индейцы Америки. По следам одной гипотезы» (1995) китабы да сенсация буларак кабул ителә. Чит илләрдә дә, аеруча АКШта, яңгыраш таба.

Ә. Кәримуллин Татарстан һәм Россиянең күпсанлы гыйльми оешмаларында, гыйльми советларында, газета, журнал редакцияләрендә һ. б. әгъза булып тора. Ул 1978 елда атаклы тарихчы Л.Н. Гумилёв тәкъдиме белән Россия географик җәмгыятенә кертелә. Чит илләрдә дә аның абруе зур булды.

Ә.Г. Кәримуллинга АКШтагы Гарвард университетының фәлсәфә докторы исеме бирелә. Күп еллар буена ул Америка (Төньяк Каролина) биографик институты советы, Халыкара биографик берләшмәнең гомерлек, энциклопедик белешмәләрне бастырып чыгару буенча Халыкара биографик үзәкнең хакыйкый әгъзасы була һ. б.

Бу Әбрар Гыйбадулла улының эшчәнлегенә, хезмәтләренә югары бәя бирү генә түгел, ә бәлки татар дөньясының югары язма мәдәнияткә, цивилизациягә ия булуын да дөнья күләмендә тану иде.

Шушы көннәрдә Г. Камал театрының яңа бинасында Ә.Г. Кәримуллинның 100 еллык юбилеена багышланган кичә үткәрелде. Анда бөек галимнең тормыш һәм фәнни эшчәнлегенә багышланган «Беренче басма татар китабы эзләреннән» исемле фильм тамашачыларга тәкъдим ителде (режиссеры Нәсүр Йөрешбаев). Фикер алышуда катнашкан күренекле галимнәр, язучылар үзләренең чыгышларында Ә. Кәримуллинның югары дәрәҗәдәге универсаль галим булуы белән беррәттән, аның ялкынлы мәкалә, чыгышлары белән татар халкының мәнфәгатьләрен яклап көрәшүен дә билгеләп үттеләр.

Институт ветераннарын барлаганда, **Һарун Вәли улы Йосыповны** (1914–1968) да искә алу кирәк. Ул – күренекле археолог, эпиграфист, тарихчы, рухи мәдәният белгече.

Һ.В. Йосыпов 1914 елның 22 июнендә Казанда татар приказчигы гаиләсендә туа. Яшьтән үк әтисеннән гарәп телен, язуын өйрәнә. Әнисе Мәүгизә йорт эшләре белән шөгыльләнә, 5 баласын тәрбияли. Казанның 19 нчы мәктәбен тәмамлагач, аның хезмәт юлы башлана: хисапчы, электромонтер булып эшли һәм бер үк вакытта 1936–1941 елларда Казан университетының география факультетында укый, географ-геоморфолог белгечлеге ала.

1941–1942 елларда, татар геология-разведка трестында прораб булып берничә ай эшләгәннән соң, Һ.В. Йосыпов хәрәкәттәге армиягә алына. 1942 елның октябреннән ул Бөек Ватан сугышына китә, иң авыр сугыш хәрәкәтләрендә – Воронеж оборонасында, Сталинград сугышында, Курск дугасында, Көнбатыш фронтта һ. б. сержант элемтәче, разведчик булып катнаша. Курск дугасында башы яралана, контузия ала. Ул «Сталинград оборонасы өчен» һәм «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә. Авыр яралануына карамастан, Һ.В. Йосыпов 1945 елның октябренә кадәр армиядә кала.

1946–1949 елларда ул – Казан университетының география факультетында өлкән лаборант, аннары атаклы Этнография музее фондында саклаучы, мөдир. Бу чорда Һ. Йосыпов экспедицияләргә чыга, музей тарихы, күренекле астроном, географ, этнограф И.М. Симоновның этнографик күзәтүләре, аның этнографик музейга нигез салган коллекциясе турында беренче фәнни мәкаләләре басыла. Шул ук вакытта Һарун Йосыпов эшчәнлегендә төп фәнни юнәлешне тәшкил иткән болгар-татар эпиграфикасын өйрәнү эше дә формалаша башлый. Гарәп палеографиясен генә түгел, ә татар халкының телен, көнкүрешен һәм мәдәниятен дә яхшы белүе аңа кыска вакыт эчендә борынгы болгар-татар эпитафияләрен уку һөнәрен төрле яклап үзләштерергә мөмкинлек бирә. 1951–1956 елларда галимнең «Эпиграфика Востока» басмаларында XIV–XVI йөзләрдәге болгар-татар эпиграфик истәлекләрен укуга, классификацияләүгә һәм фәнни аңлатуга багышланган мәкаләләре дөнья күрә.

Һ. Йосыпов 1948–1952 елларда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантура-

да укый. Н.Ф. Калинин җитәкчелегендә Казан Кремлен археологик тикшерүдә, эпиграфик экспедицияләрдә катнаша. 1953 елда М. Ломоносов исемендәге Мәскәү университетында «XIII–XVII гасырлар болгар-татар эпиграфик ядкәрләре (Казан татарларының килеп чыгышы турындагы мәсьәләгә карата)» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Һ.В. Йосыпов 1952–1958 елларда СССР Фәннәр академиясенең Башкорт филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтында археологик төркем төзеп, Башкортстанда археологик тикшеренүләрне җитәкли. Шулай итеп, Һ.В. Йосыповны Башкортстан археологиясенә нигез салучыларның берсе дип санарга мөмкин. Ул биш кыр сезоны дәвамында Агыйдел бассейнында Воскресенск, Имәндәш, Касьян һәм Табын шәһәрлекләре, Кормантау авыллыгы кебек элгәреге тимер гасырына нисбәтле үзенчәлекле археологик истәлекләрне ача һәм тикшерә. Аларны өйрәнү нәтиҗәләре «Древнейшие поселения Гафурийского района БАССР» мәкаләсендә урын алган. Һарун Йосыпов хәтта махсус археологик һәм эпиграфик экспедицияләрдә дә этнографик, шулай ук топонимика, диалектология, ономастика буенча күзәтүләр мөмкинлеген беркайчан да кулдан ычкындырмый. Параллель рәвештә ул үзенең этнография өлкәсендәге эшчәнлеген дә дәвам итә, күренекле археолог һәм этнограф С.И. Руденко белән бергә Башкортстан буенча этнографик экспедицияләрдә катнаша, анда башкорт һәм татарларның рухи мәдәнияте буенча бай материал туплый. Ул – С.И. Руденконың билгеле «Башкиры» исемле хезмәтенең рецензенты да. 50 нче еллар ахырында ук «Очерки по истории БАССР (периода феодализма)» томына «Башкортларның этногенезы турында», «Башкортстанның көнбатышында төрки халыклар турында» һ. б. гомуми характердагы мәкаләләр бастыра. Хезмәтенә башкортларның килеп чыгышы хакында бүлекчә кертә. «Көнбатыш Башкортстандагы эпиграфик ядкәрләр» дә аның төп темасы була. А. Збруева, Н. Мәҗитов һ.б. белән бергә башка тикшеренүләр алып бара. Соңрак Һ. Йосыпов Көнбатыш Башкорстандагы Тора хан, Кече мавзолей кебек археологик истәлекләрне беренчеләрдән булып тикшерә.

1960 елда, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре буларак, Һ.В. Йосыпов Мәскәүнең «Наука» нәшриятында «Введение в булгаро-татарскую эпиграфику» монографиясен бастыра. Ул Идел һәм Урал буендагы 200 дән артык эпиграфик һәйкәлнең беренче фәнни җыентыгын гына түгел, ә аларның беренче детальле классификациясен дә төзи. Шул рәвешле, хезмәткә төбәкнең төрки халыклары тарихы өчен дә, тел белеме өчен дә беренчел әһәмияткә ия булган гаять зур материал кертелә. Җ.Г. Мөхәммәтшин әйткәнчә, «Бу китап бүген дә тарихчы-эпиграфистларның өстәл китабы булып кала бирә». Алга таба да Һарун Вәли улы болгар-татар эпиграфик истәлекләрен эзләүдән һәм өйрәнүдән туктамый. Идел һәм Урал буеның барлык өлкәләренә дистәдән артык эпиграфик экспедицияләргә чыгып, ул XIII–XVI йөзләргә караган 600 гә якын эпитафия таба. Кызганычка каршы, галим тарихи-

лингвистик чыганакларның бу уникаль төре җыентыгын төзеп бетерә алмый. 1968 елның 20 июнендә Һарун Вәли улы Йосыпов кинәт вафат була.

Һарун Йосыпов – «Татарстан археологиясе картасы»н төзүчеләрнең дә берсе. Бу хезмәте өчен аңа вафатыннан соң, 1994 елда, башка авторлар белән берлектә, Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе бирелә.

Һ. Йосыповның кызы Софья үзенең шигъри истәлекләрендә әтисенең эпиграфик хезмәтен болай тасвирлый:

Пятнадцать лет, как кончилась война,
Страна считала важным – письмена!
Над вязью арабской склонилась спина,
И мокрой от пота рубаха была…

Эпиграфика белән шөгыльләнү Һ.В. Йосыповның этнографик тикшеренүләре белән бергә үрелеп бара. Аның татар халкының рухи мәдәнияте өлкәсендәге тикшеренүләре аеруча мөһим. «Наука» нәшриятында 1967 елда басылган «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» күмәк монографиясендәге кайбер мәкаләләр, шулай ук ышануларга багышланган бүлекләр беренче мәртәбә татарларның борынгы дини ышануларын күз алдына китерергә мөмкинлек бирә, бу исә Идел буе татарларының рухи мәдәнияте үзенчәлекләрен ачыклау өчен генә түгел, бәлки аларның этногенезы турында фикер йөртү өчен дә яңа материал була. Һ.В. Йосыповның шул ук пландагы төрки топонимика һәм ономастика буенча хезмәтләре вафаты алдыннан языла.

Һ.В. Йосыповны белгән кешеләр аны зур галим генә түгел, армый-талмый эшләүче, үзенә һәм башкаларга таләпчән яхшы иптәш буларак та бәяли. Һ.В. Йосыпов белән эшләгән һәркем аны тыйнак һәм игелекле кеше иде дип искә ала.

Мөгаен, минем фәнгә килүем дә Һарун Вәли улы Йосыпов исеме белән дә бәйледер. Татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда, безнең укытучыбыз, тарих һәм филология факультеты деканы Д.Г. Тумашева, үзе җитәкчелегендә язылган курс эшләрендә рухи мәдәнияткә тартылганымны күреп, мине институтның археология бүлеге җитәкчесе, профессор А.Х. Халиков белән таныштырырга булды. А.Х. Халиков миңа күренекле эпиграфист, археолог, татар тарихи этнографиясе, рухи мәдәнияте өлкәсендә тирән эз калдырган, мин укырга кергән 1968 елны бик иртә дөнья куйган Һарун Вәли улы Йосыпов турында сөйләде. «Бу талантлы, бик тырыш галимне алыштыру бик авыр. Әмма безгә, археологларга да рухи мәдәният тарихы буенча белгеч кирәк», – диде, мине – филологны – археологик экспедицияләрдә катнашырга чакырды. Соңыннан гына аңладым: ике профессор бу хакта Һ.В. Йосыповны югалтканнан соң ук сөйләшеп куйганнар, минем тарихка, археологиягә тартылган курс эшеннән генә башланмаган икән.

Язмышка шулай язылгандыр инде: миңа институтның фәнни архивында Һ.В. Йосыповның шәхси архивын эшкәртергә, аның тасвирламасын төзергә дә насыйп булды. Бу эшне миңа кадәр эшләгән Һава Абдулла кызы Сайманова башлап җибәргән булган. Фонд бик бай һәм бик чуар, эшкәртү өчен бик катлаулы булып чыкты. Ул 4 тасвирламадан тора: 1) «Фәнни һәм башка хезмәтләре, аларга материаллар» – 630 сакл. бер.; 2) «Хезмәт, биографик, җәмәгать эшчәнлегенә караган материаллар» – 1100 эш; 3) «Башка кешеләр белән хат алышу» 996 – хат; 4) 105 эш башка кешеләргә карый. Һ.В. Йосыповның шәхси архив материаллары да аның киң кырлы галим булуын, киеренке эшчәнлеген, СССР һәм чит ил галимнәре, зыялылары, иҗади шәхесләре белән ныклы элемтәдә торуын күрсәтә.

*(Дәвамы бар)*

**Әдәбият**

1. *Абдуллин Я.А., Шайдуллина Л.И.* Востоковедение в Казани // Народы Азии и Африки. 1985. № 5. С. 119–123.

2. *Гарипова З., Кабирова А.* Штрихи к портрету ученого // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2015. № 3/4, С. 202–209.

3. История. Профессия. Судьба. Памяти Мидхата Каримовича Мухарямова. Казань: Идел-Пресс, 2012.

4. *Солтанов Ф.М.* Галим һәм җәмәгать эшлеклесе: Яхъя Абдуллинның тууына 100 ел тулу уңаеннан хәтер яңарту // Из истории культуры городов Среднего Поволжья. 202. № 10. Т. 1. С. 172–178.

5. Чирек гасыр фикери эзләнүләр юлында. Казан: Школа, 2000. 124 б.

***Дәүләтшин Гамирҗан Миргаҗан улы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе*

***Давлетшин Гамирзян Миргазянович,***
*доктор филологических наук,*
*заслуженный деятель науки Республики Татарстан*
*g.davletshah@mail.ru*

УДК 398.22

***И.К. Фазлетдинов***

# БАШКОРТСТАН ТАТАРЛАРЫНЫҢ БӘЕТЛӘРЕНДӘ БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ВАКЫЙГАЛАРЫ ЧАГЫЛЫШЫ

Статья посвящена исследованию отражения событий Великой Отечественной войны в лиро-эпическом творчестве татарского населения Республики Башкортостан. Привлечен обширный, доселе непубликовавшийся материал из фольклорного фонда кафедры татарской филологии и культуры Уфимского университета науки и технологий. По особенностям художественного олицетворения описываемых событий и характеру лирического героя автор подразделяет данные произведения на две группы: фронтовые и тыловые баиты. Проведя тщательный анализ обеих групп, он отмечает то, что в фронтовых баитах преобладает эпическая и лиро-эпическая составляющая; а в тыловых баитах на первый план выходят лирические переживания сказителей. Отдельно анализируется преемственность в данных произведениях традиций баитов об Отечественной войне 1812 года и мотивов о лашманстве – заготовщиках корабельного леса первой половины XVIII века. По итогам проведенного исследования, автор приходит к выводу о том, что анализируемые произведения являются отражением реальных исторических фактов через призму народного восприятия, сочетающим в себе как панорамность изображения народного подвига, так и всю глубину его трагедии из-за безвозвратной потери сыновей и дочерей.

**Ключевые слова:** баит, Великая Отечественная война, татары Башкортостана, мотив, традиция, поэтика, жанр, преемственность, лиро-эпика.

The article is devoted to the study of the reflection of the events of the Great Patriotic War in the lyrical and epic works of the Tatar population of the Republic of Bashkortostan. Extensive, hitherto unpublished material from the folklore fund of the Department of Tatar Philology and Culture of the Ufa University of Science and Technology has been used. The author divides these works into two groups according to the peculiarities of the artistic personification of the events described and the character of the lyrical hero: frontline and rear baits. After conducting a thorough analysis of both groups the author notes that the epic and lyric-epic components prevail in the front baits; and in the rear baits the lyrical experiences of the storytellers come to the fore. The continuity in these works of the traditions of the Baites about the Patriotic War of 1812 and the motifs about the Lashmanism, the ship's timber harvesters of the first half of the XVIII century, is analyzed separately. Based on the results of the research, the author comes to the conclusion that the analyzed works are a reflection of real historical facts through the prism of popular perception, combining both the panoramic image of a national feat and the depth of its tragedy due to the irretrievable loss of sons and daughters.

**Keywords:** bait, the Great Patriotic War, the Tatars of Bashkortostan, motive, tradition, poetics, genre, continuity, lyric epic.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнүче «Татар халык иҗаты» 25 томлыгының ике китаптан торган «Бәетләр» тупланмасын эшләгәндә, Башкортстан татарлары фольклорына аерым игътибар бирелде. Бу уңайдан шуны әйтергә кирәк: әгәр 1983 елда чыккан «Бәетләр» академик томында Бөек Ватан сугышы турында Башкортстан җирлегендә язып алынган бер генә бәет урын алса («Бәбекәем, ак йөзкәем», Чакмагыш районы Аблай авылы) [6: 245], без әзерләгән ике томда аларның саны 10 га җитте. Әлеге үрнәкләрнең дүртесе – «Сугышта үлгән солдат бәете» [2: 241–242], «Солдат бәете» [2: 235], «Зөбәрҗәт бәете» [2: 253–254], «Ачлык чире бәете» [4: 210–211] – безнең тарафтан әзерләнеп, 2021 елда Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ тарафыннан бастырып чыгарылган «Башкортстан татарлары фольклоры» сериясенең 3 нче китабында дөнья күрде. Калган бишесе – «Сугыш бәете», «Кайгылы хатын бәете», «Шәмсулла бәете», «Мөхәррәм бәете» «Сабырбикә бәете» – әлегә кадәр матбугатта нәшер ителмәгән. Алар Уфа Фән һәм технологияләр университеты (элекке Башкорт дәүләт университеты) татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасының фольклор фондында саклана.

Тарихтан күренгәнчә, XVIII–XX гасырлар Русия тарихында моңа кадәр күрелмәгән дәүләтара һәм илкүләм сугышларның күплеге белән аерылып тора. Билгеле, фаҗигалылыкка корылган жанр буларак бәет мондый канкоешлы вакыйгаларны халык күңеле, аның күз яше аша ачуны төп максаты итеп куя. Мондый бәетләр «гомум бәет фондының яртысыннан артыгын тәшкил итә» [5: 18] һәм берничә циклга бүленә. Мәсәлән: рус – француз, рус – төрек, рус – япон, Беренче бөтендөнья, гражданнар сугышлары турында бәетләр. Фәндә бу төр әсәрләр «хәрби-тарихи бәетләр» термины астында берләштерелә. Без тикшерә торган Бөек Ватан сугышы турындагы бәетләр дә нәкъ шушы төркемгә карый.

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышына багышланган бәетләрне без ике төркемгә бүләбез: «Фронт бәетләре» һәм «Тыл бәетләре»нә. Әлеге классификация әсәрдә барган вакыйгаларның географиясен һәм фольклор героеның хәрби «биографиясе»н генә чагылдырып калмый, биредә чынбарлыкны сәнгатьчә чагылдыруның үзгә принциплары да эш итә. Фронт бәетләренә, кагыйдә буларак, эпик һәм лиро-эпик сәнгать алымнары хас, ә тыл бәетләрендә лирик алымнар өстенлек итә.

Күренекле фольклор галиме Фатих Урманче шулай ук Бөек Ватан сугышына багышланган бәетләрне ике зур төркемгә бүлеп карый. «Беренче төркемгә ил тормышы, сугыш вакыйгалары белән бәйләнгән иҗтимагый эчтәлекле бәетләр керә («Дошманны җиңгәч кайтырбыз», «Германия сугыш ачты көтмәгәндә»), – ди ул. – Аларда сүз, нигездә, илдәге фаҗигалы вакыйгалар, солдатларның фронттагы батырлыклары, тылдагы халыкның җиңү өчен җан аямый эшләве турында бара. Бәетләрнең бу төркеме жанрның уңай традицияләренә таяна һәм

шуларны уңышлы дәвам итә» [7: 369]. Без тәкъдим иткән классификациягә таянганда, бу төр әсәрләр «фронт бәетләре» төркеменә карый булып чыга, чөнки аларда хикәяләү сугышта катнашучының үз исеменнән алып барыла; алар яугирләрнең үзләре, я сугышчан дуслары тарафыннан иҗат ителеп, әсәр герое һәлак булган очракта хат белән җибәрелә, яисә исән-имин автор белән бергә туган якка әйләнеп кайта. Поэтик сурәтләү алымнары да биредә үзгә – ирләрчә: биредә баталь сценалар, яу үткән урыннарның конкрет географик атамалары, корал исемнәре өстенлек итә, ә хис-тойгылар саранрак итеп бирелә.

Башкортстан татарлары репертуарында әлеге төркемгә караган өч бәет табылды. Боларның беренчесен Шаран районы Яремкә авылында Совет армиясе офицеры Миргасыйм Шакир улы Әхмәтовның (1915 елгы) Бөек Ватан сугышы елларында Габделислам әбигә (фамилиясе күрсәтелмәгән) фронттан җибәрелгән хаттан БДУ студентлары күчереп алган. Ул «Сугышта үлгән солдат бәете» [2: 241–242] дип атала һәм хикәяләү шушы солдатның күңеленнән әнисенә мөрәҗәгате – монолог төсен ала:

И әнкәем, яшь чагымда
Рәнҗеттем бит мин сине;
Герман пулялары өчен
Үстергәнсең син мине.

Миннән калган киемнәрне,
Әнкәй, үзең кисәнә.
Гомерең булса, и әнкәем,
Хәер-дога кылсана.

И әнкәем, өй алдының
Баскычлары – киң такта.
И әнкәем, күп җылама,
«Сабыр бул», – дигән китапта.

И әнкәем, саклый күрче,
Бакчадагы алмаңны.
И әнкәем, күралмадың,
Җан биргәндә, балаңны.

Икенче бәет «Сугыш бәете» дип атала. Аны 1968 елда Башкортстанның Бәләбәй районы Исмәгыйль авылында Исмәгыйль Кәлимуллиннан (1903 елгы) Риф Мөхәммәтҗанов язып алган. Моны авылдан сентябрь аенда сугышка алынган солдатның тормыш хроникасы дип тә атарга мөмкин. Биредә аның сентябрьгә кадәр фронтка алынмавы, аннары өч кызыннан аерылып, Алкино лагеренда биш ай буена ачлы-туклы ком-таш кимереп ятуы, Финляндия чигендә хезмәт итеп, аягы яралану, бер аяксыз калуы турында бәян ителә. Шулай да бәет җиңүгә ышаныч белән тулы.

Каһәр суксын, Гитлер, сине,
Бик күп гарип ясадың;

Эшче халык күтәрелсә,
Таган ясап асарбыз.
Гитлер план корган икән
Москваны алырга;
Кызыл армия мәҗбүр иткән
Койрыгын сыртка салырга.

Өченче үрнәк – «Солдат бәете» 1963 елда Башкортстанның Миякә районы Миякәтамак авылында Нигъмәтулла Хәкимовтан (1875 елгы) БДУ студентлары тарафыннан язып алынган. Алдарак атап үтелгән үрнәкләрдән аермалы, ул 1945 елның август-сентябрендә япон империалистлары гаскәрен тар-мар итүгә багышланган. Һәм монда бәетләргә хас фаҗигалылык ул кадәр көчле түгел, чөнки төп җиңү инде яуланган, монысы – канкоешлы яуларның шаукымы гына. Бу бәет поэтикасы ягыннан оптимистик рухта булып, 1812 елгы Ватан сугышы турындагы бәетләргә якын тора. Белүебезчә, «Рус-француз сугышы бәет»ләре, жанрның башка үрнәкләреннән аермалы буларак, башыннан ахырга кадәр оптимистик рухта яңгырый. Фатих Урманче фикеренчә, «бу әлеге сугышта Русия солдатларының, Мәскәүне бер тапкыр Наполеонга биреп булса да, зур уңышларга ирешүе белән аңлатыладыр» [8: 219]. «Солдат бәете»ндә традиция буларак «Рус-француз сугышы бәет»ләренә хас булган поэтик алымнарның дәвам итүен, ягъни традицияләр күчемлелеген ачык күрергә мөмкин:

Сикереп торып киенгәч,
Урынга ут төрттек без;
Японнарны кайнап торган
Казанга утырттык без.

Җиттек япон башына,
Җиттек Гитлер башына.
Империалистлар сугыш башласа,
Үз башына шашына.

«Бәет жанрының әдәби-эстетик үсеше бигрәк тә икенче төркем бәетләр белән бәйләнгән, – дип яза Фатих Урманче. – Бөек Ватан сугышы елларында лирик бәетләр барлыкка килә: <…> әсәрләрдә үзәктә аерым вакыйгалар түгел, ә бәлки совет кешеләренең, батыр солдатның, газиз балаларын югалткан аналарның кайгы-хәсрәте сурәтләнә. Бу төр бәетләр зур тарихи вакыйгаларның аерым кеше язмышында чагылышын гәүдәләндерәләр. Аларда аерым кешенең хис-кичерешләренә зур урын бирелә. Бу төр бәетләр гүяки халык җырлары белән язма поэзиясе очрашкан урында барлыкка киләләр. Моны билгеле бер дәрәҗәдә жанрның яңа баскычка күтәрелүе дип бәяләргә мөмкин. Чөнки Бөек Ватан сугышына кадәр иҗат ителгән бәетләр арасында саф лирик әсәрләрне табу читен» [7: 369]. Мондый әсәрләр безнең классификациядәге «тыл бәетләре» төркемчәсенә туры килә.

Кайбер мисалларга тукталып үтик. 1971 елда Башкортстанның Шаран районы Алпай авылында Мөгаллимә Мөхәммәтовадан БДУ

студентлары язып алган «Кайгылы хатын бәете»ндә сугыш чоры өчен аеручa характерлы һәм язма поэзиядә дә зур урын алган озату мотивы бөтенләй чагылыш тапмый. Бәет тәүге строфаларыннан ук ирнең үлем хәбәре белән башлана:

Кызыл армияләр саф-саф булып,
Совет илкәйләрен саклыйлар.
Кулларына мылтык, кылыч тотып,
Дошманнардан сезне яклыйлар.

Син дә шушылай кызыл армис булып
Сугыш сафларына киттеңме?
Дошманнарга каршы торам диеп,
Җаннарыңны корбан иттеңме?

Шуңа карамастан, хатыны аны көтә, күрешү турында хыяллана. Әмма сугыш беткәч, өмете өзелә. Сугыш кырында вафат булган иренә тирән ихтирам, аның истәлегенә тугрылыклы булу – геройның бердәнбер юанычы.

Һич әйтмәмен сине үлгән диеп,
Үлгән дигән хәбәр килсә дә.
Син юл алган тарафлардан монда
Салкын җилләр генә иссә дә.
.......................................................
Һич ышанмыйм сине үлгән диеп,
Үз күзләрем белән күрмәгәч.
Балаларың өзелеп шашалар,
Синнән бер дә хәбәр булмагач.

Лирик бәетләрдә геройның катлаулы кичерешләре, кайнар хисләре искиткеч тыйнак, гади итеп ачыла. Гасырлар дәвамында шигъри тәҗрибә туплап килгән халык кешенең йөрәк ярасына каты кагылырга ярамаганлыгын яхшы аңлый. Сугыш корбаннарына үзенең мөнәсәбәтен белдерү өчен отышлы шигъри алымнар сайлый. Бәетләрдә җылы лирик монолог зур роль уйный. 1998 елда Башкортстанның Туймазы районы Тукай авылында Миңлегаян Исхаковадан Айгөл Хаҗиева язып алган «Мөхәррәм бәете»ндә каты яраланган герой сугыш кырында ялгыз кала. Киеренке драматик күренеш укучының күңелен тетрәтә. Соңгы минутларында геройның йөрәген өзгәләгән уйлары әнисе турында. Ул ерактагы әнкәсен юатырга, аның хәсрәтен җиңеләйтергә тырыша, аңа җылы, ягымлы сүзләр белән эндәшә. Бу шигъри алым психологик яктан тулысынча аклана: мондый минутта иң якын, иң кадерле кешеңә башкача эндәшү мөмкин дә түгел:

Беләм, әнкәй, авыр сиңа,
Күрешүләр өмет иткәнсең;
Минем хәлләремне белер өчен,
Хатларымны өзелеп көткәнсең.

Герой туган иле, туган халкы өчен үлүен яхшы аңлый, ләкин аның яшисе килә. Бу изге теләк үтә гади сүзләр белән әйтелә: «Өйдә чакта гармунымны туйганчы уйнамадым...» Ләкин үлем рәхимсез. Моны аңлаган геройның хисләре куера, катлаулана: «Соңгы минут, соңгы секунд...» Шул мизгелдәге авыр кичерешләрне ил азатлыгы өчен үлүнең бөек мәгънәсен аңлау алыштыра:

Чәчәк гомерем өзелде,
Фашист җитте башыма;
«Хак эш өчен үлде», – диеп,
Языгыз кабер ташыма.

Бу сүзләрдә әлеге бәет героеның гына хис-кичерешләре гәүдәләнгән дип булмый. Әсәрнең соңгы юллары ул елларда бөтен совет халкын биләгән изге тойгылар өермәсен чагылдыра. «Мөхәррәм бәете»ндә зур вакыйгалар юк, герой тормышыннан тик бер генә эпизод – яшәү белән үлем арасындагы трагик мизгел алынган һәм бөтен тирәнлеге һәм катлаулылыгы белән ачылган. Бәетнең эмоциональ яңгырашы гаять көчле.

Шуны да әйтергә кирәк: безнең тарафтан табылып, томнарга кертелгән Бөек Ватан сугыш турындагы аерым бәетләр үтә «кызыл» рәсми идеологиягә туры килми. Иҗат ителгән вакытларында аларны бастырып чыгару да мөмкин булмас иде. Мәсәлән, 1998 елда Башкортстанның Туймазы районы Тукай авылында Мөнәвәрә Гыйльмановадан Айгөл Хаҗиева язып алган «Зөбәрҗәт бәете»нең соңында аның язылу тарихы китерелә: «Зөбәрҗәт исемле кыз, 1941 елда сугыш башлангач, Сучан шахтасында эшкә җибәрелгән һәм шунда үлеп калган. Аның белән бергә эштә булган картәнием Гильманова Мөнәвәрә, ахирәтенә багышлап, бәет язган» [2: 254].

Бәет текстында үлемнең төп сәбәбе итеп сугыш чорындагы аяусыз хезмәт, крестьян хезмәтеннән көчләп аерылган гади авыл кешеләренең концлагерьлардагыча михнәтләр чигүе күрсәтелә. Биредә шулай ук XVIII гасырның беренче яртысында киң таралган «Лашман» бәетләре, ягъни Россия флоты өчен көчләп агач кисүгә җәлеп ителгән, шунда ирексез хезмәттән, сагынудан һәлак булып калган кичәге крестьяннар турындагы бәетләр белән аваздашлык нык сизелә. Марсель Бакиров, «Лашман» бәетләрен анализлап, аларда «шәхес фаҗигасы да күпчелек очракта социаль характерда» булуын ассызыклый. «Чөнки бу үлем җәмгыятьтәге социаль тәртипләр һәм төптә ятучы иҗтимагый закончалыклар нәтиҗәсендә килеп туа», – ди галим [1: 281]. Бу сүзләрне лашманчылык фаҗигаларыннан 200 елдан соң булган хәлләрне гәүдәләндергән «Зөбәрҗәт бәете»нә карата да кабатларга мөмкин. 18 яшьлек кыз, туып-үскән җиреннән аерып, Ерак Көнчыгышның күмер шахталарына алып кителә:

«Җирнең чите шушыдыр», – дип,
Башта карап тордык аптырап;

Менә Сучан[1], анда диңгез,
Находкасы[2] тора арттарак.

Шунда биш ел аяусыз хезмәттә гомер кичергәч, күмер астында калып җан бирә:

Кызлар төшә шахталарга
Кулына тотып лампасын;
Сигез сәгать буйларына
Күрми дөнья яктысын.

Өстән җир астына чаклы
Ике йөз метр ара.
Проходнойда номер гына
Чыкканны көтеп кала.

Биш ел үткәч, мин җан бирдем,
Күмер астында калып;
Җир өстенә чыгардылар,
Үлек гәүдәмне табып.

Кыскасы, «традицион бәет герое үзе яшәгән тарихи чорда хәл итәргә мөмкин булмаган төрле социаль каршылыкларны үзендә берләштерә» [1: 281].

Кыска гына гомер, бәхетсез язмышлар,
Бездән генә, әнкәй, үтмәгән,
Хәсрәт өчен туган бу кызыгыз
Монда үзе теләп китмәгән, –

ди фаҗигалы язмыш иясе.

Шулай итеп, бередә охшаш тарихи дәверләр, Россия тарихындагы кискен борылышлар чоры белән нисбәтләнгән традицияләр күчемлелеген ачык тоярга мөмкин.

«Ачлык чире бәете»н [4: 210–211] исә 2002 елда Башкортстанның Илеш районы Кадер авылында Фәнүзә Гыйльвановадан БДУ студенты Альмира Хәйретдинова язып алган. Бәетнең керешендә аның язылу тарихы китерелә: «1944 елны, сугыш вакытында, халык бик ачыкты һәм, көз көне җыелмый калган арыш башагын ашап, бик күп кеше агуланды, үлде. Бик күп өйләр йозакка бикләнде». Бу үзе үк бәетләрнең рәсми, халык героизмын гына чагылдырган әсәрләр булуыннан бигрәк, чын тарихның, канлы-яшьле тарихның халык күңелендәге образлы гәүдәләндерүенә дәлил.

Алтмыш өйле бер авылда
Кырыклап кеше үлде;
Көн саен дүрт-биш мәетне
Исән кешеләр күмде.

---

[1] Сучан – Приморск краендагы шәһәр; 1932–1972 елларда – Сучан, аннан соң Партизанск дип атала.

[2] Находка – Приморск краендагы шәһәр-порт.

Иртән чирли баласы –
Тамаклардан кан килә;
Ә кичен чирли анасы –
Танаудан да кан килә.

Өйдә бер кеше чирләсә,
Өйдә беркем калмады.
Үлем канатларын җәеп,
Безне кайгы ялмады.

Безнең Базы[1] суы әче,
Үрчетеп булмый балык.
Сугышта кеше кырылды,
Авылда үлде халык.

Биредә бик уңышлы параллель – яу кырын ул чордагы авыл тормышы белән тәңгәлләштерү күзгә ташлана. Аларның икесендә дә яшәү өчен сугыш бара. Беренчесендә – дошман ачык, немец фашисты булса, икенчесендә ул – күзгә күренмәс; ачлык һәм көздән калган башак ашаудан килеп чыккан кан чире.

Шуңа колхоз бригадирларының аяусызлыгы да килеп кушыла:

Үлгәннәр кабере яныннан
Үтәбез башны иеп;
Исән чакта җир сөрделәр,
Сауган сыерны җигеп.

«Сыерыңны җик!» – дип куша
Яшенә дә картына;
Тырма тартып, без йөрибез
Әниләрнең артыннан.

Яу кырында да, тыныч тормышта да бихисап корбаннар биреп яулап алынган тынычлыкны саклау, аның бозылуына юл куймау – бәетче өчен төп бурыч булып тора. Шуңа да ул:

Сабан сөреп, тырма тартып,
Без яшәргә тырыштык;
И Ходаем, илгә-көнгә
Бирсәң иде тынычлык, –

дип ялвара.

Шуны әйтергә кирәк: ил киңлекләрендә дә, дөньяда да сугышларның әлегә кадәр тынып торганы юк. Хәрби-тарихи бәетләр, халык иҗатының актив һәм хәрәкәтчән жанр төре буларак, теге яки бу төбәктә бәхетсезлеккә очраган һәм вакытсыз якты дөньядан киткән кешеләргә аталып, бүген дә актив иҗат ителеп тора. Әлеге төр бәетләрдә без илкүләм тарихи вакыйгаларга багышланган бәетләрдәге панорамалык сыйфатының шәхси фаҗигалар турындагы бәет

[1] Базы – Башкортстанның Шаран, Чакмагыш, Илеш һәм Дүртөйле районнары буенча агып, Агыйделгә коя торган елга.

поэтикасы белән үрелеп китүен күрә алабыз. Бөек Ватан сугышы турындагы бәетләр, татар халкы өчен генә түгел, бөтен ил күләмендәге тетрәнүләрне, фаҗигаларны чагылдырган поэтик әсәрләр булып торалар һәм бүгенге көндә дә үзләренең сәнгати-эстетик кыйммәтләрен югалтмыйлар.

**Әдәбият**


1. *Бакиров М.Х.* Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. 359 б.

2. Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар / төз., кереш мәкалә һәм аңлатмалар авт. И.К. Фазлетдинов; ф. ред. К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 312 б.

3. Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төз., кереш мәкалә һәм аңлатмалар авт. И.К. Фазлетдинов; ф. ред. К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 296 б.

4. Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар / төз., кереш мәкалә һәм аңлатмалар авт. И.К. Фазлетдинов; ф. ред. К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘһСИ, 2021. 304 б.

5. Татарское народное творчество: в 15 т. Т. 9: Баиты / сост.: Ф.В. Ахметова, И.Н. Надиров, К.Б. Замалетдинова; отв. ред. И.К. Фазлутдинов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2022. 479 с.

6. Татар халык иҗаты. Бәетләр / төз. Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 352 б.

7. *Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты. Казан: Мәгариф, 2005. 383 б.

8. *Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек: 3 томда. 1 т. (А–Г). Казан: Мәгариф, 2008. 303 б.



***Фазлетдинов Илдус Камил улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, Уфа Фән һәм технологияләр университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы доценты*

***Фазлутдинов Ильдус Камилович,***
*кандидат филологических наук, доцент;*
*доцент кафедры татарской филологии и культуры Уфимского университета науки и технологий*
*fazlutdinov75@mail.ru*

УДК 792.09

***Е.Н. Шевченко***

# КОКИ МИТАНИНЫҢ «КӨЛКЕ АКАДЕМИЯСЕ» АЙДАР ҖӘББАРОВ КУЕЛЫШЫНДА

Статья посвящена спектаклю «Пепел» Татарского государственного академического театра им. Г. Камала по пьесе Коки Митани «Академия смеха» в постановке Айдара Заббарова. Остроумная пьеса японского драматурга о комическом поединке Автора и Цензора становится для режиссера поводом для серьезного разговора на тему «художник и власть». Он включает в ткань спектакля документальный материал, связанный с трагической судьбой татарской литературы. В результате постановка Айдара Заббарова оборачивается страстным реквиемом по репрессированным татарским писателям, их уничтоженным или подвергшимся жёсткой цензуре произведениям. В статье анализируются характер взаимодействия режиссёра с текстом оригинала и особенности его авторского художественного высказывания.

**Ключевые слова:** Коки Митани, пьеса «Академия смеха», Айдар Заббаров, спектакль «Пепел», Татарский государственный академический театр им. Г. Камала, сценическая интерпретация, цензура, художник и власть.

This article is devoted to the play “Ashes” by the Tatar State Academic Theater named after G. Kamal based on the play by Koki Mitani “Academy of Laughter” directed by Aidar Zabbarov. A witty play by a Japanese playwright about a comic duel between an Author and a Censor becomes a reason for the director to have a serious conversation on the topic of “the artist and authority”. It includes documentary material related to the tragic fate of Tatar literature in the fabric of the play. As a result, Aidar Zabbarov’s production turns into a passionate requiem for the repressed Tatar writers, their destroyed or heavily censored works. The article analyzes the nature of the director’s interaction with the original text and the features of his scenic interpretation.

**Keywords:** Koki Mitani, the play “Academy of Laughter”, Aidar Zabbarov, the play “Ashes”, Tatar State Academic Theater named after G. Kamal, scenic interpretation, censorship, artist and authority.

Айдар Җәббаров (1991) – яшь булуына карамастан, инде танылып өлгергән режиссёр. Ул – Фәрит Бикчәнтәев һәм Сергей Женовачның шәкерте, бүген – Татарстан театрларында һәм республикадан читтә уңышлы эшләп килүче, күренекле режиссёр.

Татар халкының үткәне һәм бүгенгесе белән бәйле әһәмиятле тема һәм проблемалар Җәббаровның спектакльләрендә еш кына сәнгати тикшеренү объекты булып тора. Мәсәлән, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелган «Хуш, авылым» (2020) һәм «Хуш, авылым. Хыял» (2021) дилогиясе татар авылының юкка чыга баруы проблемасына багышланган. Әлмәт татар драма театрында Гаяз Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде» повесте буенча куелган

спектакльдә режиссёрны милләтара никахлар мәсьәләсе кызыксындыра. «Казанга Тукай кайткан» (2024) һәм «Әлфия Авзалова. Мәңгелек юл» (2025) спектакльләрендә Камал театрында режиссёр үзе һәм тамашачы өчен татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре образларын яңадан «ачарга» омтыла.

А. Җәббаровның япон драматургы, актёр һәм сценарист Коки Митаниның «Көлке академиясе» («Академия смеха») пьесасы буенча куелган «Көл» спектакле дә – шундый ук сәнгати тикшеренү үрнәге. Биредә режиссёрның игътибар үзәгендә «рәссам һәм хакимият» темасы.

Пьесадагы вакыйгалар сугыш вакытында ниндидер уйлап чыгарылган илдә бара. «Көлке академиясе» – үзенең даими авторы (драматург-комедиографы) булган театр труппасының исеме. Ул, яңа пьеса куйганда, һәрвакыт цензураның рөхсәтен алырга тиеш. Шул ук вакытта Цензор – сәнгатьтән ерак, театрда бернәрсә дә аңламый торган һәм өстәвенә юмор хисеннән бөтенләй мәхрүм кеше. Әгәр көченнән килсә, ул авыр сугыш елларында илдә комедияләр куюны һәм, гомумән, театрларны тыяр иде. Драматург һәм Цензорның үзара мөнәсәбәтләре пьесаның эчтәлеген тәшкил итә дә.

Шулай итеп, Автор яңа комедия куярга рөхсәт алу өчен, Цензор янына килә. Цензор, пьесага «ышанычлы» төс бирергә тырышып, Авторга төзәтмә арты төзәтмә кертә. Автор шаярта, ялагайлана, текстка берсеннән-берсе мәгънәсезрәк үзгәрешләр кертеп, буйсынган булып кылана. «Как дотла гореть, спроси у пепла» рецензиясе авторы Ольга Кручина билгеләп үткәнчә, «в предлагаемых обстоятельствах конформизм Автора – это единственная доступная ему форма протеста» [2]. Шул ук вакытта ул үзен газаплаучыны уйларында юк итә.

Әмма нәтиҗәдә, парадоксаль рәвештә, комедия көлкеле төс ала һәм камилләшә бара. Башка, тагын бер көтелмәгән метаморфоза килеп туа. Комедия иҗат итү барышында Цензор калын тиреле, тупас түрәдән иҗат шатлыгын татыган псевдо-язучыга – Драматургның авторташына әйләнә.

Драматург (Эмиль Талипов) мәгънәсез салам чәчле сәер шамакай сыйфатында тәкъдим ителә. Спектакль аның stand-up стилендәге монологы белән башлана, анда ул тамашачыга бик күңелле итеп: «Хәлләр ничек, сокамерник?» – дип эндәшә, алга таба: «Ә сез безнең илдә көлүне тыюлары турында ишеттегезме?» – дип хәбәр итә. Әлеге шамакай битлеген ул спектакльнең финалына кадәр саклый.

Ә Цензор (Алмаз Борһанов) исә – үрмәкүчне хәтерләткән, кара башлык кигән бөкре сәер җан иясе образында. Митаниның сәнгати дөньясын үзенчәлекле иткән абсурд стихиясендә актёрлар икесе дә табигый рәвештә яшиләр.

Сценография (авторы Айдар Җәббаров үзе) гади, шул ук вакытта бик тә тәэсирле: Цензор кабинеты диварында стеллаж бар,

тартмалардан кирәкле кулъязмаларны алганда, аның хәрәкәте үрмәкүчнеке сыман җитез; кәгазь турагыч аппарат (шредер) һәм туралган кәгазь таулары, алар, кар көртләре кебек, сәхнәне акрынлап күмеп китә – күпсанлы әсәрләрнең язмышы әнә шундый. Ике персонажның каршылыгы, скетчны хәтерләтеп, шушы фонда бара.

«Коки Митани» әлеге пьесасын 1996 елда яза, һәм аның бай сәхнә тарихы бар. Ул Россиядә бик популяр. Аны Пушкин исемендәге театр (реж. Роман Козак), Васильевскидагы театр (реж. Владимир Петров), Ленсовет исемендәге театр (реж. Фёдор Пшеничный), Евгений Вахтангов исемендәге театр (реж. Изабелла Каргинова), Воронеждагы «Прогресс» арт-үзәге (реж. Михаил Бычков) һ. б. куя. Кагыйдә буларак, Коки Митани әсәрләре алар тарафыннан комик, гротеск-абсурд юнәлештә хәл ителә.

Күрәсең, Айдар Җәббаровны да япон драматургы текстының сәхнә өчен яраклы булуы һәм иронiясенең шәплеге җәлеп иткәндер. Әмма ул үткен сүзле скетч белән генә чикләнмәгән. Алай гына да түгел, көлке пьесадан ул асылы белән фаҗигалы сәнгати фикерле әсәр тудырган. Ләйсән Фәизова «Көлке һәм көл» дигән мәкаләсендә Айдар Җәббаров куелышында икеләтелгән код булуын ассызыклый һәм, әсәрнең исемен аңлатып, болай дип яза: «На татарском языке название его звучит “Көл”, что действительно переводится как “пепел”. Но это омоним, также означающий “смейся”» [3]. Режиссёр регистрларны күчерә, һәм Автор белән Цензорның комик бәхәс-көрәше цензура башбаштаклыгыннан зыян күргән бихисап иҗат әһелләренең фаҗигасына әверелә. Эмиль Талипов һәм Алмаз Борһанов һәр эпизодның ахырында, Б. Брехт алымын кулланып, рольдән чыгалар: парикларын һәм әкәмәт костюмнарын салып ташлыйлар да зал белән аралашучы замана яшьләренә әйләнеп калалар. Талипов барабаннар артына утыра, Борһанов кулына гитара ала һәм алар, бергәләп, Виктор Цой, Зөлфәт Хәким җырларын һәм Хәсән Туфанның «Агыла да болыт агыла» шигыренә язылган җырны башкаралар (музыка кораллары буенча педагог – Йосыф Бикчәнтәев). Ике төрле сәхнә чынбарлыгын берләштергән әлеге алымга күп тапкырлар мөрәҗәгать ителә. Арткы пландагы «Икенче көн», «Өченче көн» һ. б. язулар актёрларны «пьесага» кайтара. Автор һәм Цензорның бәхәс-көрәше җиде көн дәвам итә. Бу – пьесаның язылу этаплары да, дөнья яратылуга ирония булган аллюзия дә.

Ә. Җәббаров спектакльгә документаль катламны да кертеп җибәрә. Танылган театр белгече һәм театр тәнкыйтьчесе Марина Дмитревская болай дип билгели: «спектакль прошит, пропитан татарскими реалиями, фактами, аллюзиями, мемуарами, ссылками и сносками» [1].

Арткы планда цензура корбаны булган татар язучыларының исем-фамилияләре языла: Габдулла Тукай, Кәрим Тинчурин, Хәсән

Туфан, Әмирхан Еники, Гаяз Исхакый, Адлер Тимергалин. Аларның истәлек-хатирәләре яңгырый: бөтенләй язмаска уйлавы турында – Әмирхан Еники, Петербургка барып, патша цензоры Смирновны атып үтерәсе килүе турында – Гаяз Исхакый, «Китмибез!» шигырен тыйганнан соңгы эзәрлекләүләр турында – Габдулла Тукай. Адлер Тимергалин мәктәп ишегалдындагы учакта тыелган әдәбиятны ничек яндырулары һәм тиздән аңа каршы эзәрлекләүләр башлануы турында сөйли. Репрессияләнгән һәм һәлак булган, бер истәлек тә калдырмаган Кәрим Тинчурин уйлап чыгарылган монолог аша тәкъдим ителә: «Ишеттегезме тәнәфестә звонокны? “Зәңгәр шәл”дән бит ул. Минем “Зәңгәр шәл”дән. Мин язган. Сәйдәш, әй, канатланып язды инде музыкасын... Артистларны кушылып җырларга, нотага өйрәтеп азапланган иде, әй... 26 нчы ел иде ул. Премьера көнне тамашачылар ярты сәгать буе пәрдәне яптырмыйча алкышлады! Ярты сәгать. Ә уникe елдан “Зәңгәр шәл” дә, башка әсәрләрем дә туракланып, көл булып күккә очты. Таа-та та-та та-таам!..»

Шулай итеп, спектакль юк ителгән кулъязмаларга реквием булып яңгырый. Алар, кызганычка каршы, янып көлгә әйләнә. Спектакльнең исеме дә шуннан алынган.

Цензор һәм Авторның үзара мөнәсәбәтләре дә көтмәгәндә тагын берничә мөһим үзгәреш кичерә. Геройлар бер-берсенең кулларын кысышкан мизгел килеп җитә, ниһаять, Автор белән Хакимият арасында компромисска ирешергә мөмкин, дигән уй туа. Әмма алдагы эпизодта ук Цензорның чын йөзе ачыла: ул сәеррәк автордаш кыяфәтеннән чыга, кара күзлеген киеп куя һәм Драматургны, дәүләт җинаятьчесе буларак, кулга алачагын белдерә. М. Дмитревская билгеләп үткәнчә, «То есть, не только Драматург придуривался и корчил смешные рожицы – паяц от власти, Цензор тоже играл все это время в свой театр, два лицедея морочили друг друга» [1].

Шулай да Цензор Драматургны кулга алмый, ул аңа: «Китә аласыз», – ди, чөнки аның беркая да барыр җире юклыгын бик яхшы белә. Сугыш бара, һәм Драматургка фронтка китәргә повестка килгән инде. Шулай булгач, Цензорга аны кулга алуның кирәге юк, болай да үтерәчәкләр. Ә «Көлке академиясе» театры белән нәрсә булыр соң? «Ул көлгә әйләнәчәк...» – дип җавап бирә Драматург. Шулай итеп, Автор белән Хакимият арасында бернинди дә татулык була алмый: берсе – иҗатчы, икенчесе – иҗатны үтерүче.

Финалда Драматург – Талипов барабаннар артына утыра һәм Хәсән Туфан сүзләренә язылган җырны башкара:

Агыла да болыт агыла
Туган-үскән җирләр ягына;
Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр,
Нәрсә әйтер туганнарыма?!
Агыла да болыт агыла...

Сүз уңаеннан, Айдар Җәббаровның Камал театрында режиссёрлык дебюты шушы шигырь белән бәйле. 2017 елда ул театрның Кече залында Хәсән Туфанның лагерьда һәм сөргендә язылган шигырьләре буенча «Агыла да болыт агыла» дип исемләнгән диплом алды спектаклен куйды. Шигырь текстлары Туфан Миңнуллинның шагыйрьгә багышланган биографик пьесасыннан алынган күренешләр белән аралашып бара. Ул вакытта ук А. Җәббаров образларының метафораларга төренүе, режиссёрның оригиналь формаларга мөрәҗәгать итүе, телне тоемлавы һәм сүзне гармонияле рәвештә ишарә белән куша белүе театр җәмәгатьчелеген аның таланты турында сөйли башларга мәҗбүр итте. Һәм аңа татарның новатор режиссёры Д. Сираҗиев исемендәге премия бирелде.

«Көл» спектаклендә Хәсән Туфанның көйгә салынган «Агыла да болыт агыла» шигыре символик мәгънә ала: Эмиль Талипов җырны башкарган вакытта, сәхнәнең арткы планында һәлак булган татар язучылары һәм шагыйрьләренең исемлеге күренә.

М. Дмитревская Айдар Җәббаров спектакле турында уйлануларын йомгаклап, болай ди: «Сложносочиненный черно-белый спектакль Заббарова звучит яростной, обугленной песней протеста, двухчасовым поминанием всей цензурованной и уничтоженной татарской литературы, он – некролог репрессированным татарским писателям, среди которых – несомненные классики» [1].

Айдар Җәббаровның сәнгати теле турында сөйләгәндә, аның синтетик, полижанр характерында булуын билгеләп үтмәскә мөмкин түгел: анда клоунада һәм публицистика, кара комедия һәм абсурд, шигърилек һәм кырыс документ теле арасында көчле бәйләнеш күзәтелә. Күпсанлы кинореминисценцияләр («от дзеффиреллевских “Ромео и Джульетты” с музыкой Нино Роты до скандального “Джокера” Тодда Филлипса, который в свою очередь вдохновлялся фильмами Мартина Скорсезе, в частности “Королём комедии” с Робертом де Ниро» [2]) аерым игътибарга лаек.

Шул рәвешле, Айдар Җәббаров үзенең «Көл» спектаклендә, Коки Митани пьесасының оригиналь текстын үзгәртмичә диярлек, документаль материал кертү, читләштерү техникасын, жанрлар синтезы һәм башка сәнгать чаралары һәм алымнарын куллану исәбенә, үзенең авторлык фикерен формалаштыра. Ул – үз халкының язмышы белән бәйле, әмма шул ук вакытта ачык театраль формалы. Шуның белән ул яшь режиссёр иҗатының гомуми контекстына табигый рәвештә кереп китә дә.

**Әдәбият**

1. *Дмитревская М.* «Пепел» Айдара стучит в мое сердце» // URL: https://ptj.spb.ru/blog/pepel-ajdara-stuchit-v-moe-serdce/?ysclid=m563e6u41g253596752 (дата обращения: 18.01.2025).

2. *Кручина О.* Как дотла сгореть, спроси у пепла // URL: https://rt-online.ru/kak-dotla-goret-sprosi-u-pepla/ (дата обращения: 10.01.2025).

3. *Фаизова Л.* Смех и пепел // URL: https://ptj.spb.ru/archive/110/process-110/smex-i-pepel/ (дата обращения: 16.01.2025).

4. *Хабутдинова М.М.* «Возвращение слова Тукая» на казанскую сцену первой четверти XXI в.: открытия и находки // Зрелищные искусства: контакты и контексты: материалы II Междунар. науч.-практ. конф., посвящ. 90-летию со дня рождения Марселя Салимжанова и 100-летнему юбилею Анаса Тумашева / сост. и науч. ред. Р.Р. Султановой. Казань: ИЯЛИ, 2024. С. 34–45.

***Шевченко Елена Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Шевченко Елена Николаевна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Центра искусствоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*elenachev@inbox.ru*

УКД 76.03.09

***Р.Н. Галиева***

# 1920 ЕЛЛАР ТАТАР ПЛАКАТЛАРЫНЫҢ ВИЗУАЛЬ ТЕЛЕ ҺӘМ ПЛАСТИК ЧИШЕЛЕШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена яркому и своеобразному явлению отечественного искусства – татарскому плакату 1920-х гг., в котором отразились особенности революционной графики и проявилась связь с национальными и региональными видами татарской художественной культуры такими, как настенные календари, шамаили, театральные афиши, получившие активное развитие на рубеже XIX–XX вв. Анализируя их формы и содержание автор показывает, как в них вырабатывались принципы взаимодействия текста и изображения, проявившиеся затем в плакате. В качестве основных отличительных особенностей татарских плакатов 1920-х гг. автор указывает двуязычие и использование в татарском языке до конца 1920-х гг. арабской графики, а также введение национального компонента через татарские типы, костюмы, обычаи, предметы быта. В качестве приоритетных жанров выделяются просветительские, а также рекламные плакаты, активно развивавшиеся со второй половины 1920-х. гг. Рассматривая художественные особенности татарских плакатов, автор выделяет два направления – реалистическое и авангардное, обращаясь к произведениям конкретных художников. Многочисленные реалистические плакаты Г. Арсланова на санитарно-гигиенические темы при несовершенстве художественных форм вносили значимый вклад в просвещение народа. Представители авангардного направления (Ф. Тагиров, Ш. Мухамеджанов и др.) работали преимущественно в рекламном плакате, используя разнообразные методы и приемы. В конструктивистских плакатах Ф. Тагирова модернизированный арабский шрифт, на основе почерка куфи, сочетался с абстрактными или предельно геометризованными формами. Ш. Мухамеджанов, работая с латиницей, оперировал условными фигуративными формами, применял фотомонтаж. Автор приходит к выводу о том, что оба направления в татарском плакате, пропагандируя новые идеи, используя новые художественные методы, сохраняли национально-культурные особенности.

**Ключевые слова:** плакатное искусство, реализм, авангард, шамаиль, календарь, афиша, арабская каллиграфия, яналиф (латиница).

The article is devoted to the bright and peculiar phenomenon of Russian art – the Tatar poster of the 1920s., which reflected the features of revolutionary graphics and showed a connection with national and regional types of Tatar art culture such like wall calendars, shamail, theater posters, which were actively developed at the turn of the XIX–XX centuries. Analyzing their forms and content, the author shows how they developed the principles of interaction between text and image, which then appeared in the poster. As the main distinguishing features of Tatar posters of the 1920s. the author indicates bilingualism and use in the Tatar language until the end of the 1920s. Arabic graphics, as well as the introduction of a national component through Tatar types, costumes, customs, everyday life. Educational and advertising posters, which have been actively developing since the second half of the 1920s, are

highlighted as priority genres. Considering the artistic features of Tatar posters, the author identifies two directions, realistic and avant-garde, referring to the works of specific artists. Numerous realistic posters of G. Arslanov on sanitary and hygienic topics with imperfect art forms made a significant contribution to the education of the people. Representatives of the avant-garde style (F. Tagirov, Sh. Mukhamedzhanov, etc.) worked mainly in an advertising poster, using a variety of methods and techniques. In F. Tagirov's constructivist posters, modernized Arabic script, based on kufi handwriting, was combined with abstract or extremely geometrized forms. Sh. Mukhamedzhanov, working with the Latin alphabet, operated on conditional figurative forms, used photomontage. The author comes to the conclusion that both directions in the Tatar poster, promoting new ideas, using new artistic methods, preserved national and cultural characteristics.

**Keywords:** Poster art, realism, avant-garde, shamail, calendar, poster, Arabic calligraphy, yanalif (Latin).

1920 еллар татар плакаты уникаль төбәк һәм милли үзенчәлекләрнең күпкырлы палитрасын чагылдыра. Аның үзенчәлекләре һәм стилистик чагылышлары Татарстан АССР өчен хас була. Аның барлыкка килүе рус плакатының үсеше белән дә, татар сәнгати мәдәниятенең традицион формалары белән дә тыгыз бәйләнгән. Дини кануннар тарафыннан хайван һәм кеше сурәтләренең тыелуы әлеге формаларның үсешен чикли. Нәтиҗәдә, шартлы сәнгать теле барлыкка килә. Һәм ул гарәп каллиграфиясендә, декоратив-гамәли сәнгатьтә гәүдәләнеш таба. Гарәп каллиграфиясе сәнгате күп гасырлар дәвамында татар мәдәниятенең аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Чикләү һәм тыюларга карамастан, чынбарлыктагы дөнья татар сәнгатендә предметларның, үсемлекләрнең һәм гыйбадәт кылу урыннарының символик сурәте рәвешендә яши. Реалистик сурәтләр XX гасыр башында аеруча активлаша, бу – татар җәмгыятен модернизацияләүгә һәм милли мәдәниятне рус һәм Европа мәдәниятенә якынайтырга омтылган җәдитчелек хәрәкәте белән бәйле була. Реалистик сурәтләр татар сәнгати мәдәниятенең календарь һәм шәмаил кебек төрләренә актив кертелә башлый. Соңгылары – татар плакатының турыдан-туры элгәрләре.

XIX гасырның икенче яртысыннан башлап актив үсеш кичергән татар календарьлары еш кына гамәли характерда булып, көндәлек тормышта файдалы күптөрле мәгълүматны үз эченә алган. Календарьлар табигате белән, плакатлар кебек үк, күпжанрлы булганнар, эчтәлек һәм функциональ билгеләнешенә карап, берничә категориягә бүленгәннәр:

– фәнни-сәнәгати;
– әдәби;
– фәнни-әдәби;
– сәүдә белән бәйле;
– гомуми файдалану өчен [2: 44].

Полиграфик эшләнеше һәм формасы ягыннан календарьларның берничә төре була: дивари плакат-календарь; дивари өзмә календарь;

кесә календаре. Татар календаре көннәр, айлар, даталар һәм бәйрәмнәр исемлеген үз эченә алган белешмә басма гына түгел, ә тормышның төрле өлкәләрен чагылдырган кыска мәкаләләрне, белдерү, реклама характерындагы материалларны, легенда һәм кыйссалар, мәкальләр, биографик мәгълүматлар, фотоматериаллар, рәсемнәр, астрономик карта һәм схемаларны сыйдырган мөстәкыйль чыганак та булып тора [2: 120]. XIX гасыр азагында татар мәгърифәтчесе К. Насыйри календарьларына Казан мәчетләренең, Сөембикә манарасының рәсемнәре кертелә. 1883 ел календаренда авторның үзе тарафыннан ясалган астрономик карталар, схемалар урын ала [2: 77]. Казанда Бертуган Кәримовлар типографиясендә өч ел дәвамында (1908–1910) нашир С.И. Строгановның календарьлары чыгарыла, һәр басманың эчтәлеге үзгә: беренчесендә «Ландыш» сабыны рекламалана, моннан тыш, календарьда Мөхәммәд пәйгамбәрнең шәхси гигиенаны үтәүнең мөһимлеген ассызыклаган сүзләре дә бар [2: 50]. Әлеге мисаллар Татарстан плакат сәнгате һәм (эчтәлеге, функциональ бурычлары ягыннан) зур практик әһәмияткә ия, шулай ук бай тематик бизәлешле календарьлар арасында охшашлыкларның аеруча күп булуын ышандырырлык итеп раслый. Календарьларда кайвакыт басма шәмаилләрне дә очратабыз, мөселман бәйрәмнәре дә аларга бәйле күрсәтелә [8: 38].

Татар басма шәмаиле – Коръән сүрәсе яки башка дини эчтәлекле сүзләр гарәп каллиграфиясен кулланып язылган һәм сакраль мәгънәгә ия дивар панносы ул. Шул исәптән төсле литография ысулы белән нәшер ителгән басма шәмаил XIX гасырда Казанда беренче милли типографияләр ачылуга бәйле рәвештә барлыкка килә һәм үсә [8: 21]. 1840 еллар башына шәһәрнең берничә типографиясе шәмаилләр бастырып чыгару белән шөгыльләнә. Берсе – Яңа Татар Бистәсендә, икенчесе шәһәр үзәгендә (Шевицның Шәрык типографиясе) урнаша. Шулай ук XX гасыр башына И.В. Перов, А.М. Кокорев (соңрак В.В. Вараксин), И.Н. Харитонов, Г.М. Вечеслов, М.А. Чиркова, В.З. Еремеев һәм А. Шашабрин, бертуган Мөхәммәтҗан һәм Шәрифҗан Кәримовларның шәхси типографияләрендә дә шәмаилләр чыгарыла [8: 22]. Басма шәмаилләрне профессиональ рәссам-каллиграфлар эшли. Еш кына шәмаилнең композицион чишелешенә гарәп язмасының төрле каллиграфик ысулларда башкарылган язулары һәм милли орнаментлар гына түгел, ә стильләштерелгән сурәтләр дә кертелә: әйтик, Мәккә, Мәдинә, Истанбул (Константинополь), Иерусалим һәм башка шәһәрләрнең архитектура һәйкәлләре һәм мөселманнарның изге урыннары, ислам дине символлары. Кайбер шәмаилләр вак детальләргә бай булып һәм аскы өлештә аңлатма язуы биреп, шәһәр пейзажы принцибы буенча эшләнә. Шәмаил дини табыну объекты гына түгел, ә үзенчәлекле картина булып, өйнең интерьерын да бизәп тора, аның төп сәнгати элементлары – шрифт һәм орнамент. Татар рәссамнары сурәтне метафорик ысуллар ярдәмендә тәкъдим итәләр һәм стильләштерәләр, шәмаилнең стилистик мөмкинлекләрен һәм эчтәлеген киңәйтәләр,

эстетик сыйфатлар өстиләр һәм кайбер реалистик мотивлар кертеп җибәрәләр. С.М. Червонная билгеләп үткәнчә, шәмаилдә стильләштерелгән предметлар гарәп язмасы белән симбиоз бәйләнеш һәм стилистик бердәмлек тәшкил итә. Хәрефләрдә, метаморфозалар узып, төрле архитектура элементлары ачык күренә башлый [7: 266]. Шәмаилләргә осталар каллиграфик ысул белән шулай ук һиҗри ай исемнәрен, мөнәҗәт, бәетләрдән алынган өзекләр һәм башка шигъри юллар, афоризмнар, мәкаль-әйтемнәрне дә язганнар [1: 31]. Татар басма шамаиленең образлы төзелеше һәм пластик чишелеше 1920 еллар татар плакатында чагылыш таба. Шәмаилне үзенә буйсындырган визуаль принциплар, шрифт һәм орнамент композицияләрен урнаштыру методлары татар плакатларының сәнгатьчә чишелешен алдан билгели.

1920 елларда татар плакатының тагын бер үсеш чыганагын татар театры афишасы тәшкил итә. XX гасыр башы татар театрының актив эшчәнлек күрсәтүе соңгысының тиз үсүенә сәбәп була. Татар театры афишасы үзенчәлекле сәнгати якын килү һәм чишелеше белән аерылып тора, шуңа күрә ул реклама һәм афиша арасындагы балансны саклаган плакат сәнгатенең аерым төре итеп карала ала. Афишаларда кулланылган гарәп язмасы үзе үк плакат бизәген хәтерләтә. Бу очракта татар кулъязма һәм басма китапларының бизәлеше белән бәйләнеш күзәтелә: китап битләре дә афишалардагы элементлар – бордюр, зигзаг, виньетка һәм ромблар белән бизәлә [3: 16]. Татар театры плакаты литография яки типография наборы техникасында эшләнә. Бу плакатларның күбесе аноним була.

1920 елларда татар плакаты барлыкка килү беренче чиратта җәмгыятьтәге революцион үзгәрешләр һәм Гражданнар сугышы белән бәйле була. Бу чорда плакат, агитация-массачыл сәнгатьнең бер өлеше буларак, күп кенә мәсьәләләрне – агитация, пропаганда, культура-агарту, аеруча кискен проблемаларны ачыклау кебек бурычларны хәл итәргә тиеш була.

Гражданнар сугышы чоры плакаты, нигездә, иллюстрацияләр характерында булып, анда реалистик күренешләр һәм гади чишелеш өстенлек итә, чөнки плакат киң халык массаларына (күбесенчә укый-яза белмәгән кешеләргә) якын һәм аңлаешлы телдә сөйләргә тиеш. Плакат бастыру белән шөгыльләнгән җирле нәшриятлар шактый төрле булып, шул сәбәпле чыгарыла торган плакатлар палитрасы да бик чуар. Казанда плакат бастырып чыгару белән түбәндәге үзәкләр шөгыльләнә: Республика запастагы армия политбүлеге һәм Идел буе хәрби округы сәяси идарәсе (ПУОКР ПРИВО), Главполитпросвет, Казан губернасы матбугат бүлеге, Госиздат (Губпечатьне алмаштырган), Санпросвет һәм Сәламәтлек саклау халык комиссариаты (Наркомздрав), Ачларга ярдәм (Помгол) оешмасының, Мөселман хәрби коллегиясенең махсус басмалары һ. б. [6: 252]. 1920 еллар башында плакат жанрлары арасында сәяси, агитацион һәм героик плакатлар өстенлек итә. Аларда социаль активлыкка чакыру,

эпидемияләргә каршы көрәш һәм гигиенага өндәү, Идел буенда һәм Россиядә наданлык, җимереклек, ачлык белән көрәш, музейларны үстерүдә булышлык күрсәтергә чакыру кебек темалар күтәрелә.

Казан губернасы инкыйлабка кадәр үк Идел-Урал төбәге халыкларының мәгарифен һәм мәдәниятен үстерүдә зур роль уйнаган фәнни, мәдәни һәм нәшрият үзәге була. Аңа соңыннан автономияле республикаларга әйләнгән төбәкләр – Чуваш һәм Мари АССРлар керә. Казан географик яктан үзенә якын булган башка милли төбәкләр: Башкортстан, Удмуртия АССР һ. б. белән тыгыз бәйләнеш тота. 1920 елларда Казан күрше төбәкләр өчен плакатлар чыгару үзәгенә әверелә. Биредә рус һәм татар телләрендә генә түгел, мари һәм чуваш телләрендә дә плакатлар бастырыла.

Плакатлар күптөсле литография һәм аклы-каралы литография техникасында башкарыла, аларга кайвакыт, кулдан буяп, төсләр өстиләр, сирәк кенә плакатлар линогравюра техникасында эшләнә. Россия революцион плакатының бер өлеше буларак, Казан плакаты башкала плакатларының күп кенә үзенчәлекләрен үзләштерә. Әмма шул ук вакытта җирле үзенчәлекләрне дә үстереп һәм ныгытып, индивидуаль сыйфатлар белән баетыла. 1920 еллардагы татар плакатының төп үзенчәлеге – аның икетеллелегендә: плакат текстлары еш кына параллель рәвештә татар һәм рус телләрендә бирелә. Плакатның композицион структурасы кыска лозунг, сурәт, текст һәм график элементларны үз эченә ала, бу аның күзгә ташланучанлыгын һәм тамашачыга тәэсирен көчәйтү максатыннан эшләнә. Төсләргә килгәндә, алар аз һәм тыйнак, минималь күләм белән чикләнә. Плакат композициясенә гадәттә милли персонаж – татар егете яки татар кызы кертелә. «Татар хатыны! Советлар Россиясенең барлык хезмәтчәннәре сафына бас. Рус пролетаркалары белән кулга-кул тотынышып, син соңгы богауларны өзәрсең!» дигән плакатта индустриаль пейзаж фонында традицион киемнән, озын толымлы татар хатыны рус кызының кулын кыса. Татар плакатларының иң мөһим үзенчәлекләреннән берсе шунда ки, 1920 еллар ахырына кадәр аларда гарәп графикасы кулланыла. Гарәп язуы аңлатма бирүче текст буларак аста яки өстә урнаша, русча текстны кабатлый. Нәсех язуы күбрәк очрый, тәгълик яки куфи – сирәгрәк.

1920 еллар татар плакаты шактый чуар була, анда, бик кызыклы оригиналь эшләр булуга карамастан, күбесенчә лубоктан төшереп алынган рәсемнәрне хәтерләткән примитив плакатлар өстенлек итә. Әлеге профессиональ дәрәҗәдә эшләнмәгән плакатларда татар рәссамнарының үзләре өчен яңа өлкәдә беренче ышанычсыз адымнары һәм график плакат теленең төп принципларын аңламаулары чагыла. О.Л. Улемнова билгеләп үткәнчә, Казан плакат продукциясе массасында лубоктан төшереп алынган рәсемнәр дәрәҗәсендәге үзешчән әсәрләр күп була. Иске мәктәп рәссамнары плакатның үзенчәлекләрен аңламыйлар һәм аны жанр иллюстрацияләре җыелмасына әйләндерәләр [4: 87]. Рәссам Госман Арслановның (1897–1941) 1927 елда

Татарстан Сәламәтлек саклау халык комиссариаты һәм Кызыл Хачның Татарстан өлкә комитеты тарафыннан халыкны агарту максаты белән нәшер ителгән плакатлар сериясе күбесенчә хатын-кызлар аудиториясенә юнәлдерелә, санитария, гигиена нормаларын, яңа туган баланы карау кагыйдәләрен, шулай ук йөклелек һәм бала тапканнан соңгы тернәкләнү чорына бәйле тәкъдимнәрне үз эченә алып, ана һәм бала сәламәтлегенә аңлы рәвештә якын килергә булыша. Плакатлар иллюстрация характерында, детальләргә бай, өлешчә фактуралар да эшкәртелгән, рәссам орнамент бизәкләре, күп кадрлы композицияләр куллана, традицион милли кием кигән татар кешесе образларын сюжетка кертә, текст рус һәм татар телләрендә тәкъдим ителә. С.М. Червонная ассызыклаганча, 1922 елда Пермьнән Казанга килеп, актив эшли башлаган Г.В. Арсланов татар матбугатында алыштыргысыз, бердәнбер рәссам була: ул авырып китсә, татар журналының чираттагы саны чыкмый кала яки тоткарлана. Сәнгать белгече Г.В. Арсланов рәсемнәренең «эстетик камиллектән ерак» торуын дәлилли, әмма рәссамның сәләте һәм эшкә җаваплы мөнәсәбәте, халык мәгарифенә керткән өлеше югары бәяләнә [6: 190].

1920 еллар уртасында бөтенләй яңа милли авангард плакаты барлыкка килә. Ул реклама плакаты формасында аеруча актив үсеш ала. Аның пәйда булуы яшь татар рәссамнары эшчәнлеге белән бәйле. Иң күренекле вәкилләрнең берсе – Фаик Шакирҗан улы Таһиров (1906–1978). Аның күпкырлы эшчәнлеге китап һәм журнал дизайнын, плакатлар ясауны колачлый, типография шрифтларын эшләүгә керткән өлеше дә зур. Рәссам үз иҗатында революция чоры символларының берсенә әверелгән конструктивизм стилен һәм гарәп каллиграфиясенең күпгасырлык традицияләрен берләштерә. Ф. Таһиров еш кына гарәп каллиграфиясенең иң борынгы язу ысулы булган куфины куллана, ул төгәл квадрат формаларга ия булуы, конструктивизмга туры килгән төгәллеге һәм гадилеге белән аерылып тора. Рәссам үз эшләрендә композиция ясаганда еш кына симметрия һәм ассиметриягә мөрәҗәгать итә. Аның хезмәтләрендә геометрик абстракт формалар: полосалар, түгәрәкләр, ромблар бар, кара һәм кызыл төсләр өстенлек итә, кайвакыт реалистик элементлар да күренгәли, ләкин алар һәрвакыт гомумиләштерелгән һәм стильләштерелгән. Мәсәлән, «Сул аягың белән атла» (1927) плакатында татар крестьяны образы чиктән тыш стильләштерелгән, геометрик фигуралар ярдәмендә мөмкин кадәр төгәл итеп эшләнгән, шул ук вакытта үзенчәлекле милли детальләр дә бар: башында яшел түбәтәй, ак чолгаулы чабата кигән. О.Л. Улемнова болай дип билгеләп үтә: «[для Ф. Тагирова] органичным было оперирование абстрактными формами, которые он использовал как средства выражения мировоззренческих и политических категорий» [5: 7].

1927 елда Татарстанда латин шрифтына – Яңалифкә күчәләр. Ф. Таһиров яңа латин шрифтларын булдыруда һәм яңа алфавитны пропагандалаган реклама плакатлары ясауда актив катнаша, «Яңа-

лиф» нәшрияты белән эшли, «Укый беләсеңме?» (1927) дигән агитплакат ясый, анда ул абстракт композиция төзегәндә симметрия алымын куллана, тамашачыга ике шрифтны күреп чагыштыру, уңайлырагын сайлау мөмкинлеге бирә. Шакир Нигъмәт улы Мөхәммәтҗанов (1900–1972) «Татиздатта китап сатып ал. Газета-журналларга языл» (1929) дигән плакат ясый.

Ул композициягә китап һәм журнал тышлыкларын, газета битләрен кертү өчен, фигуративлык белән шартлылыкны берләштереп, авангард фотомонтаж техникасын куллана. Нәтиҗәдә, яңа басмаларга өндәүче татар кешесе фигурасы абрисы янәшәсендә синкопалы ритмик композиция барлыкка килә.

Шул рәвешле, 1920 еллар татар плакаты яңа график тел эзли һәм элгәреге чор татар сәнгати мәдәнияте казанышларына һәм традицияләренә таянып эш итә. Текст һәм сурәт арасында гармонияле бәйләнеш традицияләре – орнаментка нигезләнгән гарәп язуы, архитектура һәм предмет мотивлары – чагылыш тапкан татар басма шәмаилләре сәнгати чишелеш ягыннан 1920 еллар татар плакат сәнгатенә иң якын торганнары. Плакатның шәмаилдән төп аермасы шунда ки, плакатта традицион шәмаилләрдә булмаган кеше сурәтләре бар. Татар плакаты төп ике – реалистик һәм авангард формаларда үскән, дидек. Реалистик плакат татар шәмаилләренең һәм XIX гасыр календарьларының сәнгати стилистик традицияләрен дәвам итә, аларда барлыкка килгән сурәтләү системасын җәмгыятьнең яңа социаль структурасын чагылдырган персонажлар белән тулыландыра. Авангард плакаты, үз заманы конструктивизм идеяләренә, шулай ук авангард эзләнүләргә аваздаш гарәп каллиграфиясенең борынгы традицияләренә таянып, шушы вакыт ихтыяҗлары нигезендә яңа алымны һәм үткәндәге мирасны синтезлый. 1920 еллар ахырыннан авангард плакаты татар язуының яңа формасын – Яңалифне алга җибәргән төп трибуналарның берсе була. Татар плакатының ике формасы да татар тамашачысы белән үзара бәйләнеш урнаштыруга, аңа аңлаешлы телдә яңа сәяси, социаль, гендер, медицина, мәгариф һәм башка актуаль идеяләрне җиткерүгә юнәлдерелгән (Гражданнар сугышы елларында агитация һәм пропаганда плакаты рәвешендә, 1920 еллар уртасыннан реклама плакаты формасында). Әлеге үзара бәйләнеш хәзерге заман шартларында уникаль татар мәдәниятенә хас үзенчәлекләрне һәм традицияләрне саклап калырга ярдәм итте.

**Әдәбият һәм чыганаклар**

1. *Гилемшин Ф.Ф.* Особенности текстового содержания арабографических шамаилей // Грамота. 2017. № 8(74): в 2-х ч. Ч. 2. С. 29–32.

2. *Миннуллина Л.З.* Татарские печатные календари XIX – начала XX вв. Казань: Заман, 2015. 175 с.

3. *Султанова Р.Р.* История татарского театра в плакатном искусстве. Казань, 2017. 352 с.

4. *Улемнова О.Л.* Казанская графика 1920–1930-х годов. Казань: ИЯЛИ, 2018. 336 с.

5. *Улемнова О.Л.* Пионеры конструктивизма: Фаик Тагиров, Александра Коробкова в Казани и Москве // Пионеры конструктивизма: Фаик Тагиров, Александра Коробкова в Казани и Москве. К 100-летию со дня рождения Фаика Тагирова. Каталог выставки. Казань: Заман, 2006. С. 5–9.

6. *Червонная С.М.* Искусство Советской Татарии. М.: Изобразительное искусство, 1978. 296 с. ил.

7. *Червонная С.М.* Искусство Татарии. М.: Искусство, 1987. 352 с.

8. *Шамсутов Р.И.* Слово и образ в татарском шамаиле от прошлого до настоящего. Казань: Татар. кн. изд-во, 2003. 199 с.

***Галиева Рената Наил кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать иститутының Сәнгать белеме үзәге аспиранты*

***Галиева Рената Наилевна,***
*аспирант Центра искусствоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан*
*renata1319@yandex.ru*

УДК 75.05

***Л.М. Шкляева,***
***Н.В. Герасимова***

# Ф.Г. ХАЛИКОВ ИҖАТЫНДА ТАРИХИ ЖАНР

В данной статье рассматриваются творческие работы живописца Фирината Халикова, посвященные истории татарского народа XVI века. В результате применения иконологического и семантического методов исследования авторы приходят к выводу, что художник убедительно, в академической манере, изображает реальные исторические события, однако интерпретирует их в трагическом и отчасти романтическом аспектах. Масштабные полотна привлекают внимание выразительностью художественных приемов – умелым использованием контрастов не только цветовых, но и тональных отношений. Создавая на полотнах образы ушедшей эпохи, автор не стремится к документальной достоверности, но уделяет главное внимание воплощению идеи сопричастности своих героев судьбе Родины, воспевает их мужество и стойкость. Материал исследования основан на произведениях художника, хранящихся в коллекциях Государственного историко-культурного и художественного музея-заповедника «Казанский Кремль» и Государственного музея изобразительных искусств Республики Татарстан.

**Ключевые слова:** живописные произведения, исторические сюжеты, Казань, Ф.Г. Халиков.

This article examines the creative works of the artist Firinat Khalikov, dedicated to the history of the Tatar people of the 16th century. As a result of applying icono logical and semantic research methods, the authors come to the conclusion that the artist convincingly, in an academic manner, depicts real historical events, but interprets them in tragic and partly romantic aspects. Large-scale canvases attract attention with the expressiveness of artistic techniques – the skillful use of contrasts of not only color, but also tonal relationships. Creating images of a bygone era on canvases, the author does not strive for documentary authenticity, but pays main attention to the embodiment of the idea of his heroes' involvement in the fate of the Motherland, glorifies their courage and fortitude. The research material is based on the artist's works stored in the collections of the State Historical, Cultural and Art Museum-Reserve "Kazan Kremlin" and the State Museum of Fine Arts of the Republic of Tatarstan.

**Keywords:** paintings, historical subjects, Kazan, F.G. Khalikov.

Хәзерге вакытта сынлы сәнгатьтә тарихи сюжетларны реалистик гәүдәләндерү бик тә актуальләште. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: совет чорында бу жанрга Б.И. Урманче (1897–1990), Х.Ә. Якупов (1919–2010) һәм башка танылган татар рәссамнары еш мөрәҗәгать итә. Бигрәк тә Бакый Урманче картиналары игътибарга лаек. Аның әсәрләренең күптөслелелеккә корылган чишелешендә, яссы сурәтләү манерасында һәм силуэтларының түгәрәк дулкынсыман

салмак сызыкларында Шәрык сәнгатенә хас алымнар ярылып ята. Харис Якуповның эшләрендә социалистик реализм билгеләре – монументальлек һәм героик образларны гиперболаштыру, көчләрнең идеологик күзлектән дөрес конфликты ачык чагыла. Зур рәссам иҗатына хас әлеге алымнарны шәкерте Ф.Г. Халиков та (1957) актив үзләштерә.

Бүгенге көндә Фиринат Габделхәй улы Халиков – Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2001), Россия Сәнгать академиясе академигы (2020) һәм, академик реализм традицияләренә тугрылыклы булып, Татарстанда тарихи жанрга караган тематик картиналар остасы. Үзенең «Казан өчен сугыш» (1996), «Олуг Мөхәммәд» (2003) һ. б. әсәрләрендә ул еш кына татар халкының үткәндәге героик сәхифәләренә дан җырлый. Бу полотноларның шактый өлеше «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музейтыюлыгы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее тупланмаларында саклана.

Казанда рәссамның беренче шәхси күргәзмәләре оештырыла башлаганнан бирле (1997), Татарстан сәнгать белгечләре Ф.Г. Халиков әсәрләре белән даими кызыксыналар. Мәсәлән, Р.Г. Шаһиева аның иҗатын колачлаган ике альбомга язган кереш мәкаләләрендә (2005, 2017) Казан ханлыгының үткәнен сурәтләгәндә аның матур сәнгати чаралар белән эш итү сәләтен ассызыклап күрсәтә, әйтерсең рәссам үзе дә әлеге вакыйгаларның шаһиты булган [5; 4]. «В его многофигурных полотнах и исторических пейзажах зрители увидели затерянное в анналах истории Казанское ханство, её строительную мощь и цельность, крепости, мечети, ханские дворцы, посады, колоритные базары и типажи легендарных казанцев» [5: 50].

Алдагы альбом (2012) бүлекләренең авторлары – Д.К. Вәлиева, Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова, О.Л. Улемнова, Д.Д. Хисамова һ. б. сәнгать белгечләре, Ф.Г. Халиков иҗатының әһәмиятен бәяләп, автор манерасының индивидуальлеген, кабатланмаслыгын, катлаулылыгын ассызыклыйлар. «Күпфигуралы эскизларында һәм пейзажларында ул теманы өйрәнә, композицияләр төзи, детальләрне барлый» [1: 174].

Безнең тикшеренүдә төп игътибар Ф.Г. Халиковның 1980–2005 елларда язылган һәм Казан ханлыгын яулап алу тарихына бәйле картиналарына, XX гасыр ахыры һәм хәзерге заман тамашачыларының аларны ничек кабул итүенә юнәлтелгән.

А.А. Рылов исемендәге Вятка сәнгать училищесында махсус белем алып, Ф.Г. Халиков Казан шәһәрендә Россия Сәнгать академиясенең иҗат остаханәләренә алына (1993), анда академик Х.А. Якупов җитәкчелегендә Көнбатыш Европа һәм рус сынлы сәнгатенең классик кануннарын үзләштерә. Рәссам төрле жанрларда картиналар яза – еш кына замандашларының портретларын иҗат итә яисә балачагы һәм яшьлеге үткән Киров өлкәсе авыллары пейзажларының кырыс

матурлыгын тасвирлый. Әмма 1990 еллар уртасыннан алып 2000 еллар башына кадәр аның иҗатында үзәк урынны нәкъ менә тарихи жанр алып тора. Бу шуның белән дә аңлатыла: аның остаханәдә белем алу чоры үзгәртеп корудан соңгы елларга туры килә, бу вакытта республика җәмәгатьчелегенең күп кенә вәкилләрен татар халкының милли үзенчәлеге һәм тарихи үткәне белән бәйле мәсьәләләр борчый. Әлеге темалар яшь рәссамның да игътибарын җәлеп итә, иҗатын колачлап ала һәм авторның дөньяга үзенчәлекле карашын да чагылдыра. Рәссам тарихи вакыйгаларны ышандырырлык итеп сурәтли, әмма еш кына аларны фаҗигалы аспектта интерпретацияли. Моңа ирешүдә бөтен сәнгать алымнарын эшкә җигә.

Ф.Г. Халиков XVI гасыр Казан ханлыгы язмышы белән бәйле темаларга мөрәҗәгать итә. Рәссам үзенең полотноларында татар мәдәнияте өчен гаять әһәмиятле, инде 500 елдан артык дан да җырланган, гаепләнгән дә героик образларны гәүдәләндерә. Ул иҗат иткән масштаблы тарихи әсәрләр Татарстанның фән, сәнгать һәм сәясәт эшлекләләре арасында шунда ук танылу ала.

Киндердә башкарылган эшләрендә Ф.Г. Халиков Казан ханлыгы халкының төрле катлауларын сурәтли. Аларны охшаш хис-кичерешләр берләштерә – я каршылык күрсәтү («1552 елгы октябрь вакыйгасы» һ. б.), я югалту («Сөембикәнең хушлашуы» һ. б.). Моннан тыш, рәссам үзенең картиналарында Казан ханлыгы корылмаларын да торгыза. Кирпеч-таштан салынган Хан Кирмәне биналарының һәм бистәдәге агач йортларның реконструкцияләрен ул А.Х. Халиков (1994) [2], Ф.Ш. Хуҗин (2005) [3] кебек күренекле галимнәрнең материалларына таянып эшли.

Ф.Г. Халиков, тарихи жанр традицияләрен дәвам итеп, Татарстан сынлы сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертте. Татар тарихының героик һәм бер үк вакытта фаҗигалы образларын тудырып, Татарстанның хәзерге заман рәссамнары арасында үзенең мәртәбәле урынын алды. Рәссам чынбарлыкта булган вакыйгаларны торгызырга омтыла, ул моңа, күтәрелгән теманың өйрәнелү дәрәҗәсе биргән мөмкинлектән чыгып, сурәтнең тарихи масштаблылыгын тормыш-көнкүрештәге дөреслек белән берләштерү аша ирешә. Аның тарихи әсәрләре арасында оста башкарылуы һәм хисси киеренкелекне бирә алуы белән «Колшәриф мәчете янында соңгы сугыш» (2005), «Сөембикәнең хушлашуы» (2001) картиналары аерылып тора.

«Колшәриф мәчете янында соңгы сугыш» полотносында Ф.Г. Халиков 1552 елда Явыз Иван гаскәрләре Кремльне алгандагы сугышны сурәтли, киндердә аның кульминациясендәге киеренкелекне гәүдәләндерүгә ирешә. Шул ук вакытта якларның каршы торуы шундый итеп күрсәтелә ки, тамашачы сугыштан читкә чыга торган вакыйгаларның алга таба үсешен фаразлый ала. Рәссам Мәскәү патшасының күпкә өстен хәрби көчләренең тиздән җиңүгә ирешәчәген һәм Кремльдәге Хан мәчете имамы Кол Шәрифнең шәкертләре белән

бергә һәлак булачагын алдан сиземләүне тамашачыга җиткерә. Сугыш панорамасы янгын шәүләләре һәм ялкынның кызыл телләре белән чуарланган, кара төтен белән тулы күкне дә үз эченә ала. Тарихи сугыш чынбарлыкка әверелә һәм шул ук вакытта күпкатлы мәгънәгә ия була бара. Ул хәрби куәтнең рухи көчкә каршы торуын күрсәтә, кешене һәлак итсәң дә, аның рухын сындыру мөмкин түгел. Картинаның төп герое – коралсыз имам Кол Шәриф – хәрби хәрәкәтләрнең үзәгендә сурәтләнгән, баш өстенә ике кулы белән изге Коръән китабын күтәргән (яшел ислам байрагы фонында ул аерылып тора). Ике сакраль предмет та сугышчылар урнашкан композициянең иң югары ноктасын тәшкил итә, ул, мәңгелекне символлаштырып, күккә очы белән юнәлтелгән өчпочмак ясый. Һөҗүм итүчеләрнең бердәм массасы, сөңгеләр белән коралланып, калкулыктагы сакчыларны кысрыклап, астан өскә ыргыла. Шулар арасында ачык төстәге киемнәрдән яшь шәкертләр игътибарны җәлеп итә. Алар остазларын әйләндереп алган. Ярсулы бәрелеш бераз түбәндәрәк: биредә рәссам көрәшүче дошманнарны бар буена сурәтли. Беренче планда, аларның аяклары янында, шәкертнең үле гәүдәсе ята. Һәлак булган исемсез геройга күңелләрдә ихтыярсыз теләктәшлек уяна – ул җиңелгән, әмма буйсынмаган.

Бу картинаның биш йөз ел элек булган хәрби бәрелеш белән ни дәрәҗәдә ярашуын әйтүе кыен. Әмма шунысы төгәл билгеле: имам һәм шагыйрь Кол Шәриф чыннан да яшәгән һәм Казанны саклап вафат булган. Әмма Ф.Г. Халиков ерак үткәндә калган сугышны шундый итеп чагылдырган ки, тамашачы аны «Сөембикәнең хушлашуы» композициясендәге кебек үк чынбарлыкта булган вакыйга дип кабул итә.

Бу картинаның сюжеты Сөембикә ханбикә образын аның тормышының Казан ханлыгын басып алу белән бәйле иң фаҗигалы мизгелләренең берсендә ачуга багышлана. 1551 елда, башкаланы рус гаскәрләре яулап алганчы ук, җирле татар морзалары Сөембикәне Мәскәү патшасына тапшыралар. Шул рәвешле үз дәүләтләренең бәйсезлеген саклап калуга өметләнәләр. Полотнода патшабикәне Мәскәүгә җибәрү вакыты сурәтләнгән. Нәни улы белән Сөембикә утырган арба, патшабикәнең язмышы кебек үк, Казан Кремленең ачык капкасыннан алып чыгучы таш җәелгән юл буйлап аска тәгәри. Аның алга таба юлы, туры һәм күчерелмә мәгънәдә, өстән аска таба юнәлгән. Ул әле патшабикә, әмма инде әсир ителгән, кыйммәтле киемнәрдән, ләкин гади арбада утыра. Ул әле ханзадә Үтәмешгәрәйне кочаклый, яратып күкрәгенә кыса, әмма аның нәни улы белән аерылышу вакыты, Касыйм ханы белән аянычлы туе якынлаша. Тугрылыклы халкы яраткан ханбикәсе белән саубуллашып, дога кылып, баш ия. Атлы арбаны кораллы сакчылар озата бара. Табигать күренеше дә киләчәк кайгы-хәсрәтләр турында хәбәр итә сыман. Нугай далаларыннан килгән Сөембикәгә туган җире кебек якын булган киңлекләр җәйрәп ята.

Ул, хушлашып, аларга соңгы тапкыр моңсу карашын ташлый. Кояш якты елга өстендә асылынып торган күк йөзен каплаган караңгы болытлар артына яшеренергә әзер. Кояшның нурлары, әсир ханбикәне юаткандай, бер генә секундка су өстендә чагылып ала. Ф. Халиков вакыйгада төп катнашучыларны эре планда һәм тәэсирле алым кулланып сурәтли. Ул әсир ханбикәне халык төркеме өстеннән югары күтәреп, рухының ныклыгын ассызыклый.

Шулай итеп, Ф. Халиковның 1990 еллар ахыры – 2000 еллар башы тарихи нәкыше Казан ханлыгының соңгы дәверенә бәйле темаларны сайлау белән характерлана. Ул аларны реалистик планда ачып бирә. Үз геройларын баскан килеш тасвирлап, автор тамашачыларның да полотнода сурәтләнгән вакыйгаларда «катнашуына» ирешә. Зурлыгы буенча масштаблы картиналарда рәссам еш кына күпфигуралы композицияләрне файдалана. Төрле катлау вәкилләренең киемнәренә киенгән төрле яшьтәге икенчел дәрәҗәле геройларны кертү исәбенә тамашачыда чорның дөреслеген тою хисе тудыруга ирешә. Аларның костюм комплекслары тарихи чынбарлыкка таянып, җентекләп эшләнгән. Казан ханлыгы чорының архитектура пейзажын торгызу да ышанычлылык дәрәҗәсен арттыра.

Ф.Г. Халиков үзен мәдәни үзенчәлек кыйммәтенә дан җырлаучы рәссам итеп тоя. Ул киндердә нәкъ менә Россиядәге үзгәртеп кору елларыннан соңгы халыклар аңы өчен хас идеяләрне гәүдәләндерә. Шуңа күрә XVI гасыр Казан ханлыгы каһарманнары һәм шәһәрләре аеруча ачык күрсәтелә. Алар һәр рәссамның җәмгыятьтәге ихтыяҗ һәм өметләргә туры килгән уйлап чыгарылган образлар иҗат итү хокукын чагылдыра. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: аларга һәм рәссам шәхесенә карата кызыксыну тамашачыларның кабул итүенә идеологик компонентның йогынтысы белән аңлатыла. Ул 1990–2010 елларда милли үзаңның күтәрелүендә чагылыш тапты. Хәзерге вакытта, Россиядә милли каршылыклар кимегән чорда, Ф.Г. Халиковның әсәрләре үз сәнгати кыйммәтләрен югалтмыйлар, еракта калган кызыклы һәм мифлаштырылган тарих буенча күрсәтмә материал булып хезмәт итәләр.

Ф.Г. Халиков, авторлык алымнары белән академик башкару манерасын берләштереп, татар милли геройлары образлары галереясын төзи, һәм шуның белән Татарстан рәсем сәнгатендә тарихи жанр үсешенә зур өлеш кертә.

**Әдәбият**

1. *Валеева Д.К., Валеева-Сулейманова Г.Ф., Иорданская Н.И. и др.* Awnиринат Халиков. Живопись. Графика. Скульптура. Дизайн. Казань: Заман, 2012. 208 с.: ил.

2. *Халиков А.Х.* Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. Казань: Фэн, 1994. 162 с.: ил.

3. *Хузин Ф.Ш.* Древняя Казань. Казань: Казан: Экс-Пресс плюс, 2005. 152 с.: ил.

4. *Шагеева Р., Магдеев Р.* Фиринат Халиков. М.: Белый город: Воскресный день, 2017. 64 с.: ил.

5. *Шагеева Р.Г.* Халиков Ф.Г. Вечная Казань. Альбом. Казань: Заман, 2005. 192 с.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Герасимова Наталья Владимировна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татаристика һәм мәдәният белеме кафедрасы доценты*

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*кандидат искусствоведения, старший научный сотрудник Центра искусствоведения Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

*luda-next@yandex.ru*

***Герасимова Наталья Владимировна,***
*кандидат искусствоведения, доцент кафедры татаристики и культуроведения Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского (Приволжского) федерального университета*

*natal-040183@mail.ru*

УДК 930.27:94(470.41)

***А.М. Гайнетдинов***

# САМАРА ӨЛКӘСЕ КАМЫШЛЫ РАЙОНЫНЫҢ ЭПИГРАФИК МИРАСЫ

В статье представлен краткий анализ эпиграфических памятников, выявленных на кладбищах татарских населенных пунктов Камышлинского района Самарской области. В ходе экспедиции, организованной Институтом истории им. Ш. Марджани АН РТ в 2022 г., в некрополях 9 сел и деревень было обнаружено 107 эпиграфических памятников, имеющих историческое значение. Татары, проживающие в Камышлинском крае, в плане установки памятников строго соблюдали нормы шариата, стремились к экономии средств, ставили простые и небольшие памятники, не писали на них лишних слов, не изображали узоры и орнаменты. Практически все лапидарные памятники региона выполнены в упрощенном стиле, имеют небольшие размеры, их тексты врезные, очень короткие, лаконичные, а на некоторых татарских надмогильных плитах имеются только родовые тамги.

**Ключевые слова:** татарская эпиграфика, памятники, некрополи, Камышлинский район, Самарская область.

The article presents a brief analysis of epigraphic monuments found in the cemeteries of Tatar settlements in the Kamyshly district of the Samara region. 107 epigraphic monuments of historical significance were discovered in the necropolises of 9 villages during the expedition organized by the Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences in 2022. The Tatars living in the Kamyshly region strictly observed the norms of Sharia in terms of installing monuments, sought to save money, erected simple and small monuments, did not write unnecessary words on them, did not depict patterns and ornaments. Almost all lapidary monuments of the region are made in a simplified style, are small in size, their texts are incised, very short, laconic, and some Tatar tombstones have only family tamgas.

**Keywords:** Tatar epigraphy, monuments, necropolises, Kamyshly district, Samara region.

Соңгы елларда тарихи-мәдәни истәлекләргә игътибар артты дияргә мөмкин. Төрле оешмалар илебездә яшәүче халыкларның мәдәни мирасын саклау, файдалану, популярлаштыру өлкәсендә зур эшчәнлек алып баралар. Татар эпиграфик истәлекләрен ачыклау һәм өйрәнү эшләрендә дә бераз активлык сизелә башлады. Тик чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезнең ташъязма мирасын тикшерү өлкәсендә хәлләр мактанырлык түгел. Шуңа күрә татарлар яшәгән һәр төбәк җентекләп өйрәнелергә тиеш, әби-бабаларыбыздан сакланып калган бер генә эпиграфик ядкәрне дә игътибарсыз калдырмыйча, аларны халыкка кайтару өчен тырышырга кирәк.

Самара өлкәсе Камышлы районының борынгы кабер ташлары да фәнни-практик яктан тулысынча өйрәнелмәгән иде. 2019 елда

бу якларга оештырылган экспедиция вакытында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре И.Г. Гомәров һәм В.М. Усманов тарафыннан 14 гарәп язулы кабер ташы теркәлә [3: 4]. Әлеге төбәктәге татар авыллары зиратларында бүгенге көнгә кадәр сакланып калган бөтен ташъязма истәлекләрне барлау һәм өйрәнү өчен, 2022 елның маенда Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни хезмәткәре Сайрус Хәмидуллин белән фәнни экспедициягә чыктык. 1939 елга кадәр (кириллицага күчкәнче) куелган гарәп язулы кабер ташларының һәрберсен эзләп табып, фоторәсемгә төшердек, үлчәмнәрен алдык һәм текстларын укыдык. Аннан соңгылары өйрәнелмәде, чөнки таш чагыштырмача яңарак була барган саен, аның тарихи әһәмияте кими. Әлеге төбәктә XX йөзнең 50 нче елларында тулысынча гарәп графикасында язылган ташлар да бар.

Камышлы районының кайбер авылларында борынгы ташбилгеләр бөтенләй очрамады, икенчеләрендә исә аларның саны берничә дистәдән артып китте. Иң күп ташъязма истәлек сакланган сала – Яңа Ярмәк. Анда барлыгы 45 таш ачыкланды. Камышлы авылының ике зиратында 23 ташбилге табылды. Яңа Усман саласының ике зиратында исә 13 эпиграфик истәлек сакланып калганлыгы билгеле булды. Иске Ярмәк, Иске Балыклы, Чулпан авылларында да борынгы эпиграфик истәлекләрнең саны 6 га җитте. Калган торак пунктларга килгәндә, Татар Байтуганында – 5, Яңа Усманда – 3, Дәүләтколда – 2, Иске Усманда нибары 1 ташбилге табылды.

Районда табылган иң борынгы кабер ташы 1879 елга карый. Камышлы авылының борынгы зиратындагы бу эпиграфик истәлек Уразмәт Юныс улына аның улы Галиулла тарафыннан куелган. Ташта кабер иясенең шәҗәрәсе дә күрсәтелә: Уразмәт бине Юныс бине Габдулла бине Габделҗәлил бине Рәхмәтулла. Чагыштырмача борынгы саналган, 1890 елда вафат булган Бибисабира Рәхмәтулла кызына куелган кабер ташын да атап китәргә мөмкин. Яңа Усман авылының икенче зиратында да 1890 елга караган ташбилге саклана, шулай ук 1893 һәм 1898 елларга нисбәт ителгән кабер ташлары да ачыкланды. Яңа Ярмәк авылында исә 1892 елгы эпиграфик истәлек табылды. Камышлы районында тагын да борынгыраклары булган. Әмма, кызганычка каршы, алар инде юкка чыккан. Сакланганнарының язуларына зыян килсә дә, кайберләренең текстлары әле табигатьнең кырыс шартларына бирешмәгән, даталар һәм исемнәр, авырлык белән булса да укыла.

Төбәктә дин әһеленә куелган кабер ташы да табылды. Ул – Камышлы авылының икенче зиратында Шәйхеләбрар хәзрәтнеке (1931).

XIX – XX гасыр башында Камышлы төбәгендә кабер ташлары ясау өчен комташ һәм известьташ кына кулланылган. Аларны урындагы таш карьерларыннан алганнар. Ташларның барысы да примитив рәвештә уеп эшләнгән. Экспедиция вакытында рельефлы,

ягъни калкытып эшләнгән кабер ташлары очрамады. Аларны, махсус кисеп, ниндидер бер формага да салып тормаганнар, өчпочмаклы яки турыпочмаклы ташларга кабер иясе хакында кыскача гына мәгълүмат язылып, кабер өстенә урнаштырылган. Гомумән, ташка язу сәнгате Камышлы төбәгендә зур үсеш алмаган. Моңа халыкның матди хәле тәэсир иткән булса кирәк. Гадәттә, профессиональ рәвештә эшләнгән сыйфатлы ташбилгеләрне бай, югары катлау вәкилләре куйган, чөнки аларны эшләтү бик кыйммәткә төшкән. Элекке заманнарда бер таш яздыру – бер ат, югары зәвык белән ясалганы берничә ат бәясенә төшкән [4: 56]. Гади халыкның фәкать эшкәртелмәгән кыргый таш яки кечкенә агач багана һәм такта кую гына хәленнән килгән. Яңа Усман авылының икенче зиратында агачка уеп эшләнгән ике билге ачыкланды. Алар, үзенә күрә, кабер ташы функциясен үтиләр, шуңа да игътибардан читтә калырга тиеш түгелләр.

Ташка язу, бизәк төшерү процессы гаять катлаулы булып, остадан күп көч, тырышлык, сабырлык һәм сәләт соралган. Дымлы килеш җиңел эшкәртелгәнгә күрә, эш өчен җир астыннан яңа чыккан ташларны сайлаганнар [1: 52]. Кипкәч, аларга язу төшерү, әлбәттә, авыррак булган. Ташларны «еш кына ике метр озынлыгындагы зур пычкы белән дүрткел формада кисәннәр, балта белән эшкәрткәннәр, каләм белән язганнар һәм махсус өтергеләр ярдәмендә уеп бизәк төшергәннәр. Әгәр дә эш барышында таш кибеп катыланып китсә, язарга уңайсыз була башласа, аны берникадәр вакыт су эченә салып тотканнар яисә өстенә су сибеп торганнар, һәм шул рәвешле ташны йомшартып, әүвәлге хәленә кайтарганнар» [4: 55–56].

Камышлы районында сакланган гарәп язулы кабер ташларының үлчәмнәре зур түгел. Иң зур таш 90 сантиметрдан артмый. Эпиграфик истәлекләрнең уртача озынлыгы исә нибары 45–50 сантиметр гына. Башка төбәкләр белән чагыштырганда, Камышлы районы ташлары кечкенә үлчәмнәре белән аерылып тора. Мәсәлән, Татарстанда сакланган борынгы кабер ташларының уртача озынлыгы якынча 90 сантиметр. Безнең фикеребезчә, ташларның шундый булуы Камышлы төбәге халкының тыйнаклыгы белән дә аңлатыладыр.

Гадәттә, борынгы татар ташбилгеләренә кабер иясе хакында мәгълүматтан тыш, Коръән аятьләре, хәдисләр, догалар, хикмәтле сүзләр, шигырьләр язылган. Гомумән, борынгы татар эпитафияләрен дүрт өлешкә бүләргә мөмкин: кереш, төп, дога һәм өстәмә өлешләр. Ташъязмаларның кереш өлешендә Аллаһны яисә ахирәтне искә төшерә торган сүзләр яки җөмләләр урын алган. Алар һәрвакыт Коръән иңгән телдә, ягъни гарәпчә язылып, Аллаһның исем-сыйфатлары, атрибутлары яки Коръән аятьләре һәм хәдисләрдән гыйбарәт. Шулай ук адәм баласына үлемне, ахирәтне, Аллаһны искә төшерүче сүзләр дә еш кулланылган. Халкыбызның борынгы эпитафияләренең төп өлешендә кабер иясенең, атасының исем-шәрифләре (кайвакыт бабасының да исеме яисә кыскача шәҗәрәсе, титулы), вафат булу

датасы (кайчакта үлүенең сәбәбе) һ. б. язылган. Гадәттә, бу өлеш татар телендә булган, бик сирәк очракта гына гарәп телендә яки ике телдә дә бирелгән. Эпитафияләрнең өченче өлеше – мәрхүм өчен дога кылу. Бу өлеш татар телендә дә, гарәп телендә дә булырга мөмкин. Ташка язу осталарының яратып яза торган үз догалары булган. Кабер ташының арткы һәм уң-сул якларында да өстәмә эпитафик компонентлар язылырга мөмкин. Әлеге өстәмә өлештә еш кына шигъри юллар китерелгән.

Камышлы районында сакланган күпчелек кабер ташларында исә фәкать кабер иясенең исеме, аның атасының исеме (кайбер очракта, хатын-кыз булса, иренең исеме дә) һәм үлгән елы (кайбер очракта туган елы да) күрсәтелгән. Бары тик Иске Ярмәктә Фатыйма Вәкъказ кызының кабер ташында гына «Аятел-көрси» догасы язылган, Камышлы авылының икенче зиратында Коръәндә урын алган «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун» («Чынлыкта, Без Аллаһныкы һәм, чынлыкта, без Аңа кайтачакбыз») сүзләре, биш ташта «Лә иләһә илләллаһ» («Аллаһтан башка гыйбадәт кылынырга лаеклы зат юк») тәүхид кәлимәсе, өч ташта бу кәлимәнең «Мөхәммәд әр-рәсүлуллаһ» («Мөхәммәд – Аллаһның илчесе») дигән дәвамы язылган. Дин галимнәре кабер ташларына артык сүзләр язуны өнәмәгән. Ризаэддин Фәхреддин ташларга ничек һәм нәрсә язылырга тиешлеген аермачык итеп язып калдырган: «Кабер ташлары нотык һәм хөтбәләр язылачак дәфтәрләр, матур язу үрнәге һәм инша язылачак кара такталар түгел. Шуның өчен вафат булучының исеме, гаилә һәм фамилиясе дөрес язылу, туу һәм вафат көннәре хатасыз теркәлү җитә» [5: 555–556].

XIX гасырда – XX гасыр башында кайвакыт саннарны кабул ителгәнчә сулдан уңга таба түгел, ә уңнан сулга таба язу очраклары күзәтелә. Гарәп телендә сүзләр һәм хәрефләр уңнан сулга таба язылганга күрә, саннар да шулай язылырга тиеш, дип уйлаганнар, күрәсең. Шулай ук киресенчә дә булган: саннарның сулдан уңга таба язылуын белгән кайбер ташка язучылар шулар янында килгән «йыл» сүзен саннарның уң ягына язганнар, мәсәлән, «1925 елда» урынына «йылда 1925» дип, «1928 елда» урынына «йылда 1928» дип, ялгыш язу күзәтелә. Камышлы төбәге кабер ташлары текстларына да менә шушы үзенчәлек хас.

Кабер өстенә язулы ташбилге кую мөмкинлеге булмаса, тамгалар уелган таш бастырылган. Камышлы районы зиратларында шундый ыру тамгалары шактый. Камышлы авылының ике зиратында барлыгы – 14, Яңа Ярмәктә – 10, Иске Ярмәктә – 5, Яңа Усманда – 3, Иске Балыклы һәм Татар Байтуганында берешәр тамга табылды.

Тамга – документларга, хезмәт коралларына, җир буйларына, терлекләргә куела яки салына торган ыру билгесе, мөһере. Нигездә, татарларда һәр нәселнең үз тамгасы булган, тик буыннар алышынган, нәсел ишәйгән саен, ул бераз үзгәрешләр дә кичергән. Кабер ташына куелган ыру билгесе аша кабер иясенең кайсы нәселгә һәм гаиләгә караганын белеп булган. Тамгаларны мөселман татарлар гына түгел,

ислам диненнән аерылып, язусыз калган керәшен татарлары да актив кулланганнар, зиратларындагы агач такталарга төрле билгеләр төшергәннәр [2: 144–145]. Тамгалар бөтен төрки халыкларда да киң таралыш алган һәм аларның, әлбәттә, рун алфавиты белән берникадәр бәйләнеше бар.

Кайбер ташбилгеләрнең өстендә, ягъни түбәсендә кечерәк кенә чокыр күрергә мөмкин. Бу, яңгыр яуганда шунда җыелган суны кошлар һәм бөҗәкләр эчә алсын өчен, шулай эшләнгән. Хайваннарга шул рәвешле яхшылык күрсәткән өчен, кабер иясенә, шулай ук ташны ясаучыга яки куючыга савап язылырга мөмкин, дип уйланылган.

Эш барышында Камышлы районының ике авылында казах милләтеннән булган өч кешенең кабер ташлары ачыкланды, шуларның икесенең тамгалары да бар. Казахларның ташбилгеләре җиңел таныла. Беренчедән, исемнәре милләтләренә ишарәләсә, икенчедән, казахлар ташларда кабер иясенең кайсы ырудан, нәселдән булуын да күрсәткәннәр. Яңа Ярмәктә 1932 елда Коранкол Татәмбәк улы һәм Душхан Имбәт улы, Чулпан авылында 1925 елда Зарман исемле кеше җирләнгән. Алар Кече җөз составына кергән Тана һәм Алаша ыруыннан булганнар. Бирегә казахлар сәүдә итү яисә дини белем алу өчен килгәннәрдер дип уйланыла. Бу факт ике милләт арасындагы тыгыз бәйләнешне күрсәтә.

Шулай итеп, Камышлы районында сакланган гарәп язулы эпиграфик истәлекләрнең барысы да диярлек өйрәнелде. Һичшиксез, алар Самара төбәге татарларының тарихын, телен һәм мәдәниятен өйрәнү чыганагы буларак зур әһәмияткә ия.

Ниһаять, Самара өлкәсе Камышлы районы зиратлары эпиграфик планда тикшерелде, дип санарга нигез бар. Без 1879–1939 елларга караган ташбилгеләрнең текстларын фәнни әйләнешкә керттек.

Камышлы төбәгендә яшәгән татарлар каберләргә ташлар кую мәсьәләсендә шәригать нормаларын төгәл үтәгәннәр, тыйнаклыкка омтылганнар, эшкәртелмәгән гади һәм зур булмаган ташбилгеләр куйганнар, аларга артык сүзләр язмаганнар, бизәкләр һәм орнаментлар төшермәгәннәр. Төбәкнең барлык лапидар һәйкәлләре гадиләштерелгән стильдә эшләнгән, зур булмаган үлчәмнәргә ия, аларның текстлары кыска, бары тик уеп язылган, кайбер татар кабер ташларында ыру тамгалары гына бар.

Камышлы районында таш кисү сәнгате зур үсеш алмаган. Моңа җирле халыкның авыр матди хәле һәм эре мөселман рухи үзәкләреннән ераклыгы тәэсир иткәндер, күрәсең. Шуңа карамастан, биредә сакланган чагыштырмача борынгы эпиграфик истәлекләр зур тарихи әһәмияткә ия һәм бердәм татар тарихи-мәдәни мирасының бер өлеше булып санала.

**Әдәбият**

1. *Әхмәтҗанов М.И.* Татар археографиясенә сәхифәләр. Тарих пәрдәләре күтәрелгәндә: Фәнни-популяр хезмәт. Казан, 2012. 132 б.

2. *Макаров Г.* Ыру тамгасы, баш казыгы һәм ташбилге – борынгыдан килгән тарихи хәтер билгеләре // Проблемы изучения истории заселения и образования населенных пунктов Альметьевского региона. Казань, 2000. Б. 143–156.

3. *Усманов В.М.* Самар өлкәсе татар эпиграфик һәйкәлләре. Егерме өченче китап. Казан, 2024. 180 б.

4. *Усманов В.М.* Тарихи ядкәрләр. Уфа: ДизайнПолиграфСервис, 2005. 168 б.

5. *Фәхретдин Р.* Габдессәлам мөфтинең хәтер дәфтәре // Шура. 1913. № 18. Б. 555–556.

***Гайнетдинов Айдар Марсиль улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*яңа тарих бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Гайнутдинов Айдар Марсилевич,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник*
*отдела новой истории Института истории имени Ш. Марджани АН РТ*

*aydargm@yandex.ru*

УДК 631.95

***Җ.И. Фәйзрахманов***

# ФӘНГӘ ЯҢАЛЫК КЕРТҮЧЕ
## (профессор Ф.С. Сибәгатуллинның фәнни мирасы)

Статья посвящена многогранной деятельности известного ученого, доктора ветеринарных наук, профессора и члена-корреспондента Академии наук Республики Татарстан, внесшего большой вклад в развитие сельского хозяйства и ветеринарии региона Фатиха Саубановича Сибагатуллина. В статье отражено его успешное совмещение научных исследований с административной работой, занимая такие важные должности, как министр сельского хозяйства и советник Президента РТ по экологии. Его научное наследие насчитывает 93 публикации, среди которых монографии и учебные пособия. Фатих Саубанович активно сотрудничал с различными научными учреждениями, способствовал внедрению новых технологий в животноводстве. Так в статье описывается его уникальный подход к обучению студентов. Он был известным преподавателем, давая знания студентам Казанского государственного аграрного университета и вдохновляя их на любовь к животным. Его работа в области молочного животноводства и участие в разработке национальных проектов по развитию агропромышленного комплекса оставили заметный след в аграрной науке Татарстана.

**Ключевые слова:** ученый, профессор, эколог, преподаватель, новатор в науке, целеустремленный, талантливый организатор, внимательный наставник, тенденции научно-технического прогресса.

The article is devoted to the diverse activities of the famous scientist, Doctor of Veterinary Sciences, Professor and Corresponding Member of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, who made a great contribution to the development of agriculture and veterinary medicine in the region, Fatih Saubanovich Sibagatullin. The article reflects his successful combination of scientific research with administrative work, holding such important positions as Minister of Agriculture and Advisor to the President of the Republic of Tatarstan on Ecology. His scientific legacy includes 93 publications, including monographs and textbooks. Fatih Saubanovich actively collaborates with various scientific institutions, promotes the introduction of new technologies in animal husbandry. Thus, the article describes his unique approach to teaching students. He was a famous teacher, giving knowledge to students of the Kazan State Agrarian University and inspiring them to love animals. His work in the field of dairy farming and participation in the development of national projects for the development of the agro-industrial complex left a noticeable mark on the agricultural science of Tatarstan.

**Keywords:** scientist, professor, ecologist, teacher, scientific innovator, goal-oriented, talented organizer, attentive mentor, trends in scientific and technological progress.

Сибәгатуллин Фатих Сәүбән улы (01.05.1950–24.06.2023) – ветеринария фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе, «Европа-Азия» Халыкара гуманитар академиясе

академигы, 2021 елдан Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнехановның экология буенча киңәшчесе.

Фатыйх Сәүбән улы Сибәгатуллин 1950 елның 1 маенда Татарстан АССР Кызыл Юл (хәзерге Арча) районының Апаз авылында туа. 1958–1965 елларда Апаз сигезьеллык мәктәбендә, 1965–1967 елларда Шушмабаш урта мәктәбендә укый. 1968 елда Казан ветеринария институты студенты була. 1983 елда Саратов югары партия мәктәбен тәмамлый.

1966 елда Арча районының «Ватан» совхозы эшчесе сыйфатында, хезмәт юлын башлап җибәрә. 1973–1974 елларда – Яшел Үзән районы «Бишнә» совхозында баш ветеринария табибы. 1974–1976 елларда – Балтач районы Чапаев исемендәге колхозда ветеринария табибы. 1976–1980 елларда – Балтач районы «Правда» колхозы рәисе.

1980 елда ул партия эшенә күчә. КПССның Балтач райкомы икенче секретаре (1980–1983) һәм Арча районы башкарма комитеты рәисе урынбасары (1983–1984) вазифаларын башкара. 1984–1990 елларда КПССның Мамадыш райкомы беренче секретаре була.

1990–1995 елларда – Татарстан Репубпликасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры. 1993 елда Казан ветеринария институтында «Базар икътисадына күчү чорында республиканың ветеринария хезмәтен камилләштерү» темасына диссертация яклап, ветеринария фәннәре кандидаты була. 1995 елда «Татарстан Республикасында ветеринария эшен оештыруны камилләштерү» темасына докторлык диссертациясен уңышлы яклый.

1996–2005 елларда – Нурлат (Октябрь) районы һәм Нурлат шәһәре администрациясе башлыгы, шулай ук халык депутатларының район советы президиумы рәисе.

2000–2004 елларда – II чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт советы депутаты. 2005 елда Казан дәүләт финанс-икътисад институтын тәмамлый. 2006–2007 елларда Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре башлыгы, шулай ук даими булмаган нигездә муниципаль район башлыгы булып эшли. «Татнефтепром-Зюзеевнефть» АҖ Директорлар советы рәисе һәм «Татнефтепром» АҖ Директорлар советы әгъзасы.

Фатих Сибәгатуллин 2008 елда РФ Дәүләт думасы депутаты итеп сайлана. Ул – кайда гына эшләсә дә, үзеннән соң якты эз калдырган шәхес.

Фатих Сәүбән улы озак еллар дәвамында зур административ эшне фәнни-тикшеренү эшчәнлеге белән янәшә алып бара, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе, Казан дәүләт аграр университеты, Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты һәм башка фәнни учреждениеләр белән тыгыз хезмәттәшлектә, галимнәр коллективларын берләштерергә омтылып яши. Шуның матур үрнәге – икътисад фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, югары мәктәп Халыкара

фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе, Казан дәүләт аграр университеты ректоры Җәүдәт Ибраһим улы Фәйзрахманов белән озак еллар дәвам иткән фәнни һәм иҗади хезмәттәшлек.

Фатих Сәүбән улы 1999–2023 елларда Казан дәүләт аграр университетының «Терлекчелек продукциясен җитештерү һәм эшкәртү технологиясе» кафедрасында эшли. 1999 елда Нурлат шәһәрендә Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясенең филиалы ачыла. Бу эштә дә ул башлап йөрүчеләрнең берсе була. Үсемлекчелек һәм терлекчелек буенча практик дәресләр Нурлат районының иң алдынгы хуҗалыкларында үткәрелә. Татарстан Республикасы ипподромы һәм ат спорты музеенда Ф.С. Сибәгатуллин Казан дәүләт аграр университетының өлкән курс студентлары белән «Ветеринария нигезләре һәм хайваннарны үрчетү биотехникасы», «Терлекчелек экологиясе», «Атчылык» буенча дәресләр үткәрә. Фатих Сәүбән улы үзе атларны бик яраткан. Студентлар белән эшләгәндә дә, ул аларның иң элек атларны яратуына ирешүне максат итә. Ул чын мәгънәсендә үз эшенең остасы була.

Фатих Сәүбән улы авыл хуҗалыгы җитештерүен, шул исәптән сөт терлекчелеген үстерүгә дә үзеннән зур өлеш кертә. «2010 елга кадәр Татарстан Республикасында агросәнәгать комплексын үстерү» өстенлекле милли проектын һәм «2008–2012 елларга Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгын үстерү» республика максатчан программасы авторларының берсе. Ул Татарстан Республикасында терлекчелекне үстерү концепциясен эшләүдә дә катнаша. Республиканың Авыл хуҗалыгы министрлыгы белгечләре белән бергә «Ак Барс Агро» ҖЧҖ, «Красный Восток» ААҖ, «Сөләйманов» КФХ һәм Россия Федерациясенең башка мегафермаларында аның төп нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча фәнни-методик җитәкчелекне үз кулына ала.

Ф.С. Сибәгатуллин – 93 фәнни эш, шул исәптән терлекчелек һәм ветеринариянең төрле мәсьәләләре буенча 4 монография, шулай ук 5 уку әсбабы авторы. Казан дәүләт аграр университетында аның җитәкчелегендә бер кандидатлык диссертациясе яклана.

Ф.С. Сибәгатуллин Казан дәүләт аграр университеты Гыйльми советы тарафыннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең авыл хуҗалыгы фәннәре бүлегенә «Авыл хуҗалыгы фәннәре» белгечлеге буенча академиклыкка кандидат итеп күрсәтелә.

Эшчәнлегенең соңгы елларында А. Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институты белән берлектә «Терлекчелек калдыкларын утильләштерү өчен биологик активаторлардан файдалану» темасына фәнни тикшеренүләр үткәрә, аерым алганда, «Мефосфон» препараты (фосфин кислотасының бис(оксиметил) тозы) ярдәмендә хайваннар тиресен һәм кош тизәген куркынычсыз һәм тизләтелгән ферментацияләү ысулын һәм аннан нәтиҗәле файдалану юлларын эзли.

Ф.С. Сибәгатуллин һәм аның җитәкчелегендәге фәнни коллектив үткәргән тикшеренүләр нәтиҗәсендә тавык тизәген «Мефосфон» препараты белән зарарсызландыруның нәтиҗәлелеге исбатлана:

– тизәкнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысы киметелә, тизәкнең куркынычлык классы III дәрәҗәдән IV гә кадәр төшә;

– тизәкне ферментацияләү процессы тизләтелә, нәтиҗәдә аның агулылыгы 1,7 тапкыр кими;

– эчәк таягы төркемендәге бактерияләр (ЭТТБ) саны һәм энтерококклар 1,8 тапкыр кими.

Шулай ук тавык тизәгеннән «Компост «ПУ–1» органик ашламасы алу өчен «Мефосфон» препаратын кулланның нәтиҗәлелеге билгеләнә.

1. Компостлаштырганда «Мефосфон» препаратын куллану микроблар комплексының активрак эшләвен тәэмин итә, тизәкнең «өлгерү» вакытын кыскарта, әйләнә-тирә мохиткә аның зарарлы йогынтысын киметә, аксымнарның тизрәк һәм тулырак таркалуына, аммиак бүленеп чыгуга һәм тирәлекне оптималь дәрәҗәдә селтеләндерергә ярдәм итә. Димәк, ГОСТ 53117-2008 таләпләренә тулысынча туры килгән һәм составында патоген микрофлора булган «Компост «ПУ-1» органик продукты барлыкка килә.

2. «Йолдыз» сортлы сабан бодаен үстергәндә «Компост «ПУ-1» продуктын органик ашлама сыйфатында куллану:

– орлыкларның шытып чыгуын арттырырга булыша;

– үсемлекләрнең үсеш процессын яхшырта (тулысынча өлгергән очракта башак озынрак була);

– җыелган ашлык күләмен арттыра;

– бөртекнең сыйфатын (пыяласыманлыгы, җилемчә микъдары, аксым микъдары) яхшырта.

Шулай итеп, «Мефосфон» биологик активаторы ярдәмендә тиресне, кош тизәген утильләштерү, алга таба авыл хуҗалыгында югары нәтиҗәле органик ашлама буларак кулланылып, максатчан продукт алу ысулы булырга мөмкин, дип раслап була. Бу туфракның уңдырышлылыгын, авыл хуҗалыгы культураларының уңышын күтәрергә һәм тулаем экологик хәлне яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк.

Галимнәр төркеме тарафыннан эшләнгән тизәкне зарарсызландыру технологиясенә дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе бар. 2017 елдан, биологик актив «Мефосфон» препаратын кулланып, терлекчелек калдыкларының хәвефлелек «классын киметү»нең килештерелгән технологик регламенты эшләнә. Препаратны куллануның максатка ярашлылыгы Россия Федерациясе Табигый байлыклар һәм экология министрлыгы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан раслана.

Фатих Сәүбән улы – фәндә новатор, максатчан һәм сәләтле оештыручы, игътибарлы остаз була. Кайда гына эшләмәсен, патриотлыгы, зур җаваплылык хисе, эшкә ихлас бирелгәнлеге белән аерылып тора. Барлык дәүләт вазифаларында да ул фән-техника прогрессы тенденцияләрен гамәлгә ашырырга омтыла.

Ф.С. Сибгатуллин Россия Федерациясе Дәүләт думасының Экология һәм әйләнә-тирә мохитне саклау комитеты әгъзасы, Гуманитар

фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы һәм Россия Федерациясе Федераль собраниесе Дәүләт думасының Табигый ресурслар, табигатьтән файдалану һәм экология комитеты әгъзасы, углеводород чималы комитеты рәисе, Россия Федерациясе Федераль собраниесе Дәүләт думасы депутаты буларак зур иҗтимагый эш алып бара.

Фатих Сәүбән улы Сибәгатуллин Казан дәүләт аграр университетындагы хезмәттәшләре хәтерендә хезмәт кешесе, галим һәм Татарстан Республикасының лаеклы гражданины булып сакланыр. Аның командада эшли белүе, лидерлыгы, профессиональлеге уңышлы эшчәнлегенең нигезенә ята һәм олы ихтирам хисе уята. Озак еллар дәвамында Ф.С. Сибәгатуллин кафедрада авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, профессор, Россия табигать фәннәре академиясе академигы Г.С. Шәрәфетдинов һәм авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, доцент Р.Р. Шәйдуллин җитәкчелегендә нәтиҗәле эшли.

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгын үстерүгә, кырларның һәм фермаларның продуктлылыгын арттыруның фәнни проблемаларын эшләүгә, үсемлекчелектә һәм терлекчелектә заманча технологияләрне гамәлгә кертүгә зур өлеш керткән өчен Ф.С. Сибәгатуллин Россия табигый фәннәр академиясе «Агросәнәгать комплексының фәнни проблемалары» бүлеге хакыйкый әгъзасы итеп сайлана (1996).

1997 елда аңа «Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә, 2000 елда ул Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премиясе лауреаты була. Биология фәне һәм авыл хуҗалыгы өлкәләрендәге уңышлары өчен аңа Н.И. Вавилов исемендәге көмеш медаль (2001), Халыклар Дуслыгы ордены (1986 ), «Почёт билгесе» ордены (2002), «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены (2007), шулай ук IV дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены, «Россиянең агросәнәгать комплексын үстерүгә керткән өлеше өчен» алтын медале, «Россия агросәнәгать комплексын үстерүгә керткән өлеше өчен» көмеш медале, «Казанның 1000 еллыгы» медале һәм башка күпсанлы дәүләт бүләкләре тапшырыла, шул исәптән ул – «Авыл хуҗалыгындагы казанышлары өчен» ордены кавалеры да (Франция, 1994).

Казан дәүләт аграр университетының тарих музеенда Фатих Сәүбән улы Сибәгатуллинга багышланган стенд күпсанлы тамашачыларның игътибарын җәлеп итә. Анда галимнең хөкүмәт бүләкләре, мактау грамоталары, китаплары һәм фотосурәтләре куелган.

***Фәйзрахманов Җәүдәт Ибраһим улы,***
*икътисад фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы*

***Файзрахманов Джаудат Ибрагимович,***
*доктор экономических наук, профессор, действительный член Академии наук Республики Татарстан*

*marat-kmn@yandex.ru*

УДК 398

*И.Г. Закирова*

# ФОЛЬКЛОРЧЫ ФЛОРА ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ

Статья посвящена научному творчеству татарского ученого-фольклориста Ф.В. Ахметовой-Урманче, обозначены главные направления ее научных исследований, актуальные для татарской фольклористики по сей день. Известному фольклористу, старшему научному сотруднику отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук РТ, кандидату филологических наук, лауреату Государственной премии им. Г. Тукая, заслуженному деятелю культуры Республики Татарстан Флоре Вагаповне Ахметовой-Урманче 23 мая 2025 года исполнилось бы 90 лет. Ф.В. Ахметова-Урманче является автором многочисленных статей, посвященных эпическому творчеству татарского народа. Особое место в научной деятельности ученой занимает работа по составлению и изданию томов «Дастаны» и «Баиты» академического свода татарского народного творчества.

**Ключевые слова:** Ф.В. Ахметова-Урманче, дастаны, татарский эпос, баиты, текстологическая работа.

The article is devoted to the scientific work of the famous Tatar scientist-folklorist F.V. Akhmetova-Urmanche, the main directions of her scientific research, relevant for Tatar folklore studies to this day are outlined. The famous folklorist, senior researcher of the folk art department of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, candidate of philological sciences, laureate of the State Prize named after G. Tukay, honored cultural figure of the Republic of Tatarstan Flora Vagapovna Akhmetova-Urmanche would have turned 90 on May 23, 2025. F.V. Akhmetova-Urmanche is the author of numerous articles devoted to the epic creativity of the Tatar people. A special place in the scientific work of F.V. Akhmetova is the work on the compilation and publication of the volumes "Dasans" and "Baity" of the academic collection of Tatar folk art.

**Keywords:** F.V. Akhmetova-Urmanche, dastans, Tatar epic, baits, textual work.

Дастаннарны җыю һәм өйрәнү буенча зур эш башкарган фольклорчы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Флора Әхмәтованың Татар фольклористикасы тарихында үз урыны бар. Быел эпос белгече Флора Әхмәтова-Урманчега 90 яшь тулыр иде. Мин Институтның халык иҗаты бүлегенә 1995 елда килдем, һәм без ун елдан артык Флора апа белән коллегалар булдык. Шуңа күрә бу мәкаләдә дә аны, үзенә эндәшкән вакыттагы кебек, Флора апа дип тә атыйм.

Флора Ваһап кызы Әхмәтова 1935 елның 23 маенда Төмән өлкәсенең Тубыл районы Күкрәнде авылында укытучы Габделваһап абзый гаиләсендә туа. Алар авылның хөрмәтле нәселләреннән берсе булып, әтисенең әтисе Туктабай да укымышлы кеше – мулла була.

Әтисе Габделвәһап бала чагыннан ук үзенең уйлау сәләте, башлы булуы белән бөтен авылдашларын шаккатыра. Флора апа сөйләве буенча, әтисе рус мәктәбендә белем ала, Троицкида 1915 елда ирләр өчен ачылган педагогик училищены тәмамлый. Троицкидан кайткач, ул укытучылык хезмәтен башлый, киң карашлы, заманы өчен тирән фикерле мөгаллим авыл балалаларына белем бирүгә үтә җитди карый. Әмма бу затлы кешенең тормышында да кара киртәләр корылган була. Тубыл Милли Шурасы рәисе итеп сайланган, халыкка киңәшкә килгән, авылдашлары ихтирам иткән Габделвәһап абзыйны Сталинның шәхес культы елларында кулга алалар. Ул төрмәдән Күкрәндегә – өенә каты авыру хәлдә, үләргә генә кайтарыла. Флора апаның әнисе тагын да иртәрәк дөнья куеп, кыз бала 8 яшендә тома ятим кала. Дүрт баланы әниләренең Фәрә исемле (Фәхриҗамал) туганнан туган сеңлесе үстерә. Үзе дә яшь, кияүгә дә чыкмаган кыз һәрберсен укыта, олы тормышка озата. Тубыл педагогия институтын сугыштан соң тәмамлаган абыйсы Әдипкә (1930 елгы) ияреп, Флора 6 нчы класстан соң Обь елгасы буендагы салкын-шыксыз Лабытнанги шәһәренә китә һәм рус мәктәбенә урнаша. Татар мәктәбеннән соң балага укуын русча дәвам итү дә, туганнарыннан читтә булу да бик авыр бирелә. Бер-ике айдан ул үзен кире Күкрәндегә кайтаруны сорый. Авылга кайтып, 7 класс бетереп – башта Тубыл татар педагогия училищесында, аннан соң Төмән педагогика институтында укый. Институтны тәмамлаганнан соң, Ханты-Манси округының Сургут районында балалар укыта.

Институтның 2021 елгы комплекслы экспедициясе вакытында Флора апа туып-үскән Күкрәнде авылында без дә булдык. Сазлыклар эчендә кечкенә генә утрау булып урнашкан бу авылга җәен – көймә белән, кышын боз өстеннән генә кереп була. Шуңа карамастан, авыл хәзер дә исән, телне һәм гореф-гадәтләрне саклап яшәвен дәвам итә. Күкрәндедә, Флора апаның әтисе һәм бертуганнары тырышлыгы белән, 1940 елда яңа мәктәп бинасы салына. Зур тәрәзәле, якты бу бина – хәзерге вакытта да эшләп торган мәктәп. Бина Әхмәтовлар проекты буенча салынган һәм яхшы уйланылганлыгы белән сокландыра. Һәр кабинет коридордан ягыла торган мич белән җылытыла, мич үзе эчке яктан күренми, салкын кышларда укучы көн дәвамында мич ягучыны да, утын ташучыны да күрми. Себер салкын кышлары белән мәгълүм булса да, биредә кояшлы көннәр дә күп. Аяз көннәрдә кабинетны зур тәрәзәләр аша кояш та җылыта. Гомумән, авыл тарихында да, мәктәп тарихында да Ваһап Әхмәтов һәм аның уллары-кызлары тирән эз калдыралар. Авылның тел-мәдәниятне саклап, бүгенгәчә яшәп килүендә шушы мәктәпнең, аның белән җитәкчелек иткән Әхмәтовларның роле зур булу беркемдә дә шик уятмый. Мәктәп ачылган көннән башлап, биредә эшләгән укытучылар – татар әдәбиятына, мәдәниятенә гашыйк шәхесләр. Алар укучыларда да туган телгә, әдәбиятка, халык иҗатына мәхәббәт уятырга тырышалар. Күкрәнде мәктәбендә язучы Якуб Зәнкиев математика укыта. Шушы

авыл, аның кешеләре әдипнең «Иртеш таңнары» романына да прототип булып кереп китәләр. Авыл халкы, туганнары Флора апаны җылы сүз белән искә алдылар. Ул бирегә туганнары белән очрашырга да, фольклор материаллары тупларга да еш кайта. Мәсәлән, Күкрәнде авылында Шәрифҗамал Халитовадан (1907 елгы), Кави Ибраһимовтан (1914 елгы), Зәкия Ильясовадан (1956 елгы) «Алыпмәмшән» дастанының вариантларын, Галимә Кәримовадан (1888 елгы) «Бүри хан» дастанынның вариантларын язып ала һәм фәнни әйләнешкә кертә.

Күкрәндедән чыгып киткән кызның урау юллар белән Казанга килеп төпләнүендә, соңрак тормышын фән белән бәйләвендә атаклы галимә, диалектолог Диләрә Гариф кызы Тумашеваның роле зур. Диләрә ханым чакыруы буенча, Флора аспирантурага укырга керә. 1968 елда «Фольклор һәм хәзерге татар прозасы» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклагач, ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фольклор секторында эшли башлый, халык иҗатын өйрәнү белән шөгыльләнә. Җырлы-дастанлы Себер ягыннан килгән кыз өчен филология фәненең бу өлкәсе аеруча якын була. Галимәнең исеме вакытлы матбугат битләрендә беренче тапкыр 1964 елда «Совет әдәбияты» журналында күренә. 1965 елдан газета-журналларда татар фольклорына багышланган мәкаләләре басыла башлый. Аның татар фольклористикасындагы дастан, бәет жанрларына, әдәбият һәм фольклор бәйләнешләрын яктыртуга багышланган мәкаләләре фәнни җыентыкларда, вакытлы матбугат битләрендә еш дөнья күрә.

Флора апа татар эпосын өйрәнүгә бөтен көчен куя. Ул 1976 елда Алма-Ата шәһәрендә узган тюркология конференциясендә татар фольклорындагы дастан жанры турында чыгыш ясый. Татар дастаннарын өйрәнүдә 30 елдан артыкка сузылган тынлыктан соң, 1978 елда эпоска багышланган «Дастаннар» дигән беренче күләмле мәкаләсе «Татар фольклоры жанрлары» җыентыгында басыла. Шул ук елда Элиста шәһәрендә узган конференциядә татар дастаннарын «Джангар» белән чагыштырма планда өйрәнеп, үзенең нәтиҗәләрен фәнни даирәгә тәкъдим итә, Якутск шәһәрендә узган конференциядә якут һәм татар эпик бәйләнешләрына туктала. 1979 елда Улан-Удэ шәһәрендә узган «Себер халыкларының эпик иҗаты» дигән фәнни конференциядә «Алпамыш» дастанының татар версиясе турында чыгыш ясый. Гомумән бу елларда ул СССР шәһәрләрендә узган конференцияләрдә актив катнаша. Чикләр ачылганнан соң, Флора апа татар фольклорын дөньяга танытуга да зур хезмәт куя. Татар дастаннарын өйрәнүгә багышланган мәкаләләре белән халыкара симпозиумнарда, чит илләрдә оештырылган фольклор форумнарында да катнаша. Мәсәлән, Америка фольклорчылары алдында (Мэдисон, 1990) татар халык иҗаты турында чыгыш ясый.

1984 елда «Татар халык иҗаты» академик җыентыгының Флора Әхмәтова төзегән «Дастаннар» томы дөнья күрә. Бу татар дастаннарын төрле архивлардан, кулъязмалардан һәм басма чыганаклардан

туплап чыгарган беренче җыентык һәм шактый еллар бердәнбер хезмәт була һәм тиз арада таралып бетә. Галимә әлеге җыентыкны, тулыландырып, 2004 елда «Татар эпосы. Дастаннар» дигән исем белән яңадан чыгара.

Татар фольклорының Флора апа өйрәнгән тагын бер юнәлеше – бәетләр. Ул «Татар халык иҗаты» академик томнарының «Бәетләр» томын төзүдә дә катнаша. Борынгы һәм Октябрьгә кадәрге чор бәетләрен туплап, томны И. Надиров һәм Л. Җамалетдинов белән бергәләп төзи. Соңрак әлеге томны тулыландырып, яңа кереш сүз һәм искәрмәләр белән «Татар эпосы. Бәетләр» җыентыгын (2001) бастыра. Флора апаның Себер татарлары фольклорын туплаган соңгы җыентыгы – «Джаным» дип исемләнгән антология – 2016 елда Мәскәүдә, аның вафатыннан соң, атаклы фольклор тәрҗемәчесе А.В. Преловский тырышлыгы белән дөнья күрә. Бу җыентыкларга Флора апаның Себернең төрле өлкәләрендә узган фольклор экспедицияләре вакытында язып алган дастан, бәет, әкият, җыр текстлары да кергән.

Галимәнең тагын бер фәнни эшчәнлеге гарәп язулы хезмәтләрне кирилл алфавитына күчереп, халыкка кайтару белән бәйле. Ул Рәшит Ибраһимовның «Дәүре галәм» һәм «Тәрҗемәи хәл» дигән хезмәтләрен кириллицага күчереп бастырып, халыкка бу шәхесне таныргa ярдәм итә.

Флора Әхмәтова – күренекле скульптор, рәссам Бакый Урманченың хатыны (сүз уңаеннан, ире аңа гомере буе Айгөл дип эндәшә). Ул Бакый ага белән ничек танышулары турында сөйләргә ярата иде. Алар 1966 елда Институт оештырган Халыкара конференциядә Флора апаның чыгышыннан соң танышалар. Бакый Урманче японкага охшаган кызны бик игътибар белән тыңлый. Рәссам аның күпсанлы портретларын гына язып калмый, беренче күрүеннән үзенең музасы итеп сайлап, аңа шигырьләрен дә багышлый.

Кафедрада бер кыз  
Тәнкәе ак, чәчкәйләре  
шомырт кара  
Күзләре, кашлары  
кара шундый,  
Йөзе тулган ай.  
Сокланып, сокланып карыйм.  
Татар фольклоры хакында сүз бара.  
Үзе фольклор бу,  
Үзе халык җыры, үзе дастан,  
Сөбхан, сөбхан, сөбхан!

Бу урында Флора апаның тагын бер сәләтен искә төшермәсәк, мәкалә тулы булмас иде. Ул бик матур җырлый, һәм бу сыйфаты белән халык иҗаты бүлеге мәҗлесләренең күрке була иде. Һәр бәйрәмдә фольклорчылар Флора ападан «Кара елан» җырын җырлаталар. Татар дастаннары көйләре-назымнарны да Флора апа кебек башка-

ручы сирәк булгандыр. Бу көйләр хәзер дә Флора апа белән Бакый Урманче язмаларында саклана. Флора ханым рәссам һәм скульптор Бакый Урманче иҗатын популярлаштырып, бу бөек шәхеснең иҗатына багышланган өч альбом әзерли, 1999 елда рәссамның шәхси музеен ача. Музей фондын да Флора апа үзе туплый. Мемориаль комплекс һәм сәнгать күргәзмәсе принципларын берләштергән әлеге музейда останың иҗади эшчәнлегенең барлык якларын күзалларга мөмкинлек биргән экспонатлар – шәхси әйберләре, йортыннан һәм остаханәсеннән җиһазлар, һәм, әлбәттә, картиналар, графика һәм Б. Урманче иҗат иткән мәрмәр сыннар һәм скульптуралар урын алган. Б. Урманченың иҗат мирасының төп өлеше шушы музейда саклана.

Аларның уллары Айдар хәзерге вакытта, әтисеннән алган сәләтен дә кушып, уникаль агач эшләнмәләр җитештерү белән шөгыльләнә.

Язмамны Бакый Урманченың икесенең дә эшчәнлегенә бәя биргән шигыре белән тәмамлыйсы килә:

Айгөл генәсе,
Җиһанның бер генәсе.
Гомеремнең бизәге,
Рәхәте син генәсе.
Икебез дә без – дәрвишләр,
Хыял, сәнгать – нәни генә безнең эшләр.

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

***Закирова Ильсеяр Гамиловна,***
*доктор филологических наук, главный научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

*ilzakirova@mail.ru*

УДК 811(=512.145)

***И.Б. Бәширова***

# «ӘДӘБИ ТЕЛ ТАРИХЫ – АНЫҢ СТИЛЬЛӘРЕ ТАРИХЫ»
## *(Латыйф Җәләйнең тууына 130 ел тулу уңаеннан)*

Статья посвящена 130-летию со дня рождения доктора филологических наук, профессора Латифа Заляя. Автор исследования описывает научные достижения ученого, подчеркивая их актуальность и в настоящее время. Научная деятельность исследователя многогранна: он определяет понятие история татарского литературного языка, анализирует историю его стилей, поясняет сущность понятий стиль и стилистика. Л. Заляй научно обосновывает теорию стилистики – это отрасль науки, изучающая неодинаковые для разных условий языкового общения принципы выбора и способы организации языковых единиц. По мнению ученого, сформировавшийся литературный язык делится на пять стилей. Он, перечисляя стили татарского литературного языка середины XX века, выделяет присущие им термины, объясняет их историю. Исследователь отмечает, что практическая стилистика и практическая грамматика имеют общую основу, но при этом делает акцент на том, что их функциональные задачи различаются. Также Л. Заляй ведет научную деятельность по таким направлениям, как история татарского языка, татарская грамматика, татарская диалектология. Он защищает кандидатскую и докторскую диссертации, долгие годы читает лекции студентам, пишет рецензии на литературные произведения, написанные в разных жанрах. В этой статье, опираясь на теоретические обобщения Л. Заляя, определяются стили, сформировавшиеся в истории татарского литературного языка. Здесь впервые высказывается мысль, что до художественного стиля в традициях богословского учения существовал стиль, который автором статьи определяется, как художественный божественный / духовный / человеческий стиль.

**Ключевые слова:** Латиф Залялетдинович Заляй, история татарского литературного языка, стиль, стилистика, функциональный язык, функциональные стили.

The article is dedicated to the 130th anniversary of the birth of Doctor of Philology, Professor Latif Zalyai. The author of the study describes the scientific achievements of the scientist, emphasizing their relevance today. The researcher's scientific activity is multifaceted: he defines the concept of the history of the Tatar literary language, analyzes the history of its styles, explains the essence of the concepts of style and stylistics. L. Zalyai scientifically substantiates the theory of stylistics – this is a branch of science that studies the principles of choice and methods of organizing language units that are different for different conditions of language communication. According to the scientist, the formed literary language is divided into five styles. Listing the styles of the Tatar literary language of the mid-twentieth century, he highlights the terms inherent in them, explains their history. The researcher notes that practical stylistics and practical grammar have a common basis, but at the same time emphasizes that their functional tasks are different. L. Zalyai also conducts research in such areas as the history of the Tatar language, Tatar grammar, and Tatar dialectology. He defends his candidate and doctoral dissertations, has been lecturing to students for many years and writing reviews of literary works written in various

genres. In this article, based on L. Zalyai's theoretical generalizations, the styles that have formed in the history of the Tatar literary language are defined. Here, for the first time, the idea is expressed that before the artistic style in the traditions of theological teaching, there was a style that the author of the article defines as an artistic divine / spiritual / human style.

**Keywords:** Latif Zalyaletdinovich Zalyai, history of the Tatar literary language, style, stylistics, functional language, functional styles.

Бу мәкалә татар тел белемендә беренче фән докторы, төрки дөньяда танылган галим, киңкырлы уку-укыту эше белән шөгыльләнгән профессор-педагог Латыйф Җәләлетдин улы Җәләлетдиновның (Л. Җәләй) тууына 130 ел тулу мөнәсәбәте белән языла. Л. Җәләй 1894 елның 17 ноябрендә Ульяновск өлкәсе Кече Кандал районы Иске Кызыл Су (русча: Тат. Урайкино) авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Башта авыл мәктәбендә укый, 1906 елдан Мәләкәс мәдрәсәсендә белем ала, 1912 елдан укытучылык эшенә керешә.

1915 елда Л. Җәләй солдатка алына, сугышта контузияләнә, госпитальдән чыккач, яңадан фронтка китә. Февраль революциясен – Румыниядә, Октябрь революциясен туган авылында каршылый. Укыту белән шөгыльләнә, төрле өязләрдә мәгариф бүлегендә эшли. 1929–1931 елларда башта Кузнецк шәһәрендә, аннан Мәләкәстәге партия мәктәбендә татар теле укыта, Самара педагогия институты каршындагы аспирантурага керә.

1933 елда Л. Җәләй Казанга килеп, педагогия институты каршындагы аспирантурада укуын дәвам итә. 1935 елда аны тәмамлый һәм шунда ук эшкә дә калдырыла: әдәби тел тарихы, тарихи грамматика һәм диалектология курсларын алып бара. Шуның белән бергә, яшь әдипләрнең беренче хикәяләренә рецензияләр язуын дәвам иткән хәлдә [5], стилистика дип башлана торган берничә мәкалә яза: «Стилистика һәм әсәрнең композициясе. Тәрҗемәчеләр белән укыр өчен бер курс (1934, 36 б.); «Стилистика һәм гомуми тел белеме буенча язмалар» (1935, 38 б.). Мәкаләләр Яңалифтә ныклы система-план белән язылган. Башта «Стиль – тар һәм гади мәгънәдә алганда, «форма-рәвеш», ягъни эш яки предмет-әйбер формасы. Мәсәлән, иптәш Сталинның «Эштә Ленин стиле» дигән тәгъбире кулланыла. Бу бина яңа стильдә салынган. Бу кешенең сөйләү стилендә борынгылык чагыла» һ. б. мисаллар ярдәмендә стиль төшенчәсенең мәгънәсе аңлатыла. Аннан соң «Стиль сүзе борынгы римлыларда кискеч, кыргыч, кинжал, каләм мәгънәсендә кулланыла. Стиль – балавызлы тактага язу коралы. Соңыннан язу формасы, язу алымы төшенчәсенә күчә. Гомумән, фикер тәгъбире формасы. Пушкин һәм Лермонтов стильне кинжал мәгънәсендә кулланалар», дип, әлеге сүзмәгънәнең тарихи үзгәреше күзаллана. Автор үз чоры идеологиясенә туры китереп, бу сүзнең социаль мәгънәсе һәм аңа карата фикерләр бар дип, «Буржуазия стильне индивидуальләштерә, димәк, стильнең сыйнфыйлыгын, аның экономик сәбәпләр, сыйныфлар көрәше белән нык

бәйләнештә һәм шушы нигездә үсүен карамый. ...Марксизм каршында, стиль сыйнфый. Иптәш Сталинның «Эштә Ленин стиле» дигән мәкаләсе бар. Буржуазиядә – коры практивизм. Революциядә – революцион теория һәм революцион практика» дип, буржуазия һәм марксизм карашының терминда ничек чагылышы аңлатыла: «Димәк, а) стиль – ул бер әдәбият, телгә караган нәрсә генә түгел, ә) стиль – ул сыйныфның яшәү, көрәш, үз интересларын яклауда кулланылган алым үзенчәлекләреннән тора», дип нәтиҗә ясала. Аннан соң, стилистика дигән фән тармагының максат-бурычы билгеләнә: «Беренчедән, стильнең әдәбиятта, фәнни, политик, художество һәм йомышлы әдәбият күзлегеннән карап алынган төшенчә булуын күрәбез. Стилистика – ул әдәбиятта кулланыла, стиль турында белем дигән сүз. Димәк, без хәзер стильдә тел фактларының сөйләм практикасына карата кулланылыш функциясен күрәбез» [6]. Шулай итеп, татар тел белемендә беренче мәртәбә стилистика дип атала торган фән тармагының предметы / табигате һәм вазифасы билгеләнә: стилистика – ул, тел берәмлекләренең сөйләм барлыкка китерү үзенчәлеген тикшерә торган фән тармагы. Стилистиканың әлеге максатын Л. Җәләй үзенең «Практик стилистика алдында торган төп бурычлар» дигән мәкаләсендә тәгаенли: аның практик грамматика белән охшаш һәм аермалы якларын күрсәтә. «...Практик стилистиканы практик грамматика белән һичбер вакытта да алмаштырырга ярамый. Уртаклык һәр икесенең дә тел-сөйләм чараларының бер үк объектлары... өстендә эшләүләреннән гыйбарәт. Аерма – объектларны үзләренчә ачыклауларында. Мәсәлән, грамматикада тел-сөйләм практикасындагы фактлар (авазлар, сүзләр, җөмләләр) билгеле нормаларга салына, ...эчтәлек һәм форма берлеге ягыннан билгеләнә; практик стилистикада шул ук объектларның ...стиль-сайлау культурасы ягыннан ятымлырак, төшенчә, уй-фикерләр бирүдә баерак булулары мәсьәләсе, ягъни художество, эмоция ягыннан эшләнеш формалары күзәтелә» [7]. Димәк, әлеге мәсьәлә истә тотылмыйча, морфологик кушымчаның стилистик кулланылышы дип өйрәнелгән очракта, практик грамматика турында сөйләгән булабыз. Аңлашылганча, стилистика дип өйрәнгәндә, тел берәмлеге тоташ сөйләм (җөмлә) эчендә, стиль-сайлау культурасы ягыннан карап анализлана. Шулай итеп, XX гасырның 30 нчы еллары уртасында, татар тел белемендә беренче мәртәбә стилистика дип аталган фән тармагының үзенә хас табигате һәм вазифасы билгеләнә, теориясе һәм практик нигезе ассызыклана. Алга таба әлеге мәсьәләләр «Сурәтләү чарасы булучылыкта җөмләнең аерымланган кисәкләре» [8], «Әдәби телне өйрәник....!» [9], «Татар теле әдәби теле туу мәсьәләсенә карата» мәкаләләрендә [10] төрле яклап яктыртыла.

Л. Җәләйнең бу еллардагы һәм алдагы чорлардагы эшчәнлеген күзәтү барышында, стилистика тармагы өйрәнелә башлау белән бергә, татар теле тарихы, диалектология, тарихи грамматика һәм әдәби тел тарихы өлкәләренә караган фәнни юнәлешнең дәвам иттерелүе күренә. «Татар теле тарихына карата кайбер материаллар» дигән

хезмәтен галим 1938 елда кандидатлык диссертациясе итеп яклый. Казан педагогия институтында укытучылык эшен дәвам иткән хәлдә, 1939 елдан Татарстан Мәгариф халык комиссариаты карамагындагы Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институтында (хәзерге Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) эшли башлый. 1956 елдан 1962 елга кадәр Тел бүлеге җитәкчесе вазифасын башкара. Бер үк вакытта Казан дәүләт университетында Татар теле һәм әдәбияты бүлеген оештыруда да актив катнаша, анда диалектология һәм тел тарихы курсларын алып бара. 1938 елда басылган «Татар телендә диалектлар» дигән мәкаләсендә нигезләнгән фикерләре гомумиләштерелеп, системага салына, 1947 елда «Татар диалектологиясе» дигән дәреслеге дөнья күрә. 1955 елда «Татар теленең урта диалекты турында монография» дигән хезмәте докторлык диссертациясе булып яклана. Академик Н.К. Дмитриев тарафыннан ул: «Безнең алда татар фәнендә әле моңарчы күрелмәгән грандиоз хезмәт, һәм бу Сөембикә манарасыдай һәйкәлгә автор үзенең бөтен яшьлеген, кыю һәм иҗади эзләнүләренең бөтен ялкынын салган» [4], дип бәяләнә.

Бу елларда Л. Җәләйнең әдәби тел турында язылган мәкаләләренең бер өлеше басылган [8; 9; 10], кайберләре басылмый калган: «Татар әдәби теле тарихы тармагыннан тикшеренүләр. «Әдәби тел» төшенчәсе» (1954–1955, 19 б.); «Болгар-татар чоры әдәби телендәге төп стильләр (1958, 84 б.) һ. б.

Казан дәүләт университетында «Татар диалектологиясе», «Татар теленең тарихи грамматикасы», «Татар әдәби теле тарихы» һәм «Татар әдәби теленең стильләре» дигән махсус курслар буенча лекцияләр укыганда, мәкаләләрендә язма стиль таләп иткәнчә бирелгән фикерләрен сөйләм телендә тәгаенләп җиткергәнлеге аңлашыла. Мәсәлән, «Әдәби телне өйрәник!» мәкаләсендәге «Әдәби тел, гомумхалык теленә нигезләнгән килеш, шушы халыкның җәмәгатьчелек фикере, психологиясе, тормышны таныпбелүе, культурасы формалашу процессында туган, камилләшкән һәм фәнни, әдәби эшкәртелгән стильләр суммасыннан тора», дигән фикере лекциясендә түбәндәгечә әйтелә: «Әдәби тел нигезендә ничә багана торырга тиеш соң? Беренчедән, әлеге тарихны туа башлаган чорыннан ук өйрәнергә кирәк, гадәттә XVI–XVIII йөзләрдән башлап кына тикшерелә; икенчедән, халыкның экономикасы төзелү белән бәйләп өйрәнелергә тиеш, телне тормыштан аерырга ярамый; өченчедән, әдәби телнең күрсәткече – язу, шуңа күрә ул язу тарихы белән бергә алып барылырга тиеш; дүртенчедән, халыкларның гомуми телләре формалашуда диалектларның үсеше зур урын алып тора, шул үсешнең тарихы исәпкә алынырга тиеш; бишенчедән, әдәби телнең гомумхалык теленнән аермасы – стиль булуда, ул – стильләр тарихы». Сүз уңаеннан, «функциональ тел» төшенчәсенә дә мөнәсәбәт белдерелә: «...кайбер халыклар, сөйләштә үз телләре булса да, әдәби тел рәвешендә икенче халык телен йөрткәннәр. Европа халыкларында шундый тел борынгы латин теле

була. Татар теле тарихында гарәп теле тулаем әдәби тел функциясен үтәми, мәчет әдәби теле булып кала: намаз гарәпчә укыла. Аерым галимнәр китапларын гарәп телендә язганнар. Дини китаплар да гарәпчә генә түгел, күбрәк татарча да язылган, динне халыкка тизрәк җиткерү өчен...» (шәхси архивтан. – *И.Б.).* Мин дә Л. Җәләйнең лекцияләрен тыңлаган бәхетле кешеләрнең берсе булдым.

«Татар әдәби теленең стильләре» дигән лекциясендә, профессор Л. Җәләй: «Формалашып җиткән әдәби тел биш стильгә бүленә, аларның һәрберсенең тарихы бар», – дип, түбәндәге сөйләм стильләрен күрсәтә: сәнгатьчә әдәбият стиле, фәнни һәм фәнни-популяр әдәбият стиле (гыйльми әсәрләр теле стиле), публицистика (иҗтимагый-политик темаларга караган) стиле, йомышлы (эш кәгазьләре) стиле, хатлар язу стиле. Алга таба һәр стильнең үзенчәлеге, билгеле бер дәрәҗәдә тарихы күзаллана. Мәсәлән, фәнни әдәбият стилендә кулланылган термин төшенчәсе турында мәгълүмат бирелә: «Термин – борынгы латин сүзе – чик, граница, предел, чик саклый торган Алла. Ул бер таш була. Хәзер сүзгә күчкән. Терминнар – синонимнары булмаган сүзләр. Борынгы әдәбиятта истыйлах дип йөртелгән. К. Насыйри шулай ди. Һәрбер әдәби телдәге терминнар ике төркемгә бүленә: а) үзьяшәешле (самобытные термины) – һәр телнең үз материалы, татарча: адым, колач, өчаяк һ. б.; б) алынмалар: бездәге тәм, гарәп теленең тәгам – аш, ашамлык сүзеннән; сәләт – сәляхият сүзеннән һ. б. Иң борынгы алынмалар Кытайдан булырга кирәк, төрки халыклар алар белән элемтәдә торалар: креп-де-шин – кытай материалы; апил-син – кытай алмасы, кувшин – күкшин, куыкшин – кытай куыгы һ. б. Кытайлар һәрбер алынма сүзне үз телләренә яраштырып, үз кагыйдәләренә туры китереп үзгәртә торган булганнар. Икенче төркем – фин-угорлардан (кызганыч, мисаллар язылмаган). Өченче катлам фарсыдан килә, боларның күбесе сәүдәгә карый һәм кеше исемнәре: Сөмбел, Маһинур, Маһруй. Көн исемнәре дә фарсыдан: шинбә – көн; якьшәнбә – беренче көн; дүшәмбә – икенче көн; сиһшәнбә – сишәмбе – атнаның өченче көне, буш көн; чәһаршәнбә – чәршәмбе – дүртенче көн; пәнҗәшәнбә – бишенче көн; җомга (монысы гарәп теле сүзе) – атнаның алтынчы көне исеме. Дүртенче катлам – гарәп теленнән кергән алынмалар: дин, ишан, мәсҗид – мәчет, гөнаһ, мөэмин, мөселман, сәяхәт, каләм һ. б. Бишенче катлам – рус теленнән алынган, күбесе хуҗалыкка карый: XIII йөздән – пич, ызба; XVIII йөздән – печать һ. б.

Эш кәгазьләре стиле болай дип аңлатыла башлый: «Бу стильгә конкретлык хас, аны бизәкләү кирәкми. Беркетмә язганда шигырь кыстыру кирәкми. Бу стиль шаблонга корылган, доклад, чыгыш әкият дип аталмый. Татар тарихында ташъязмалар булган, ярлыклар булган. Алар халык телендә язылган, уйгур әлифбасында язылганнары да бар (шәхси архивтан. – *И.Б.*) Гомумтөркигә караган V–VIII гасыр Орхон-Енисей, Күлтәгин, Тоньюкук ташъязмаларыннан алынган күпсанлы мисалларны автор «Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар)» хезмәтендә һәр сүз төркемен аңлатканда файдалана [11].

Беренче күрсәтелгән сәнгатьчә әдәбият стиленә тарихи планда соңыннан гына игътибар ителә. 1) Язма тел һәм сөйләмә тел мөнәсәбәте хакында әйтелгән төрле фикерләр китерелә, аларның аермасы искәртелә: сөйләм ат кебек чаба, ә язма тел җәяүләп кенә бара, кем дә кем сөйләшкәнчә язса, хәтта үтә оста сүзле кеше булса да, ул – надан кеше. А.С. Пушкин болай дигән: «Язу теле сөйләү теленә нигез була алмый». Язу теле сөйләү теленнән алынган тәгъбирләр белән җанландырыла. Сөйләшү теле белән генә язу, язуны (телне) белмәү дигән сүз. Язу теле сөйләшү теленә генә тәңгәл була алмый, – дип, Л. Җәләй кайбер әдипләрнең әсәрләреннән алынган мисалларны анализлый: «Бездә сөю һәм ярату бар. Бәрәңге яратам, ләкин сөям түгел. Болай дигән кеше татар булмый. Руста барысы да любить. Ярату – кешенең тышкы дөнья белән мөнәсәбәте, интим нәрсә түгел. Сөю-психологик эчке дөнья: ата-ана сөюе. Бездә матурлык төшенчәсенә йөри торган 20–25 сүз бар, ә монда бер абзацта – 4 тапкыр матур, 3 мәртәбә – пычрак, өчесе дә урынсыз...», – дип, яшь язучы Р. Ишморатованың хикәяләрендәге сүз кулланылышын күздән кичерә (Шәхси архивтан. – *И.Б.*).

Г. Бәширов, А. Шамов, Н. Исәнбәт, Ә. Исхак, К. Нәҗми, Ш. Камал әсәрләренең теленә карата мактау сүзләре әйтелү белән бергә, мәкалә итеп бастырганда, җитешсезлекләр дә күрсәтелә. Г. Бәшировның «Сиваш» повестена җентекле анализ ясап, болай дип яза: «Поэтик синтаксис таләпләре ягыннан килгәндә исә, бу өзектә бер кимчелек бар. Өченче җөмлә белән дүртенче җөмләне автор аерым-аерым үзбаш итеп куйган, минемчә, боларны тезмә кушма җөмләне каршы кую формасында бирү тарихны тулырак чагылдырыр иде, ... “бу чакта” сүзен ташларга, ягъни экономия ясарга да мөмкин булыр иде», – дип, башка җөмләләрне анализлагач, «Разин иптәшнең абайсызланып, һәм шуның аркасында, поэтик синтаксис таләпләрен бозып, монотоник бер алым биреп, кушма җөмләнең затын китәрүенә мисал булып тора. ...Мин уйлыйм... “-тан-тән, -ганда-гәндәләр” белән дыңдырдап торган монотоник аһәңсез, уйгынлык һәм тойгынлыкка кимчелек китерә торган сүзләр тезмәсен ташлаган һәм икенче вариантта биргән булыр иде» [13]. Шул рәвешле, «Үч» җыентыгындагы хикәяләренең һәр җөмләсе диярлек анализлана [14]. Г. Бәшировның, «Намус» романы турында авторга язган хатында болай диелә: «Менә инде моннан соң сәнгатьчә пешүе килмәгән әсәр язучыларның базары бетте. Моннан соң начар әсәр язарга ярамый, чөнки “Намус”ны укып, халыкның зәвыгы үсәчәк. ...Синең “Намус”ың татарны роман укырга өйрәтте. Бу – һичкем тана алмаслык тарихи факт» [15].

Шулай итеп, Сәнгатьчә әдәбият стиленең тарихы дигәндә, әдәби телнең сөйләмә һәм язма формаларда була алуы хакында кыскача мәгълүмат бирелә. Үзенең чордашы булган Г. Бәширов, А. Шамов, Н. Исәнбәт, К. Нәҗми, һ. б. әдипләрнең әсәрләре өйрәнелү уңаеннан, авторның аерым сүзләрне ничек куллануын күзәтү белән бергә, җөмлә төзелеше үзенчәлегенә игътибар итү зарурлыгына да басым ясала.

Әдәбиятның сәнгатьчәлеген, ягъни әсәрнең нәфислеген, әдәбилеген тикшергәндә, аңа укучының зәвыгын үстерү ягыннан карап, тулаем анализ ясарга кирәклеккә игътибар ителә.

Шуның белән бергә, Л. Җәләй үз вакытында «Тукай телендә фигыльләр» дигән мәкаләсендә: «Тукай телен өйрәнү – татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычын өйрәнү, дигән сүз. Кешелек дөньясы барлыкка китергән культура байлыгын тәнкыйть үтәзеннән сөзеп алмый торып, яңаны төзеп булмый. ...Тукай телен өйрәнүне теоретик нигезләү хәзерге телдәге бик күп мәсьәләләрне һәм фәнни, һәм практик яктыртуга мөмкинлек бирәчәк», дип, сүз белән сурәт ясау мөмкинлегенә тарихи нигездән карарга кирәклеген искәртә [12: 84–103]. Бу контекстан, Тукай телен анализлагандагы кебек, башка әдип, шагыйрьләрнең иҗатына да, «татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычын өйрәнү дип» якын килү сорала.

Татар язма теле баскычларының башлангычы гомумтюркологик хезмәттә билгеләнә. «Языки мира. Тюркские языки» энциклопедик басмасында, төрки телләр гаиләсендәге 15 борынгы һәм 39 хәзерге халык теленең язмачылык тарихы V–VI, XIII–IX, X–XII йөзләрдә башланып, XII–XIII йөздән үз дәүләтендә язылган истәлекнең язылу датасы билгеле булган иске язулы телләр (старописьменные языки) дигәндә, азәрбайҗан, төрек, төрекмән, уйгур, үзбәк телләре белән рәттән, татар теле дә санала [33]. Язма истәлек дигәндә, Идел Буе Болгар дәүләтендә Кол Гали тарафыннан 1233 елда сәнгатьчә югарылыкта иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» поэмасы истә тотыла. Димәк, Кол Галинең, үлемсез әсәре белән, халкыбызны иске язулы телләр рәтендә раслаткан мәшһүр шәхес булуын да онытырга ярамый.

Татар әдәби теле тарихының XIII йөздән башлап өйрәнелүе уңаеннан шуны әйтергә кирәк: иске язулы телләр әдәби язма тел нормасына нигезләнә, алга таба норма традиция буларак дәвам иттерелә, аерым дәүләттә (төбәктә) яшәүчеләрнең сөйләм телләре белән баетылу язма норманың төрле вариантлар белән кулланылуына китерә [25: 10–17]. Бу яктан караганда, остазыбыз Л. Җәләйнең сәнгатьчә әдәбият стиле дип аңлатыла торган күренешне XX гасырның 30–40 нчы елларында иҗат ителгән аерым проза әсәрләрен санап-анализлап кына күзалларга тырышуы тарихи объектив дөреслеккә туры килеп бетми. Мәдрәсәдә дини гыйлем алган Л. Җәләй сәнгатьчә әдәбият стилен «татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычы» дип караганда, аның башка стильләрдән аерыла торган үз тарихы булуын, бу тарихның бисмилләһир-рахманир-рәхим дип, Аллаһы Тәгаләне гүзәл атамалары белән мактап, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмне зурлап, ягъни Илаһият тәгълиматы традициясендә башлануын яхшы белсә дә, бу хакта сүз кузгата алмый. Чөнки татар халкының, аның теле, әдәбияты, мәдәниятенең тарихы бар дип расларга тырышкан Бертуган Шәрәфләр, Г. Рәхим, Г. Газиз, С. Вахиди, Җ. Вәлиди, С. Җәләл, Г. Ибраһимов һ. б. ның фаҗигалы язмышка дучар ителүенә үзе дә шаһит була.

XX гасырның соңгы елларында гына, иҗтимагый-сәяси хәлләргә объектив дөреслек күзлегеннән мөнәсәбәт белдерү мөмкинлеге ачылгач, төрки-татар әдәбиятында барлык жанрларның да, гасырлар буена Илаһият тәгълиматына нигезләнгән иҗади традициядә, дөньяви чынбарлыкның тасвирлануы белән яңартылып, сәнгатьчә эшчәнлек бару турында фикер кузгатыла, хезмәтләр языла башлый. Казан дәүләт университетында гарәп теле укыткан Ж.Г. Зәйнуллинның «XVIII – XX йөз башында татар рухани әдәбияты: Коръән тәфсирләре, хәдисләр һ. б. чыганаклар. Тәрҗемә принциплары һәм тел үзенчәлекләре» дигән хезмәте дөнья күрә [16]. «Рухани әдәбият татар мәдәниятенең зур һәм гаять әһәмиятле бер катламын тәшкил итә. Берничә гасыр дәвамында тудырылган дини эчтәлекле тәрҗемә әсәрләр – «Коръән тәфсирләре, хәдисләр, шәрехләүләр), дин фәлсәфәсе өлкәсендә эшләгән күренекле галимнәребезнең кыйммәтле мирасы, дин гамәлләре, дини тәрбия һәм үгет-нәсыйхәт эчтәлекле күпсанлы китаплар һ. б. бүгенге көнгә кадәр өйрәнелмәгән хәлдә кала килә», – дип яза галим. Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен чыгарылган «Татар стилистикасының теоретик нигезләре» дигән программа-кулланмада татар әдәби теленең Л. Җәләй санаган гамәлдәге биш стиленә алтынчысы – дини-дидактик стиль өстәлә; аның башка стильләрдән үзенә генә хас табигате һәм вазифасы белән аерымлануы билгеләнә [2: 21–25].

Иң мөһиме, XXI гасырның беренче унъеллыгында сигез томлы «Татар әдәбияты тарихы» академик басмасы аның төзүчесе һәм җаваплы мөхәррире Р.Ф. Рахманиның: «...Фәлсәфи яктан материалистик, атеистик, большевистик идеологиягә хезмәт иткән әсәрләрне генә алга чыгарып, психологик тирәнлекләргә төшмичә, әдәби әсәрләрне барлауда, нигездә, штамп фикергә иллюстрация эзләү белән чикләнеп, без аң һәм җан яшәешен, эстетик үсешебезне таш диварга китереп терәдек, чөнки ике мең еллык әдәби ядкярләребез, – асылда, тулаем ачык иманлы, дини карашлар белән камил үрелгән югары сәнгатьле рухи хәзинә», – дигән фикерләре белән башланып китә [29]. Татар әдәби теле тарихын өйрәнү барышыннан күренгәнчә, Илаһият тәгълиматына нигезләнгән иҗади традициядә автор аңында эстетик кабул ителгән дөньяви чынбарлыкның, максатка туры китерелгән нәфис сүз-сурәтләр белән тасвирлы яңартылган сәнгатьчә эшчәнлек буларак, гасырлар буена дәвам итүе аңлашыла. Әлеге мәсьәләләрнең, танылган телче һәм әдәбиятчы галимнәребез тарафыннан җентекләп өйрәнелеп, укучыларга тәкъдим ителүе мәгълүм. Аларның фикерләрен зиһендә тоткан хәлдә, остазыбыз Л. Җәләй белдергәнчә, «татар әдәби теле тарихы – аның стильләре тарихы ул» дип тикшерү барганда, бу юнәлештәге катлаулы проблемаларны хосусый фән кысасында, ныклы системада күзаллау өчен, язма текстларны, аерым стильләргә бүлеп, махсус аңлату көтелә.

Әйтеп үтелгәнчә, тарихи яссылыкта караганда, сәнгатьчә әдәбият стиленә хас үзенчәлек XX йөзнең 40–60 нчы елларында язылган әдә-

би әсәрләрне өйрәнү белән генә билгеләнә алмый. XII–XIII йөзләрдән татар әдәби теленең сәнгатьчә әдәбият стилендәге колачын, табигатен һәм вазифасын күзаллау өчен, татар әдәбияты тарихында «тулаем ачык иманлы, дини карашлар белән камил үрелгән югары сәнгатьле рухи хәзинә» булган язма истәлекләребезнең үзенчә формалашкан жанр төрләрендә илаһият тәгълиматы нигезендә сәнгатьчә сурәтләнүен тулаем зиһенгә алып тикшерергә, заманасына карап, яңарышны билгеләргә кирәк.

Сүз уңаеннан, сәнгатьчә әдәбият стиле дигәндә, хосусый терминның тәгаенләнгән мәгънәсен искә төшерү сорала. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә:

**Сәнгать**- и. 1. Иҗтимагый аңның чынбарлыкны нәфис образлар аша чагылдыра торган формасы; дөньяны эстетик танып белү. 2. Иҗади эшчәнлекнең бер төре: чынбарлыкны нәфис образлар аша сурәтләп бирү иҗаты [30].

Димәк, сәнгатьчә әдәбият дигәндә, чынбарлыкны, ягъни адәм баласын чолгап алган табигатьне, тормыш-көнкүрештәге яшәешне, эчтәлеге һәм формасы ягыннан эстетик категорияләр халәтендә күзаллау, мөнәсәбәт белдерү һәм нәфис, гүзәл образ-сүз-сурәтләр белән сәнгатьчә иҗат ителгән әдәби әсәрне күздә тотабыз.

Иҗади эшчәнлекнең бер төре булуы истә тотылып, Л. Җәләй сәнгатьчә әдәбият стиле дигән төшенчәне аның шәкертләре сәнгатьле сөйләм / матур әдәбият стиле дип кулланалар [22: 45]; Матур әдәбият теле / сәнгатьле сөйләм / матур әдәбият стиле дип, бер үк төшенчәне тел, сөйләм, стиль сүзләре белән аңлаталар [31: 219]. Бу уңайдан укытучыбыз Л. Җәләйнең: «Әдәб – гарәп сүзе, тәртипле, тәрбияле; әдиб / әдип – нәфис әсәрләр язучы; әдәбият сүзе дә шул ук тамырдан килеп чыккан – матур калыпка салынган тел; матур әдәбият дигәндә, матур сүзе артык, матур-матур / красивая литература була. Наданлык нишләтми ул, мөгез булып чыкса, татар башы мөгездән генә торыр иде», – дигән фикере дә хәтердә. Әмма кулланышта матур әдәбият стиле дигән атама тотрыклылана.

Сәнгать сүзеннән аермалы буларак, стиль – күп мәгънә белдерә торган төшенчә [30: 672]. Татар филологиясендә аны беренче мәртәбә Казан университетының төрек-татар кафедрасы профессоры Н.Ф. Катанов «Материалы к изучению Казанско-татарского наречия» хезмәтендә куллана. «Образцы книжной и устной литературы Казанских татар» бүлегенең керешен болай дип башлый: «В Казани лишь в последнее время стал вырабатываться особый стиль: одни (А.К. Насыров, А.А. Фейзъханов) стали употреблять слова своего и др. языков с коренными казанско-татар. грамматич. формами, а другие (А.Г. Максутов) стали употреблять современный турецкий язык. Оба направления обращаются за словами к языкам араб. и персид., даже тогда, когда есть свои татар. слова» [19: 4]. Автор стиль терминының теориясен аңлатмый, ә М. Ломоносов хезмәтеннән алып куллана. Н.Ф. Катанов әйткән бу фикер, беренчедән, үз вакытында С. Кукляшев («Язма татар

теле өч төргә – гади (простой), эш (деловой), гыйльми (ученый) телгә бүленә» [21: 3] һәм К. Насыйри [23] хезмәтләрендә күзәтелә, әмма «тел» дип аталган күренеш «стиль» дигән яңа термин белән кабатлап әйтелә. Икенчедән, төрки-татар телендә язылган әдәбиятта җанлы сөйләмә тел берәмлекләре белән бергә гарәп һәм фарсы алынмалары да XII–XIII гасырларда язылган текстларда ук инде иркен кулланылган, әлеге нигездә язма телнең аристократ-абруйлы һәм халыкчан сөйләмә дип кулланылуы билгеләнгән була һәм бу юнәлештәге өйрәнүләр алга таба да дәвам иттерелә [25: 105–12].

Татар язма әдәби теленең X–XIII гасырлардан башланган тарихын өйрәнү барышында, сәнгатьчә әдәбият стиленең дә, әдәби телнең башка стильләре кебек үк, дәверләр буена эзлекле рәвештә дәвам итеп килгән төрки-татар язмачылык тарихының буеннан-буена «чынбарлыкны нәфис образлар аша сурәтләп бирү иҗаты» буларак барлыкка килеп, катлаулы үсеш процесында формалашуы күренә. Татар әдәби теле тарихын, аның стильләре тарихы дип, эзлекле рәвештә өйрәнгәндә, Л. Җәләй тарафыннан әдәби телнең беренче стиле дип билгеләнгән сәнгатьчә әдәбият стиленә кадәр сәнгатьчә иҗади эшчәнлекнең, Илаһият тәгълиматына нигезләнеп сәнгатьчә илаһи / рухани әдәбият стиле дип яшәеш алуы, шул нигездә, әмма адәм балаларының дөньяви яшәешен тасвирлауга игътибар ителеп, сәнгатьчә илаһи / рухани / инсани әдәбият стиле дип формалашып дәвам итүе; XIX йөзнең соңгы чирегенә таба гасырлар буена традиция булып килгән илаһи / рухани төшенчәләре урынына аерым персонажның исеме (Хисаметдин менла, 1886) алга куелып, конкрет тормыш шартларында тасвирлануы белән, сәнгатьчә инсани әдәбият стиле дип исемләргә мөмкин иҗади эшчәнлекнең безнең көннәргә кадәр төрле үзгәрешләр белән дәвам итүе мәгълүм була. Әдәби тел тарихын, аның стильләре тарихы дип өйрәнү барганда, һәр стильдә язылган әдәби әсәрнең, гасырлар буена эзлекле рәвештә илаһият тәгълиматына нигезләнгән сәнгатьчә язма традициядә, автор аңында эстетик кабул ителгән дөньяви чынбарлыкны үзенчә тасвирлаудагы яңарышы белән хәрәкәттә булуы, иҗтимагый тормыш шартларына бәйле рәвештә яңартыла баруы аңлашыла.

Мәкалә кысасында катлаулы мәсьәләләргә киңәеп тукталып булмый. Тарихи планда караганда гына күренә һәм аңлашыла торган катлаулы, үзенчәлекле проблемалар, «...татар халкының рухи мирасы булган, татар телен төрле яклап, тирәнтен... фәнни тикшерү» кирәклеген ассызыклаган [2] таләпкә туры китерелеп, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институтында, махсус проект буларак ачылып, «Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы)...» дип өйрәнелә башлады. Хезмәтне, «Әдәби тел тарихын өйрәнү, гомумтел элементларын билгеләү һәм тикшерүгә, шулай ук тел системасының гомумграмматик һәм лексик-семантик категорияләрен аңлауга нигезләнә» дигән мәгълүм кабул ителгән теория истә тотылып [3: 278], гомумтелнең аерым тармакларына нигезләп тикшерү зарур.

1 нче томда фонетика / графика тармагына [25], 2 нче томда грамматика / морфология тармагына [26], 3 нче томда лексика / семантика тармагына [27; 28] мөнәсәбәтле проблемалар күз уңына куелды. Әдәби телнең һәр чоры, шул дәвердәге истәлекләрне тикшерүче белгеч буларак танылган, ягъни монографияләре басылып, фән кандидатлары, докторлары дәрәҗәсендә студентларга махсус курс алып баручы Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадирова, И.Б. Бәширова кебек галимнәр тарафыннан өйрәнелеп, укучыларга тәкъдим ителде. Гомумтелнең элемент / тармакларына нигезләнеп, язма әдәби тел тарихының эзлеклелеген билгеләргә һәм тел системасының категорияләрен аңларга мөмкинлек биргән юнәлештәге тикшерүнең методологик нигезе, метод / ысул, принцип / алымнары, әлеге эшчәнлекнең татар филологиясендә ничек өйрәнелгәнлеге, алга таба анализның ничек барырга тиешлеге турындагы төп фикер проект җитәкчесе тарафыннан бөтен томнар өчен уртак гомуми керештә ассызыкланды. Һәр томда, татар язма әдәби теленең тарихы, аны яшәтүче конкрет тармакларның тарихы буларак күзалланып, аерым тема булып күтәрелде. Һәр авторның монография / хезмәтләрендә, үзе теләгәнчә төрле принципта анализланган мәсьәләләрнең нәтиҗәләрен, әдәби телнең тарихи эзлеклелеген билгеләү максатына туры китереп, мөнәсәбәт белдерергә кирәк булды; әдәби телнең тарихын өйрәнү – аның гомумтел элемент / тармаклары белән гомумграмматик һәм лексик-семантик категорияләренең тарихын күзаллап анализлау булуын истә тотып, метод / ысулы, принцип / алымнары һәр томның керешендә җентекләп аңлатылды [25: 206–232].

Хезмәтнең структур төзелешенә туры китереп, 3 нче томның 2 нче кисәге гомумтелнең синтаксис тармагына нигезләнеп тикшерүгә багышланды. Әлеге фәннең үзенә хас нәзари һәм гамәли мәсьәләләрен аңлау өчен, Л. Җәләйнең шәкерте, остазыбыз М.З. Зәкиевнең «Татар грамматикасы. Синтаксис» [17] хезмәтенә мөрәҗәгать итеп, төп фикерләрен зиһенгә алырга кирәк булды. Әлеге теорияне әдәби тел тарихын барлыкка китерә торган стильләр тарихы дип тикшерелә торган темабызга туры китерергә, ягъни аның стилистика фәне белән уртаклыгы булуга игътибар итәргә кирәк иде. Әлеге мәсьәләнең танылган тел галиме, методист-педагог, Л. Җәләйнең шәкерте С.М. Ибраһимовның «Синтаксик стилистикадан күнегүләр» (1968), «Синтаксик синонимнар һәм аларның төрләре» (1970), «Синтаксик стилистика» (1989) дигән хезмәтләрендә «сөйләм берәмлекләрен стилистик куллану үзенчәлегенә караган» фикерләрендә хәл ителүе билгеле [32: 160]. С.М. Ибраһимов, стиль дип сүз башлаганда, профессор В.Х. Хаковның: «Матур әдәбият әсәрләренең телен башка стильләр белән бер рәткә куеп булмый. Ул функциональ-сөйләм стильләренә караганда бик киң һәм үзендә телдәге барлык стильләрнең дә үзенчәлекләрен чагылдыра, шулай ук анда укучыга эстетик тәэсир итү көчле була, художестволы сурәтләү чараларына зур урын бирелә һәм язучының индивидуаль стиль үзенчәлекләре киң чагылыш

таба», – дигән фикерен инкяр итүдән башлый. Хаклы рәвештә болай ди: «...Һәр стильнең үз кануннары, үз таләпләре бар. ...синтаксик синонимнарны сайлап алуда, бу факторны тормышка ашыру өчен, функциональ стильләрнең теоретик нигезе дә җентекле эшләнгән булырга тиеш. Әлегәчә матур әдәбият стилен гомуми бер стиль дип, ул башка стильләрнең кушылмасын тәшкил итә, анда публицистика, хатлар, фәнни популяр һәм гади сөйләм стилен дә табарга мөмкин дип карау, әдәби әсәрнең теленә әйтеп бетергесез зыян китерә. Әдәби стиль – үзе бер мөстәкыйль стиль һәм ул үз юлы белән барып камилләшергә тиеш тә», дип, функциональ стильләр саналып китә: матур әдәбият стиле, публицистика стиле, фәнни стиль, рәсми эш кәгазьләре стиле, хатлар стиле [18: 3–20]. Алга таба синтаксик категорияләрнең (синоним, омоним, тәңгәл, сүзтезмә һ. б.) аерым стиль таләбенә кирәкчә ярашып файдалану тиешлеге мәсьәләсе игътибар үзәгенә куела, аерым сөйләм стильләренең үзенә кирәк тел стильләре берәмлекләрен сайлап алуы белән башкалардан аерымлануы, бу юнәлештә синтаксис һәм стилистика дигән фән тармакларын берләштереп тикшерергә кирәк булуы ассызыклана.

Без, остазларыбызга догада булып, аларның фикерләренә нигезләнәбез. «Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). 3 т. 2 кисәк. Синтаксис. Сөйләм стильләре һәм Тел стильләре. Илаһият тәгълиматына нигезләнгән сәнгатьчә язма традиция һәм дөньяви чынбарлыкны тасвирлаудагы яңарыш» дип тикшерелә торган монографиянең 3 нче томының 2 нче кисәген язу барышында, гомумтелнең сөйләм өйрәнелә торган синтаксис һәм текст синтаксисы тармагына караган мәсьәләләре истә тотылып, Л. Җәләйнең хезмәтләрендә стиль, стилистика дип күтәрелгән фикерләргә игътибар бирелде.

Әсәрнең темасы, башламы дип сүз башлау белән, XIII гасырдан алып, XIX гасырның ахырына кадәр татар сәнгатьчә әдәбият стиленең, бисмилләһир-рахмәнир-рахим дигән аять белән бергә (аятьне төрле кеше төрлечә яза, әлеге шәкелнең аять булуы һәм язылышы «Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә» хезмәтенә нигезләнеп бирелә) (20), Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дип, илаһият тәгълиматы традициясендә башлануы һәм авторның үз чоры дөньяви яшәешен тасвирлавы белән яңартылып дәвам иттерелүе мәгълүм була. Шуңа күрә тема «Илаһият тәгълиматы традициясендә дөньяви чынбарлыкны сәнгатьчә тасвирлаудагы яңарыш» дип ачыкланды. Үз вакытында Л. Җәләй тарафыннан күрсәтелә алмаган «Сәнгатьчә илаһи / рухани» һәм «Сәнгатьчә илаһи / рухани / инсани» әдәбият стиле дип исемләргә мөмкин ике стиль урыннарына куелды. Бу том басмага әзерләнде. Шулай итеп, остазыбыз, олуг галим, танылган педагог Латыйф Җәләлетдин улы Җәләлетдиновның (Л. Җәләйнең) тууына 130 ел тулган көннәрдә дә киңкырлы эшчәнлегенең актуаль булуы, аның үзенең һәм шәкертләренең фикер юнәлешләрендә фәнни тикшеренүләрне дәвам итү мөмкинлеге күренде. «Татар әдәби теле тарихы. XIII гасыр – XX йөз башы...» дип башланган теманы гомумтелнең һәр дүрт

тармагына нигезләп тикшерү белән аерым проект булып ачылган фәнни тикшеренүнең тәмам булуын куанып әйтә алабыз.

Татар халкының үз карамагында мәктәп-мәгарифе булмаган XX йөз ахыры – XXI йөз урталарындагы вазгыятьтә татар халкының сөйләмә һәм язма әдәби теленең (стильләренең) иҗтимагый тормыш шартлары таләбенә җавап бирү юнәлешендәге катлаулы үсеш-үзгәрелеш мәсьәләләрен һәм теоретик, һәм гамәли нигездә өйрәнүнең актуаль тема булып күтәрелүе мәгълүм [1, 24 һ. б.]. Димәк, яңа проблемаларны өйрәнү өчен, яңа проект ачу өчен ныклы нигез салынганлыкка ышаныч белдереп, алга таба бу мөһим юнәлештә эшчәнлек дәвам итәр, дигән өметтә калабыз.

## Әдәбият


1. *Абдуллина Ч.З., Сагдеева Ф.К.* Языковая ситуация в Республике Татар стан: сферы применения татарского языка. Казань: Школа, 2021. 136 с.

2. *Бәширова И.Б.* Татар стилистикасының теоретик нигезләре: Татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентлары өчен программа. Казан, 2005. Б. 21–25.

3. *Виноградов В.В.* История русских лингвистических учений. М.: Высшая школа, 1978. 367 с.

4. *Дмитриев Н.К.* Актуальные вопросы татарского языкознания. Вып. 4. Казань, 2005. С.5.

5. *Җәләй Л.* Әдәби мөсабәкәләр. Татар шагыйрьләре «Яшь йөрәкләр» // Вакыт. Оренбург, 1913. 23 март.

6. *Җәләй Л.* Стилистика һәм әсәрнең композициясе. Тәрҗемәчеләр белән уку өчен бер курс. 1934. 36 б.; Стилистика һәм гомуми тел белеме буенча язмалар. 1935. 38 б. // Язма мирас үзәге. Ф. 29, тасв. 1, сакл. бер. 4.

7. *Җәләй Л.* Практик стилистика алдында торган төп бурычлар // Мәгариф. 1935. №11. Б. 3–8.

8. *Җәләй Л.* Сурәтләү чарасы булучылыкта җөмләнең аерымланган кисәкләре // Совет әдәбияты.1935. № 12. Б. 87–95.

9. *Җәләй Л.* Әдәби телне өйрәник! (Ә. Еникинең «Рәхмәт, иптәшләр» повестена карата) // Совет әдәбияты. 1953. №7. Б. 121–124.

10. *Җәләй Л.* Татар теле әдәби теле туу мәсьәләсенә карата // Совет әдәбияты. 1956. № 12. Б. 91–99.

11. *Җәләй Л.* Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар). Казан: Фикер, 2000. Б. 12, 16, 17, 18, 20, 34, 35 һ. б.

12. *Җәләй Л.* Тукай телендә фигыльләр // Совет әдәбияты. 1938. № 3, 4, 5.

13. *Җәләй Л.* Рец.: «Сиваш» (Г. Разин әсәре, 1937 ел) // Совет әдәбияты. 1938. № 6. Б. 84–103.

14. *Җәләй Л.* Рец.: «Үч» (Г. Бәшировнең хикәяләр җыентыгы, 1943) // Кызыл Татарстан. 1943. 9 июнь.

15. *Җәләй Л.* «Намус турында»// Язма мирас үзәге. Ф. 75, тасв. 2, сакл. бер. 3.

16. *Зәйнуллин Җ.Г.* XVIII – XX йөз башында татар рухани әдәбияты: Коръән тәфсирләре, хәдисләр һ. б. чыганаклар. Тәрҗемә принциплары һәм тел үзенчәлекләре. Казан: Мәгариф, 1998. 207 б.

17. *Зәкиев М.З.* Татар грамматикасы: өч томда, 3 т.: Синтаксис. Казан, 1999, Б. 5–14; 450–483.

18. *Ибраһимов С.М.* Синтаксик стилистика. Студентлар өчен кулланма. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1989. 150 б.

19. *Катанов Н.Ф.* Материалы к изучению Казанско-татарского наречия. Казань: Типо-литогр. Имп. ун-та, 1898. Ч. 1: Образцы книжной и устной литературы казанских татар. 1898. 168 с.

20. Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә. Казан: «Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты, 2020. 808 б.

21. *Кукляшев С.* Татарская хрестоматия. Казань: Университетская тип., 1859. 124 с.

22. *Курбатов Х.Р.* Татарская лингвистическая стилистика и поэтика. М.: Наука, 1978. 217 с.

23. *Насыйри К.* Ысулы җәгърафия кәбир. Казан, 1898 // Сайланма әсәрләр. ике томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 84–87.

24. *Сагдеева Ф.К.* Проблемные поля когнитивной лингвистики (на материале татарского языка). Казань, 2025. 206 с.

25. Татар әдәби теле тарихы / И.Б. Бәширова, Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадирова; ред. Ф.М. Хисамова. Казан: ТӘһСИ, 2015. 1 т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма и вариантлылык. 696 б.

26. Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадыйрова, Р.Ф. Мирхәев; ф. ред. Ф.М. Хисамова. Казан: ТӘһСИ, 2017. II т.: Морфология. Грамматик категорияләрнең структур-субстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. 888 б.

27. Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, М.З. Вәлиева, Г.Ф. Гайнуллина, Х.Х. Кузьмина; ф. ред. Ф.С. Баязитова. Казан: ТӘһСИ, 2019. III т.: Лексика. Лексик-семантик категорияләрнең инвариант-парадигма үзенчәлеге һәм контекстуаль-синтагматик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. Беренче кисәк. 528 б.

28. Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, М.З. Вәлиева, Р.Ф. Мирхәев; ф. ред. Ф.С. Баязитова. Казан: ТӘһСИ, 2020. III т.: Лексика. Лексик-семантик категорияләрнең инвариант-парадигма үзенчәлеге һәм контекстуаль-синтагматик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. Икенче кис. 588 б.

29. Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 1 т.: Борынгы чор һәм Урта гасырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 8.

30. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. 2 т. Казан, 1979. Б. 710.

31. *Хаков В.Х.* Хәзерге татар әдәби теле. (Стилистика). Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 304 б.

32. *Шәкүрова М.М., Гыйниятуллина Л.М.* Татарстан галимнәренең фәнни-методик мирасы: Сәгадәт Мөгаллим улы Ибраһимов (галим-методистның тууына 95 ел) // Фәнни Татарстан. 2023. № 4. Б. 160.

33. Языки мира. Тюркские языки. Бишкек, 1997. С. 160, 395, 413,427, 438, 358.

***Бәширова Илида Басыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе*

***Баширова Илида Басыровна,***
*доктор филологических наук,*
*заслуженный деятель науки Республики Татарстан*
*lilvil25@mail.ru*

УДК 398

***И.И. Ямалтдинов***

## ТАТАР ҖЫРЛАРЫН ӨЙРӘНҮГӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР (Фольклорчы Илбарис Надировның тууына 100 ел)

Статья посвящена анализу научной и научно-организационной деятельности заслуженного работника культуры Республики Татарстан, лауреата Государственной премии Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая, ученого-фольклориста И.Н. Надирова. В работе рассматриваются основные направления его исследований в области татарской фольклористики.

**Ключевые слова:** татарская фольклористика, татарское народное творчество, Ильбарис Надиров, татарские народные песни, фольклор периода Великой Отечественной войны.

The article is devoted to the analysis of scientific and scientific-organizational activities of the Honored Worker of Culture of Tatarstan, Laureate of the Gabdulla Tukai State Prize of the Republic of Tatarstan, folklore scientist I.N. Nadirov. The paper examines the main directions of his research in the field of Tatar folklore.

**Keywords:** Tatar folklore, Tatar folk art, Ilbaris Nadirov, Tatar folk songs, folklore of the Great Patriotic War period.

Татар халык иҗатын, аерым алганда җырларны аеруча җентекләп һәм нечкәләп өйрәнгән, алардагы хис байлыгын, шигъриятне, рухи сафлыкны һәм фәлсәфи тирәнлекне ачып, аңлатып бирүгә аеруча зур өлеш керткән фольклорчы галим, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Илбарис Надировның тууына 100 ел тулды. Татар фольклористикасы фәне өлкәсендәге тикшеренүләрнең һәм гомумән фәнни эшләрнең оештыручысы булган бу киң эрудицияле, максатчан шәхеснең тормышы һәм иҗаты аерым игътибарга лаек.

Илбарис Нурислам улы Надиров 1925 елның 15 апрелендә Татарстанның Әлмәт районы Нәдер авылында туа. Озакламый аларның гаиләсе Ютазы районындагы Алмата авылына күченеп килә. Балачак елларында бер авылдан икенче авылга, җырлый-җырлый, Сабан туйларына йөргән чаклары, ул җырларның һаман күңелдә саклануы, булачак галимнең төп шөгыленә – татар җырларын җыю, аларны төрләргә бүлү һәм халкыбызга җыр жанрының үзенчәлекләрен ачып бирүгә олы этәргеч булгандыр.

И. Надиров 1932–1943 елларда башлангыч мәктәпне Ютазы районының Алмата авылында, урта мәктәпне Кәрәкәшле авылында мактау граматосы белән тәмамлап, район Башкарма комитетында нархозучет инспекторы булып эшли башлый.

Ул Ютазы районы комсомол комитеты юлламасы белән Уфа авиация институтына укырга керә, 1943 елны Чкалов өлкәсенең (хәзерге

Оренбург) Колтубанка төбәгендә урнашкан снайперлар мәктәбендә белем ала, көзен фронтка китә. 1944 елның августыннан башлап, сугыш беткәнче, Балтыйк буе фронтында хезмәт итә, ике тапкыр яралана. Җиңү бәйрәмен 1489 нчы үзйөрешле артиллерия полкында радиотелеграфист буларак каршылый. 1948 елның февралендә, демобилизациянеп, Ютазы районы Алмата авылына әти-әнисе янына кайта. Егетнең укырга, белем алырга теләге зур була. Радиотелеграфист дусты Анатолий Шикуновның: «Иптәш Надиров, ... син белгәнем җитәр дип туктарга уйлыйсың кебек... Төпле белем алу өчен, университет бетерергә кирәк...», – дигән сүзләре һәм киңәше дә йогынты ясый. Ул 1948–1953 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә укып, аны кызыл диплом белән тәмамлый.

И. Надиров СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында (хәзерге Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) «фольклористика» белгечлеге буенча филология фәннәре докторы, олуг галим Хәмит Ярми җитәкчелегендә аспирантура уза. Ул беренчеләрдән булып Бөек Ватан сугышы чоры татар халык иҗатын өйрәнә һәм 1959 елда «Бөек Ватан сугышы чорында татар халык иҗаты» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Сугыш чоры фольклорын җентекләп өйрәнүе, билгеле, галимнең биографиясе белән бәйләнгән.

1961 елда галимнең диссертациясе нигезендә «Халык һәм җыр: Бөек Ватан сугышы чорында татар халык поэтик иҗаты» монографиясе дөнья күрә. Бу китап Бөек Ватан сугышы елларында татар халкы иҗат иткән әсәрләрне җыю һәм өйрәнү өлкәсендә беренче житди адым була. Китапта сүз Бөек Ватан сугышы чоры татар халык иҗаты әсәрләренең фронтта иҗат ителүе һәм сугышта – солдатлар, ә тылда гади эшчеләр һәм колхозчылар арасында таралу, халык телендә яшәү үзенчәлекләре турында. Монографиянең төп өлешен сугыш чоры фольклорының идея-тематик эчтәлеген өйрәнү алып тора. Совет патриотизмы, дошманнарга каршы аяусыз көрәш, фронтта батырлык, тылдагы фидакяр хезмәт – бу чор халык иҗатында яңгыраган иң көчле фикер. Автор авыр шартларда иҗат ителеп, халык арасында киң таралган фольклор әсәрләренең әдәби-эстетик үзенчәлекләрен дә тикшерә. Аның «Бөек Ватан сугышы елларында халык җырлары» (1957), «Совет армиясе турында татар халык җырлары» (1958), «Бөек Ватан сугышы чорында татар халык иҗаты» (1959), «Сугыш чоры бәетләре» (1960) кебек мәкаләләре бер-бер артлы дөнья күрә. Бу темага И. Надиров вакытлы матбугат битләрендә дә күп кенә мәкаләләр белән чыгыш ясый. Аларда совет чорында яңа фольклор әсәрләре: җырлар, бәетләр туу, аларның шигъри үзенчәлекләре кебек теоретик яктан да әһәмиятле мәсьәләләр яктыртыла [4: 22].

И. Надиров – гомерен халкыбызның җырларын җыюга, фәнни яктан өйрәнүгә, бастырып чыгаруга багышлаган галим. Аның бу өлкәдәге казанышы итеп, 1965 елда дөнья күргән «Татар халык җырлары» дигән җыентыкны күрсәтергә була [6: 2]. Әлеге китап татар

фольклористикасы тормышында мөһим вакыйга булып, халкыбызның җырларын җыю һәм өйрәнү тарихында өр-яңа бер сәхифә ача. Аңа кадәр беркайда да басылмаган 400 артык лирик озын җырларны һәм йола җырларын туплаган әлеге басма фәнни әйләнешкә яңа сыйфатлы фактик материал алып килә. Галим Х. Мәхмүтов билгеләп үткәнчә, «элеккеге елларда татар халкының җыр иҗаты нигезендә дүртьюллык кыска җырлардан тора, дигән караш өстенлек итә иде. И. Надировның үз сүзләре белән әйткәндә, бездә «халыкның ата-бабадан килгән гореф-гадәтләре, гаилә бәйрәмнәре белән бәйле йола поэзиясе» дә, «күңел ачулар, уеннар, биюләр белән тыгыз үрелештә торучы уен җырлары, бию такмаклары» да, «кеше күңелендәге иң тирән кичерешләрне, хисләр хәрәкәтен энҗе кебек бергә тезеп, шигъри бөтенлектә чагылдыручы озын җырлар» да бар. Җыентыкка бирелгән зур күләмле һәм тирән эчтәлекле кереш мәкаләдә И. Надиров, яңа фактик материалларга таянып һәм җырларның көнкүрештә тоткан урынын, йола, уен, биюләр белән бәйләнешен, поэтик үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларны дүрт төркемгә бүлә: «йола җырлары», «уен-бию җырлары», «лирик кыска җырлар», «лирик озын җырлар» [4: 21]. Әлеге классификация бу өлкәдә алга таба үткәрелгән тикшеренүләрнең нигезенә ята һәм бүген дә үзенең фәнни әһәмиятен саклап кала.

1960–1970 елларда фольклористика фәнендә житди бер юнәлеш ачылып, төрле халыклар авыз иҗатының күптомлы басмаларын чыгару эше башлана. Казах, кыргыз, үзбәк, мордва, башкорт һәм башка халыкларда шул юнәлештә беренче житди адымнар ясала [1: 13]. 1972 елда Институтның халык иҗаты секторы мөдире итеп билгеләнгән И. Надиров әнә шундый күптомлыкның проспектын төзү белән житәкчелек итә. Әлеге эшне татар фольклористикасы үсешендә яңа бер этап дип билгеләргә була. 12 томлы «Татар халык иҗаты» җыелмасының тәфсилле һәм чын фәнни нигездә әзерләнгән проспекты төзелеп беткәч, сектор галимнәре күптомлыкны әзерләү эшенә керешә. Шушы зур житди басманың фәнни житәкчесе булудан тыш, И. Надиров – дүрт томның турыдан-туры төзүчесе, кереш мәкаләләр һәм искәрмәләр авторы. Ул төзегән «Кыска җырлар» (1976), «Йола һәм уен җырлары» (1980), «Бәетләр» (1983), «Тарихи һәм лирик җырлар» (1988) томнары халык иҗатын өйрәнүгә зур өлеш кертәләр. Шушы уникетомлыкны әзерләүгә куйган хезмәтләре өчен галимгә (тагын берничә хезмәттәше белән бергә) Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

И. Надировның Мәскәү, Ленинград, Казан, Тбилиси, Алматы, Кишинёв һәм башка шәһәрләрдә уздырылган бөтенсоюз фольклор киңәшмәләрендә проблемалы докладлар белән катнашуын, фәнни-оештыру эшләренә, яшь белгечләр хәзерләүгә күп көч куюын әйтми калу мөмкин түгел. Ун ел дәвамында ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми сәркатибе һәм директор урынбасары булып эшли, егерме елга якын биредә халык иҗаты бүлеген житәкли.

И. Надиров бүлек мөдире булып эшләгән чорда татар фольклорының төрле проблемаларына караган җиде фәнни җыентык дөнья күрә. Мәсәлән, «Татар фольклоры жанрлары», «Борынгы татар фольклоры мәсьәләләре», «Татар фольклорында социаль мотивлар», «Татар халык поэтик иҗатының хәзерге торышы», «Поэтика татарского фольклора» һ.б. Идел-Урал буенда яшәүче халыклар фольклорындагы үзара бәйләнешләргә багышланган региональ симпозиум үткәрелә. Галим татар фольклоры буенча белгечләр әзерләүгә дә зур игътибар бирә. Ул дүрт аспирантка җитәкче була, һәм бүгенге көндә алар барысы да – татар фольклористикасы үсешенә өлеш керткән галимнәр.

И. Надиров шулай ук чит илләрдә яшәгән татар диаспоралары белән бәйләнешләрнең беренче эзләрен салыша. Финляндиягә татар галимнәре, артистларының тәүге сәфәрен оештыруда, чит илдә яшәүче милләттәшләребезне Казанда кабул итүдә И. Надировның роле зур булды. Шуның белән бергә, галим – татар фольклор фәненә зур хезмәт күрсәткән аерым шәхесләр һәм Финляндиядәге татар диаспорасы турындагы мәкаләләр авторы да. Болар барысы да аның киң кырлы шәхес, оста оештыручы булуын тагын бер мәртәбә раслый.

Шулай итеп, Илбарис ага Надиров – Бөек Ватан сугышы чорындагы татар халык иҗатын беренчеләрдән булып өйрәнгән галим. Шул ук вакытта ул үзенең бөтен көчен, сәләтен, гомерен аңа җан рәхәте биргән татар халык иҗатын – җыр жанрын өйрәнүгә багышлаган. Аның хезмәтләре яши һәм бүген дә үз халкына хезмәт итүдән туктамый.

**Әдәбият**

1. *Мәхмүтов Х.Ш.* Хәмит Ярми. Галим һәм шәхес: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 223 б.

2. Татарский энциклопедический словарь. Казань, 1999. С. 383.

3. Утлы еллар кайтавазы: Бөек Ватан сугышы чорында татар халык иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 199 б.

4. Фәнни эзләнүләр юлында. Казан: Фикер, 2000. 288 б.

5. *Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора. Казань: ИЯЛИ, 2016. 184 с.

6. *Ямалтдинов И.И.* XX йөзнең 60 нчы елларында халык авыз иҗаты буенча тикшеренүләр // Фәнни Татарстан. 2024. № 3 (43). Б. 103–106.

***Ямалтдинов Ильмир Илдар улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Ямалтдинов Ильмир Ильдарович,***
*кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник отдела народного творчества Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ*

*jailmir@mail.ru*

## ТАТАРЛАРНЫҢ ДӨНЬЯНЫ МИФОЛОГИК КАБУЛ ИТҮЕ: ТӨП ОБРАЗЛАР ҺӘМ СИМВОЛЛАР

Бер халыкның мифологик күзаллаулар системасын өйрәнү – гуманитар фәннәрнең мөһим юнәлеше, һәм ул борынгы ышануларны реконструкцияләргә генә түгел, аларның хәзерге заман шартларында трансформациясен күзәтергә дә мөмкинлек бирә. Билгеле булганча, һәр халыкның мифологиясе мифологик ышанулар, ритуаллар һәм дөнья төзелеше турында күзаллауларның киң спектрын колачлый, хәтта хәзерге замандагы социаль һәм мәдәни трансформацияләр вакытында да актуальлеген югалтмый. Халык мифологик традициясен үсештә һәм хәзерге чынбарлык контекстында тикшерү – комплекслы фәнара якын килүне таләп итә торган мөһим бурыч.

Л.Х. Дәүләтшинаның «Мир вокруг нас: о современном состоянии мифологической традиции татар» (Казань: ИЯЛИ, 2024. – 120 с.: ил. – (Серия «Обычаи и традиции татарского народа»)) дигән фәнни-популяр монографиясе татар мифологик күзаллауларының традицион аспектларын да, хәзерге заман үзгәрешләрен да аңларга һәм системалаштырырга омтылудан гыйбарәт. Структурасы ягыннан монография төп ике бүлектән тора.

Беренче бүлек – «Как устроен мир: структура Вселенной» («Дөнья ничек төзелгән: Галәм структурасы») – дөньяның килеп чыгышы һәм беренче кешеләр, сакраль география һәм пространство төзелеше турындагы мифологик күзаллауларны өйрәнүгә багышлана. Анда татар мәдәниятендә таралган дөнья яратылу турындагы мифлар, аларның борынгы төрки космогоник модельләр белән бәйләнышлары, шулай ук аларга ислам күзаллауларының йогынтысы анализлана. Татарларның традицион мәдәниятендә символик мәгънәгә ия булган йорт һәм юл образларын да кертеп, сакраль киңлек концепциясенә аерым игътибар бирелә. Автор традицион рәвештә җәлеп ителә торган фольклор жанрларын гына түгел, йолаларны һәм ышануларны да тикшерә, аларның коллектив аңда тотрыклылыгын һәм хәзерге шартларда трансформациясен күрсәтә.

Икенче бүлек – «Кто нас окружает: обитатели двух миров» («Тирә-юнебездә кемнәр: ике дөнья вәкилләре») – халык традициясендә бүгенге көндә дә актуаль булган мифологик персонажлар турындагы ышанулар системасын тикшерүдән гыйбарәт. Автор түбән мифология персонажларының төп категорияләрен аерып чыгара: йорт һәм табигать локусларының ияләре, зыян салучы һәм нейтраль затлар һ. б. Хезмәттә аларның функцияләре, йөз-кыяфәтләре, үз-үзен тотышлары өйрәнелә. Автор кайбер персонажларның хәтта глобальләшү шартларында да үз характеристикаларын саклап калуларына, ә икенчеләренең исә борынгы ышану калдыклары рәвешендә генә яшәвенә игътибар итә.

Хезмәтнең төп казанышларыннан берсе – татар мифологиясен өйрәнүгә комплекслы якын килү. Автор мифологик күзаллауларның эволюциясен тарихи перспективада анализлап, аларның вертикаль кисеменә дә, халык традициясендә мифологик персонажларның заманча формаларын өйрәнеп, горизонталь кисемгә дә игътибар бирә. Мондый алым татар мифологик традициясенең, структур бөтенлеген саклаган хәлдә, үзгәрүчән шартларга ничек җайлашуын ачыкларга мөмкинлек бирә.

Хезмәтнең зур өстенлеге – экспедицияләр вакытында автор тарафыннан җыелган кыр материалларының фәнни әйләнешкә кертелүендә. Халык сөйләкләрен, ышануларын, ырымнарын һәм йолаларның тасвирламаларын анализлап, Л.Х. Дәүләтшина татар халкының мифологик күзаллаулар системасының мәдәни үзтәңгәллекнең әһәмиятле өлеше булып калуын билгеләде.

Хезмәтнең уңай ягы – аның дисциплинаара характерда булуында, ул татар мифологиясен киң мәдәни контекстта карарга мөмкинлек бирә. Автор чиктәш фәннәр (фольклор, этнография, дин белеме, культурология) мәгълүматларына, шулай ук, борынгы төрки һәм Урта гасырлар татар мәдәнияте язма истәлекләрен дә кертеп, чыганакларның киң спектрына, этнографик материалларга, шулай ук хәзерге тикшеренүләргә һәм кыр язмаларына таяна.

Тикшеренүнең шулай ук гамәли кыйммәте дә зур: ул татар халкының матди булмаган мәдәни мирасын сакларга ярдәм итә. Бу контекстта хезмәт мифологик күзаллауларны документлаштыруда, аларны системага салу һәм төшенүдә мөһим функция үти. Бу яктан ул тикшеренүчеләр, укытучылар, музей хезмәткәрләре һәм халык мәдәнияте белән кызыксынучылар өчен мөһим чыганак булып тора.

Автор татар мифологик традициясенең төп элементларын тәфсилләп тасвирлый, әмма шул ук вакытта кайбер юнәлешләрне алдагы хезмәтләрдә тирәнрәк яктырту сорала. Шуларның берсе – мифологик контекстта этносара бәйләнешләрне өйрәнү. Татар мифологиясе Идел-Урал буенда яшәгән күрше халыклар белән интенсив бәйләнеш шартларында формалаша һәм яши, бу исә мифологик образларның, сюжет һәм ритуалларның үзара үзләштерелүенә китерә. Бу процессны җентекләбрәк өйрәнеп, мәдәни алмашу механизмнарын яхшырак аңларга, мифологик традицияләрнең кисешү нокталарын ачыкларга һәм татар мифологиясенең күрше этнослар белән үзара йогынты ясавын күрсәтергә мөмкин булыр иде.

Татар мифологиясенең сакраль географиясен анализлау да – перспективалы күренеш. Монографиядә сакраль киңлекнең аерым элементлары (йорт, юл, табигый локуслар) тикшерелә, әмма изге урыннар, ритуаль зоналар һәм аларның символикасы турындагы мифологик күзаллауларны җентекләп өйрәнү аша татарларның традицион мәдәниятендә пространстволы кабул итүне киңрәк аңларга мөмкин булыр иде.

Китап фольклор, этнография, культурология өлкәсендәге белгечләргә, шулай ук татар халкының рухи мирасы белән кызыксынучы киң катлау укучыларга адресланган. Ул татар мифологиясенең традицион аспектларын ачып кына калмый, XXI гасырда аның актуальлеге, глобальләшү шартларында мифологик күзаллауларның трансформацияләнүе һәм аларны саклау юллары турындагы мәсьәләләрне дә көн тәртибенә куя.

Тулаем алганда, «Мир вокруг нас: о современном состоянии мифологической традиции татар» дигән китап – татар мифологиясе һәм аның хәзерге замандагы яшәеше турындагы фәнни күзаллауларны киңәйтә торган тикшеренү. Ул бу өлкәдә моннан соңгы хезмәтләр өчен ныклы нигез хезмәтен үти.

***Ильина Галина Геннадьевна,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Чуваш дәүләт гуманитар фәннәр институты*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Ильина Галина Геннадьевна,***
*кандидат филологических наук, доцент,*
*ведущий научный сотрудник Чувашского государственного института*
*гуманитарных наук*

*galiil69@mail.ru*

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**2025 елның 2 апрелендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты сәхнәләштерүгә 80 ел тулуга багышланган түгәрәк өстәл үткәрелде. Институтның Сәнгать белеме үзәге хезмәткәрләре, Казанның югары уку йортлары һәм сәнгать оешмалары вәкилләре үз чыгышларында «Шүрәле» балетының төрле аспектларын яктыртты.

**2025 елның 2–4 апрелендә** Татарстанда «Энергопром» халыкара энергетика форумы үткәрелде. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов форум мәйданчыгында «Новикомбанк» һәм Курск электр аппаратлары заводы вәкилләре белән очрашты һәм төрле өлкәләрдә хезмәттәшлек мәсьәләләре турында фикер алышты.

Форум кысаларында Россия һәм Белоруссия, Евразия икътисади берлеге һәм Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләренең ягулык-энергетика комплексы тармакларында ирекле һәм көйләнә торган бәяләрне формалаштыру һәм куллану мәсьәләләре буенча түгәрәк өстәл узды, анда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты катнашты.

**2025 елның 3 апрелендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты Айнур Тимерханов Татарстанның Халыклар дуслыгы йортында Казахстан Республикасының Казандагы Генераль консуллыгы һәм Татарстан халыклары ассамблеясы катнашында уздырылган «Казахстан халкы ассамблеясы: 30 ел бердәмлек һәм татулык – киләчәккә караш» түгәрәк өстәлендә катнашты. Ул Татарстан һәм Казахстанның гуманитар фәннәр өлкәсендәге багланышлары турында сөйләде.

**2025 елның 9–10 апрелендә** Казанда «Халыклар һәм төбәкләр язмышында 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы» халыкара фәнни конференциясе үтте. Конференция Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан оештырылды. Россиянең төрле өлкәләреннән һәм чит илләрдән килгән 150 дән артык эксперт фронттагы сугыш хәрәкәтләре, тылдагы хезмәт батырлыклары, СССР халыкларының җиңүгә керткән өлеше, сугыш елларында социаль һәм мәдәни процесслар турында фикер алышты.

**2025 елның 10–11 апрелендә** «Казань Экспо» үзәгендә XV Россия венчур форумы үтте. Форумда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тәкъдим иткән күргәзмәдә Tatsoft тәрҗемә сервисы, файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген күтәрә торган микросейсмик мониторингның аппарат-программа комплексы, 3D-басмада кулланыла торган алюминий һәм кремний диоксиды порошоклары үрнәкләре, нәселдән килгән авыруларны дәвалау өчен ген дарулары, Урта гасырлардан бүгенге көнгә кадәр Россия дәүләтен яклауга, ныгытуга һәм үстерүгә татар халкының керткән өлеше турында «Татарлар Ватанга хезмәттә» фәнни-тикшеренү һәм мәгърифәтчелек проекты һ. б. белән танышырга мөмкин иде. Күргәзмәне Россиянең фән һәм югары белем министры Валерий Фальков һәм Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов та карады.

**2025 елның 10–11 апрелендә** Казанда «Күптелле Россия: мәдәниятләр диалогыннан сыйфатлы белем бирүгә» халыкара форумы узды. Чарада Россия Федерациясенең төрле төбәк-

ләреннән, шулай ук Казахстан, Үзбәкстан, Беларуссиядән һәм Азәрбайҗаннан спикерлар катнашты. Форум полилингваль белем бирү системасын үстерү буенча перспектив тикшеренүләрне һәм идарә практикаларын алга җибәрү максатында үткәрелде.

Форумның пленар утырышында Г. Ибраһимов исемендәге Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге хезмәткәрләре дә катнашты. Шулай ук чарага махсус оештырылган күргәзмәдә алар тарафыннан эзерләнгән яңа буын укыту-методик комплектлар, туган (татар) теле һәм әдәбияты буенча укыту һәм укыту-методик әсбаплар тәкъдим ителде.

**2025 елның 10–13 апрелендә** Дагстан дәүләт университетында профессор Мөхәммәтсәет Мусаев истәлегенә багышланган XIV Халыкара фәнни конференция оештырылды, ул гомуми һәм региональ ономастиканың актуаль мәсьәләләренә багышланган иде. Конференция лингвистик география, топонимика һәм антропонимика өлкәсендәге тикшеренүләр буенча фикер алышу мәйданчыгына әверелде.

Пленар утырышта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Илгиз Халиков һәм директорның фәнни эшләр буенча урынбасары Олег Хисамов чыгыш ясады.

**2025 елның 14–16 апрелендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Россия һәм Кытай: Дала Евразиясе тарихын һәм археологиясен өйрәнүнең актуаль проблемалары» дигән халыкара фәнни конференция уздырылды. Ул, Россиянең һәм Кытайның әйдәп баручы галимнәрен очраштырып, ике ил халыкларының үткәне турында фикер алышуга юнәлдерелде. Конференция эшендә 200 дән артык кеше катнашты, шул исәптән Россиянең (Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Әстерхан, Барнаул, Буденновск, Владивосток, Йошкар-Ола, Кемерово, Новосибирск, Чиләбе, Элиста, Улан-Удэ) һәм Кытайның (Пекин, Ланьчжоу, Сиань, Тяньцзинь, Шицзячжуан, Хух-Хото, Чунцин) фәнни-укыту үзәкләреннән 50 дән артык галим, шулай ук 70 тән артык онлайн тыңлаучы һәм Татарстанның мәдәният, фән һәм белем бирү оешмаларыннан 80 гә якын кунак чакырылды. Секция утырышларында галимнәр Дала Евразиясе территориясендәге тарихи процесслар, дисциплинаара тикшеренүләрнең яңа методикалары, археологиядә яңа техник җайланмаларны куллану мөмкинлекләре, археологик тикшеренүләр нәтиҗәләре, тарихи һәм археологик тикшеренүләр нигезендә традицияләр һәм кыйммәтләр алмашу турында фикер алыштылар.

**2025 елның 16–18 апрелендә** Новосибирск шәһәрендә Татарстан Республикасы фәне һәм мәдәнияте көннәре үткәрелде. Татарстан делегациясен Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева җитәкләде. Делегация составында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов, республика югары уку йортлары вәкилләре, танылган галимнәр, мәдәният һәм мәгариф эшлеклеләре бар иде.

**2025 елның 16–18 апрелендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтында «Каюм Насыйри» шәхси энциклопедиясе һәм шул исемдәге биобиблиографик күрсәткеч җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты Айнур Тимерханов институт коллективына Каюм Насыйриның бай мирасын саклауга, өйрәнүгә һәм мәңгеләштерүгә керткән зур өлешләре өчен рәхмәт белдерде.

Чарада министрлыклар, югары уку йортлары, фәнни-тикшеренү һәм иҗтимагый оешмалар, мәдәният учреждениеләре вәкилләре, Каюм Насыйриның туганнары да катнашты.

**2025 елның 16–26 апрелендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге мөдире Рауза Солтанова җитәкчелегендәге бер төркем рәссамнар катнашында «Тукай Әстерханда» дип аталган арт-пленэр оештырылды. Анда катнашучылар, 1911 елның язында Әстерханда Габдулла Тукай булган урыннарда йөреп, кырыкка якын сәнгать әсәре (этюдлар, картиналар, рәсемнәр) иҗат итте. Бу эшләр арасыннан иң камилләре Г. Тукайның Казандагы әдәби музеенда киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителәчәк.

**2025 елның 29 апрелендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «Бөек Ватан сугышы әдәбиятта һәм публицистикада» дигән түгәрәк өстәл үткәрелде. Галимнәр, язучылар, журналистлар катнашында узган бу чарада институт галимнәре Дания Заһидуллина, Әлфәт Закирҗанов, Венера Макарова, Айгөл Ганиева, Ләйсән Галиева, шулай ук Уфа фән һәм технологияләр университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы мөдире Альбина Хәлиуллина һәм кафедра доценты Илдус Фазлетдинов, әлеге университетның Стәрлетамак филиалы татар һәм чуваш филологиясе кафедрасы мөдире Илсур Мансуров, Казан федераль университетының Алабуга институты доценты Фәридә Габидуллина үз чыгышларында Бөек Ватан сугышы һәм фронтовик язучылар, сугыш чорында Казандагы әдәби тормыш, прозада «окоп хакыйкате», хәзерге татар әдәбиятында сугыш темасының чагылышы һ. б. темаларга тукталдылар.

**2025 елның 12 маенда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә әл-Фәраби исемендәге Казах милли университеты белән хезмәттәшлек турында фикер алыштылар. Эшлекле очрашуда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов, әл-Фәраби исемендәге Казах милли университеты ректоры Жансеит Туймебаев, Казахстанның Казандагы Генераль консулы Ерлан Исхаков һәм ТР Фәннәр академиясе вәкилләре катнашты. «Безнең республикаларны җитәкчелек арасында җылы һәм ышанычлы мөнәсәбәтләр, ныклы икътисади элемтәләр, фән өлкәсендәге хезмәттәшлек кенә түгел, ә бай уртак тарих, традицияләр, дин, туган мәдәният һәм тел бәйли», – дип ассызыклады Рифкать Миңнеханов һәм казах хезмәттәшләрен Дала Евразиясе халыкларының тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүдә, археологиядә актив хезмәттәшлеккә чакырды.

**2025 елның 14 маенда** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган «Сугыш утын үткән галимнәр» түгәрәк өстәле узды. Чарада институт хезмәткәрләре фронтовик галимнәр: Мидхәт Мөхәррәмов, Әбрар Кәримуллин, Илбарис Надиров, Һарун Йосыпов, Рашат Гайнанов, Шакир Абилов һ. б. турында докладлар укыды, алар хакында шәхси истәлекләре белән уртаклашты. Түгәрәк өстәлгә Институтта озак еллар эшләп киткән күренекле галимнәр: Илида Бәширова, Лена Гайнанова, Гамирҗан Дәүләтшин, Гөлзадә Саберова, Фәрит Хәкимҗанов, Фәрит Солтанов, Фәрит Яхин да чакырылган иде, алар фикер алышуда катнашып, оештыручыларга рәхмәтләрен белдерделәр.

**2025 елның 14–16 маенда** «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVI халыкара икътисади форумында Татарстан Республикасы Фәннәр ака-

демиясе стенды да тәкъдим ителде. Анда төрле фәннәргә караган алдынгы проектлар урын алды.

**2025 елның 16–18 маенда** Казанның Мәрҗани мәчетендә «Шиһабетдин Мәрҗани укулары» X Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе үтте. Быел ул «Евразия цивилизациясе контекстында өммәт трансформациясе: өстенлекләр, чакырулар һәм яңа офыклар» темасына багышланган иде. Экспертлар Россия җәмгыятенең хокукый культурасын һәм гражданлык үзенчәлеген үстерүдә татар дин белгечләренең һәм җәмәгать эшлеклеләренең роле турында фикер алыштылар.

Конференциядә катнашучыларга сәламләү сүзе белән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов мөрәҗәгать итте. Үзенең чыгышында ул: «Татарстан Фәннәр академиясе үзебезнең мөселман дини мәктәбен торгызуга, хокукый культураны үстерүгә һәм яшьләр арасында гражданлык җаваплылыгы тәрбияләүгә юнәлдерелгән фәнни проектларны һәм белем бирү программаларын гамәлгә ашыра», – дип билгеләде.

**2025 елның 26 маеннан 6 июненә кадәр** Мордовия Республикасының Темников, Атюрьев һәм Ельников районнарындагы татар авылларында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган комплекслы экспедиция эшләде. Институт галимнәре халык иҗаты, лингвистика, этномузыкология, халык һөнәрләре һәм кәсепләре, археография һәм эпиграфика юнәлешләре буенча бу төбәкләрдә яшәүче татарларның рухи һәм язма мирасын, матди һәм традицион музыкаль мәдәниятен, халык сәнгатен җыю һәм өйрәнү белән шөгыльләнде.

**2025 елның 9–11 июнендә** «Pax Tatarica: урта гасыр чыганаклары һәм тарихи контекст» дип аталган VIII Халыкара Алтын Урда форумы узды. Форум Болгар һәм Казан шәһәрләрендә оештырылды: беренче көнне Болгарда Форумның тантаналы ачылышы, пленар һәм секция утырышлары узды, калган көннәрдә Форум үз эшен Казанда дәвам итте.

Форумның төп оештыручылары – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Болгар ислам академиясе.

Форум Россия, Казахстан, Төркия, Мисыр, Марокко, Иран, Кытай, Япония, Франция, Канада һәм башка илләрдән йөздән артык галимне берләштерде. Алар Алтын Урда һәм татар ханлыклары тарихына караган яңа ачышлар һәм актуаль мәсьәләләр турында фикер алышты. Форумда Болгарның Алтын Урданың беренче башкаласы булуын раслый торган яңа материаллар тәкъдим ителде.

**2025 елның 19–20 июнендә** Казанда Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышланган «Мәгърифәтчелек һәм мәдәниятара багланышлар: заманча тикшеренүләр контекстында Каюм Насыйри мирасы» дип аталган халыкара фәнни форум үткәрелде.

Әлеге чараның төп оештыручысы – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты.

Форум эшендә чит илләрдән (Азәрбайҗан, Казахстан, Кыргызстан, Үзбәкстан) һәм Россиянең Мәскәү, Казан, Махачкала, Чабаксар, Уфа шәһәрләреннән галимнәр катнашты.

Каюм Насыйриның 200 еллыгы уңаеннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән яңа китаплар тәкъдим ителде: И.К. Загидуллинның «Великий татарский просветитель Каюм Насыри» (2024) хезмәте һәм Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ хезмәткәрләре әзерләгән «Каюм Насыйри календаре» (2025).

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2025. № 2

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 25.06.2025. Басылды: 27.06.2025.
Офсет кәгазе. Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Гарнитура «Times».
Басма табак 12. Тираж 100 данә. Заказ

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшриятында басылды
(нәшрият һәм типография адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал Татарстан, Башкортстан Республикаларында, Самара, Ульяновск, Оренбург, Әстерхан, Төмән өлкәләрендә бушлай таратыла

Г.М. Дәүләтшинның «Фронт һәм фән юлын узган галимнәр» мәкаләсенә




Беренче рәттә (сулдан уңга): Ә.Г. Кәримуллин, Я.Г. Абдуллин, М.К. Мөхәррәмов, Ш.Ш. Абилов, К.С. Сабиров; икенче рәттә (сулдан уңга): И.Н. Надиров, Ф.Н. Гыйззәтуллин, Р.Р. Гайнанов, Ф.С. Фәсиев. 1975 ел

И.Б. Бәшированың «“Әдәби тел тарихы – аның стильләре тарихы” (Латыйф Җәләйнең тууына 130 ел тулу уңаеннан)» мәкаләсенә



Латыйф Җәләй (уңнан өченче) хезмәттәшләре белән. 1953 ел

И.Г. Закированың «Фольклорчы Флора Әхмәтова-Урманче» мәкаләсенә



Казан дәүләт университеты студентлары Урманчелар гаиләсендә кунакта. 1986 ел

Л.М. Шкляева, Н.В. Герасимованың «Ф.Г. Халиков иҗатында тарихи жанр» мәкаләсенә



Ф.Г. Халиков. 1997. «Автопортрет». Киндер, майлы буяу



Ф.Г. Халиков. «Сөембикәнең хушлашуы». 2001. Киндер, майлы буяу

Е.Н. Шевченконың «Коки Минтаниның “Көлке академиясе” Айдар Җәббаров куелышында» мәкаләсенә









«Көл» спектакленнән күренешләр. Г. Камал исемендәге ТДАТ. Режиссёры Айдар Җәббаров



Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Мордовиядә комплекслы экспедициядә. 2025 ел

Яңа китап



## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗГА ФОТОКҮЗӘТҮ



ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «Бөек Ватан сугышы әдәбиятта һәм публицистикада» дигән түгәрәк өстәл утырышы. 2025 ел, 29 апрель



ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган «Сугыш утын үткән галимнәр» түгәрәк өстәл утырышында катнашучылар. 2025 ел, 14 май




Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышланган «Мәгърифәтчелек һәм мәдәниятара бәйләнешләр: заманча тикшеренүләр контекстында Каюм Насыйри мирасы» дип аталган халыкара фәнни форумда катнашучылар. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе. 2025 ел, 20 июнь




«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVI халыкара икътисади форумында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе делегациясе. 2025 ел, 14 май



Дагстан дәүләт университетында профессор Мөхәммәтсәет Мусаев истәлегенә багышланган XIV Халыкара фәнни конференциядә катнашучылар.
2025 ел, 10 апрель




ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Сәнгать белеме үзәге мөдире Рауза Солтанова җитәкчелегендәге бер төркем рәссамнар «Тукай Әстерханда» дип аталган арт-пленэрда катнашучылар арасында.
2025 ел, апрель